*«Нәфис-нәфасәти үсеш» юнәлешендә милли культура чаралары ярдәмендә баланың дөньяга эстетик карашы формалашуы һәм сәнгати үсеше берлектә карала. Мәктәпкәчә мәгариф системасына милли культураны кертү милли культура элементлары булган музыка, сынлы сәнгать, театр, фольклор, халык җырлары, биюләре, уеннары аша тормышка ашырыла. Бу юнәлешкә «Иҗади сәнгать», «Музыка» белем бирү өлкәләре керә.*



*Программа мәктәпкәчә балачакның яшь үзенчәлекләренә карап бирелгән бүлекләрдән тора.*

*1. Аңлатма язуы.*

*2. Программаны гамәлгә кертү һәм үзләштерү буенча өлкәннәр һәм балалар эшчәнлеген оештыру.*

*3. «Сәламәтлек», «Физик культура», «Куркынычсызлык», «Социальләштерү», «Хезмәт», «Танып белү», «Аралашу», «Матур әдәбият уку», «Музыка», «Иҗади сәнгать» белем бирү өлкәләрен үзләштерү буенча психолого-педагогик эш эчтәлеге.*

*4. Программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре буенча мониторинг.*

*Хөрмәтле хезмәттәшләребез! Программа мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән эшнең эчтәлеген баетырга, танып белүдә, иҗат итүдә аларның ихтыяҗларын канәгатьләндерергә, милли төбәк компоненты үсеше дәрәҗәсен тормышка ашырырга ярдәм итәр дип ышанабыз. Программа мәктәпкәчә балачакның мөһим чор икәнен күрсәтә, чөнки анда туган як тарихын, культурасын, табигатен танып белү баланың иҗтимагый уңышка китерәчәк культуралы, физик, акыл һәм шәхси сыйфатларына нигез булып тора.*

*Программаны төзүдә киңәшләре һәм «Матур әдәбият уку», «Музыка» белем бирү өлкәләре буенча күрсәткән ярдәмнәре өчен Казан шәһәре Совет районы 415нче балалар бакчасының өлкән тәрбиячесе К. В. Закировага, Идел буе районы 23нче балалар бакчасының музыка җитәкчесе З. Г. Ибраһимовага, Яңа Савин районы 405нче балалар бакчасының музыка җитәкчесе Г. Р. Гыйләҗетдиновага рәхмәт белдерәм.*



## *Пр ограмманы гамәлгә керт ү һәм үзләштерү буенча өлкәннәр һәм балалар эшчәнлеген оештыру*

*Көндәлек режим ул – балаларның эшчәнлек төрләре һәм ялының рациональ дәвамлылыгы, дөрес чиратлашуы. Режим мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе тарафыннан түбәндәгеләрне истә тотып төзелә:*

*– балаларның төркемдә булу вакытлары;*

*– гамәлдәге санитария нормалары һәм кагыйдәләре (СанПин);*

*– мәктәпкәчә белем бирү өлкәсендә федераль дәүләт таләпләре;*

*– мәктәпкәчә мәгарифнең үрнәк төп гомуми белем бирү программасы тәкъдимнәре;*

*– белем бирү процессын тормышка ашыруның үзенчәлекле шартлары (климатик, демографик, милли-мәдәни һ. б.);*

*– ел фасыллары һ.б.*

*Мәктәпкәчә мәгарифнең төп гомуми белем бирү программасының вариатив өлешен билгеләүче Программа күләме аны тормышка ашыру вакытының 20 % ын тәшкил итә, һәм ул мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә.*

*Программаны үзләштерү, тормышка ашыру буенча өлкәннәр һәм балалар эшчәнлеге көндәлек режимда ике төп модельдә оештырыла: өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлеге, балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге.*

*Белем бирү мәсьәләләренең чишелеше беренче модель кысаларында – өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлегендә – турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге төрендә дә, шулай ук режим вакытларында бара торган белем бирү эшчәнлеге төрендә дә тормышка ашырыла.*

*Турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге вакыт белән билгеләнгән шөгыльләрдә түгел, ә бәлки педагог үз теләге белән*



*бала эшчәнлегенең төрле төрләрен (уен, хәрәкәт, танып белүтикшеренү, аралашу, музыкаль, сәнгать, хезмәт эшчәнлеге, шулай ук матур әдәбият уку) оештыру аша яки аларны төрле формалар (проблемалы уен ситуациясе, матур әдәбият уку, күзәтү, хәрәкәтле уен, уен күнегүләре, эксперимент-тикшеренү эшләре, проект эшчәнлеге һ. б.) кулланып берләштергәндә тормышка ашырыла.*

*Бала туган ягы турында тулырак күзалласын өчен, тематик яктан комплекслы якын килергә тәкъдим ителә, ул балаларның яшь мөмкинлекләренә һәм кызыксынуларына ярашлы билгеле бер чынбарлыкны чагылдырырга һәм гомуми мәгънәне бирергә тиеш. Һәр яңа мәгълүмат балалар тарафыннан төрле кабул итү каналлары (күрү, ишетү, кинестетик) аша үзләштерелүен исәпкә алырга кирәк, шуңа күрә аның эчтәлеген үзләштергәндә бала эшчәнлегенең төрле*

*төрләрен файдаланырга тәкъдим ителә. Ләкин балаларның эшчәнлек төрләре белем бирү эчтәлегенең системасын чагылдырырга тиеш. Алар мәктәпкәчә мәгарифнең төп үрнәк гомуми белем бирү программасының эчтәлеген киңәйтергә һәм тирәнәйтергә мөмкин, бу – ата-аналарның белемгә ихтыяҗларын, балаларның танып белүгә карата кызыксынуларын канәгатьләндерергә, төбәк компонентының үстерешле потенциалын тормышка ашырырга мөмкинлек бирә.*
*Гадәти шөгыль үзенең кыйммәтен югалтмады, ләкин ул белем бирү процессының бердәнбер формасы булырга тиеш түгел. Ул балаларга белем бирүнең актив этабында, ягъни яңа материал биргәндә кулланыла. Ләкин педагогик эшнең үзләштерү этабында балаларны мөстәкыйльлеккә этәрүче башка формалар да актив рәвештә файдаланырга тиеш. Шөгыль барышында балалар туган телләрендә ирекле рәвештә аралашырга, ягъни фикерләрен әйтергә, сораулар бирергә, уртак эш өчен берләшергә мөмкиннәр. Шөгыльләрдә балаларны урнаштыруның төрле формаларын (өстәлләр артына, келәмгә, мольбертлар артына һ. б.) куллану зарур.*
*Төбәкнең _____________мәктәпкәчә белем бирү программасы 97*
*Балаларны татар (рус) теленә уртанчылар төркеменнән өйрәтә башларга тәкъдим ителә. Бу яшьтәге балаларга тел өйрәтү өчен атнасына 15 әр минут, зурлар төркемендә 25 әр минут, мәктәпкә әзерлек төркемендә 30 ар минутлы өчәр шөгыль бирелә. Бу вакытны эш төрләре буенча тәрбияче планлаштырылган тәрбия һәм белем бирү процессына яраклаштырып бүлә.*
*Тәрбиячегә татар (рус) телен өйрәнүче мәктәпкәчә яшьтәге балаларның телне ясалма тудырылган тел мохитендә үзләштерүләрен онытмаска кирәк. Тел мохите үстерешле характерда булырга тиеш. «Үстерешле тел мохите» төшенчәсе баланың үз тел тирәлеген (тел мохите), шулай ук үстерешле предметлы мохитне (тирәлекне) дә үз эченә ала. Татар (рус) телен өйрәтү шөгыльләре өчен махсус бүлмәләр булдыру зарур.*
*Бу бүлмәдә РФ һәм ТР дәүләт символлары, туган шәһәр, башкаладагы истәлекле урыннарның фотографияләре, татар (рус) халкының декоратив-гамәли сәнгать үрнәкләре сурәтләнгән альбомнар, үстерешле уеннар, балаларның төрле рәсемнәре, проектлары, кирәкле мәгълүматларны истә калдырырга ярдәм итә торган схемалар, татар халык әкиятләренең геройлары (уенчыклар), балалар матур әдәбияты, аудио-, видеоязмалар һ. б. булырга мөмкин.*
*Татар (рус) телендә сөйләшергә өйрәнү ул – сүзләр һәм аңлатмалар ятлау гына түгел, ә башка культура тирәлегендә яшәргә өйрәнү дә. Башка телне өйрәнү – башка культура, башка халык бәйрәмнәре һәм йолалары, әкиятләре, балалар уен-*

нары, фольклоры белән танышу. Шулай итеп, «тел мохите» төшенчәсен «культуралы» сүзен өстәп анықларга кирәк. Мондый мохит балаларга яңа белемнәр биреп кенә калмый, ә аларга үз культураларын яхшырак өйрәнергә ярдәм итә, чөнки белем бирү процессы чагыштырулар белән бара.
Мәктәпкәчә учреждениедә чит тел мохите тудыруда төп чараларның берсе булып өлкәннәрнең чит телдә сөйләм эшчәнлеге тора. Өйрәтү характеры сөйләм өйрәтү буенча мах-

сус шөгыльләрдә генә түгел, ә балалар эшчәнлегенең төрле төрләрендә һәм режим моментларында да чагылырга тиеш. Шулай табигый рәвештә барлыкка килгән сөйләшүләр (диалоглар) балаларга сөйләм тәртибе моделе һәм охшарга тырышу өчен үрнәк булып тора. Педагогның сөйләме балаларны өйрәтерлек булсын өчен, түбәндәге шартларны исәпкә алырга кирәк:
– татар (рус) телен өйрәтүче тәрбиячененң сөйләме балаларга аңлаешлы булырга тиеш; озын һәм төзелеше буенча катлаулы җөмләләрне кулланудан сакланырга кирәк;
– тәрбиячененң нәрсә әйткәнен бала аңламаса, кабатлап әйтергә, икенче төрле итеп әйтергә һ. б. ысуллар куллану тәкъдим ителә;
– белем бирү процессы баланың сөйләм үсеше бурычларын эзлекле рәвештә катлауландыру, эшлекле якын килү һәм интеграция (берләштерелү) принциплары нигезендә төзелә.
Белем бирүне оештыруга интеграцияле якын килү танып белү ысуллары һәм аның сәбәпләренең җыелмасын формалаштыру, танып белү ысулларының бер эшчәнлек төреннән икенчесенә күчүе итеп карала. Анда төп игътибар баланың төрле эш төрләрендә үзлегеннән аерым барлыкка килми, ә бер-берсен тулыландыра, бербөтен педагогик процесска берләштерә торган интегратив сыйфатлар үсешенә бирелә.
Интегральләшкән белем бирүнең үзенчәлеге булып аның белем бирүнең үзәге булган бер мөһим яки өстенлек итүче эшчәнлек нигезендә төзелүе тора. Бу эшчәнлек белән берләшкән башка эшчәнлекләр белем бирүнең төп эчтәлеген, яшәп килгән бәйләнешләрне һәм балаларның алган белемнәрен мөстәкыйль эшчәнлектә куллану мөмкинлекләрен тирәнрәк аңларга ярдәм итәләр.
Үсешнең төрле юнәлештәге белем бирү бурычлары берберсен тулыландыралар һәм баеталар. Еш кына бер үк белем бирү бурычлары төрле эчтәлектә чишелергә мөмкин. Моннан тыш, эшчәнлекнең бер төрендә үсешнең берничә бурычын хәл

итәргә була. Мәсәлән, нәтиҗәле эш төрләрендә, техник яктан үзләштерелүеннән тыш, танып белү бурычларын (балалар-

*ны көн мозаикасы сәнгате белән таныштыру, көн читекләр, аларның алгы һәм балтыр өлешләрендәге бизәкләрен карау), иҗади сәләтләрен, сөйләм үстерү, әгәр эшләнгән эскиз уен шартына туры килсә – уен эшчәнлеген формалаштыру бурычлары ___________(балалар үзләренең уй-теләкләрен, эш нәтиҗәләрен сөйлиләр) хәл итәлергә мөмкин.*

*Белем бирү процессын билгеле бер тәртиптә төзегәндә, белем бирү бурычлары бер-берсен тулыландыра ала. Шундый мөмкинлекләрне белем бирү процессын планлаштырганда истә тотарга кирәк.*

*Белем бирү процессын планлаштыру балаларның үзләренә генә хас булган төрле эш төрләре комплексын «уртак тема» тирәли берләштерүне күздә тота. Теманы сайлаганда, инициатива педагоглар, балалар һәм аларның әти-әниләренә бирелергә мөмкин. «Тематик атналар», «Вакыйгалар», «Проектлар», «Табигатьтә ел фасыллары күренешләре», «Бәйрәмнәр», «Йолалар» һ. б. темалар була ала. Бирелгән эчтәлекне үзләштерү өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлегендә, шулай ук балаларның мөстәкыйль эшчәнлегендә тормышка ашырыла.*

*Балалар эшчәнлегенең төрләрен шулай төзергә тәкъдим ителә: һәр киләсе эшчәнлек кузаллауларны баетырга, бирелгән вакыйгага, күренешкә яңача карарга, ә нәтиҗәле эшчәнлек аларны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирергә тиеш. Шундый якын килү генә тарихны, мәдәниятне, туган якның табигатен аңлы рәвештә иҗади өйрәнергә һәм алган белемнәрне мөстәкыйль кулланырга ярдәм итә.*

*Тәрбиячегә, балаларның активлык балансын тәэмин итеп, эшчәнлекнең катгый билгеләнгән графигын түгел, ә үзгәртә ала торганын кулланырга, аларның эзлеклелеген мөстәкыйль рәвештә билгеләргә тәкъдим ителә. Теге яки бу мәсьәләләрне чишү өчен, көндәлек режимда бирелгән вакыт кысаларында эшчәнлекнең бер төрен икенчесе белән алыштырырга мөмкин.*



*Эчтәлекне планлаштырганда, өлкәннәр белән балаларның үзара мөгамәләләренең төрле формаларын файдалануны күздә тоту мөмкин: турыдан-туры, турыдан-туры булмаган белем бирү, тигез хокуклы хезмәттәшлек. Турыдан-туры белем бирүдә тәрбияче актив позициядә тора, балалар мөстәкыйль рәвештә үзләштерә алмаган эчтәлекне ача (шәһәрнең символларын күрсәтә, истәлекле урыннары, тарихы турында сөйли). Аларга бирелгән мәгълүматны үзләштерергә ярдәм итәргә кирәк. Өлкәннәр белән балаларның һәм балаларның үзара партнёрлык эшчәнлеге үзләштерүнең төрле этапларында еш-рак файдаланыла, бу – эчтәлекнең үзенчәлегенә һәм балаларның тәҗрибәсенә бәйле.*

*Баланың аңы өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән уртак*

***эшчәнлектә генә түгел, ә мөстәкыйль эшчәнлектә дә үсә. Шуңа күрә тәрбиячегә төркемдә баланың үзлегеннән үсеш процессына, мөстәкыйль иҗади башлангычларына этәргеч көч булып торган предметлы-үстерелешле мохит оештыру мөһим. Төрле яшьтәге балалар белән тәрбия һәм белем бирү процессын планлаштыруның үзенчәлекләре бар. Кечкенәләр, уртанчылар, зурлар төркемнәрендә белем бирү процессы күбесенчә ирекле формаларда оештырылса, мәктәпкә әзерлек төркемендә махсус оештырылган өйрәтү шөгыльләренә мөһим урын бирелә. Шөгыльләрдә уку-укыту методик комплектын куллану, укыту һәм уен бурычларын кертү белем бирү эшчәнлеге элементларының үсешенә (бурычны кабул итәргә өйрәнү, инструкция буенча эш итү, үз-үзеңне тикшереп торуга) ярдәм итә. Ләкин бу очракта оештырылган белем бирүнең ролен арттырмаска кирәк. Яшь үзенчәлекләре буенча, балаларга тормышчан вакыйгаларны күзәтү, билгеле әйберләр белән эш итү, уен һәм ярыш характерындагы эшчәнлек аеруча якын.***

***Тәрбия һәм белем бирү процессын проектлаштырганда, мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе педагогларының (тәрбиячеләр, логопедлар, физик культура инструкторлары,***



***музыка җитәкчеләре, өстәмә белем бирү педагогларының) эшчәнлеген планлаштыру аша берләштерү мөһим. Мәктәпкәчә мәгарифнең төбәк программасын тормышка ашыруда педагоглар эшчәнлеге эчтәлеген үзара килешү буенча системалы эш алып бару зарур. Балаларның билгеле бер эчтәлекне үзләштерүләре йомгаклау вакыйгасы – ял вакыты, бәйрәм, спектакль, күргәзмәләр оештыру белән тәмамланырга мөмкин. Анда балалар алган белемнәрен йомгаклыйлар, үзләренең уңышларын күрсәтәләр. Әгәр дә сценарийга алынган белемнәрне куллануны таләп итүче ярыш моментлары, викторина элементлары, гамәли биремнәр кертелсә, бу чаралар балалар бакчасындагы педагогик процесс барышын күзәтүнең үзенчәлекле ысулы булып тора ала. Мәсәлән, «Безнең шәһәр транспорты» проекты команданың ата-аналар катнашындагы уен ярышы рәвешендәге «Шәһәр урамнарындагы куркынычсызлык» музыкаль-спорт күңел ачу чарасы белән тәмамланырга мөмкин.***

***Тәрбия һәм белем бирү процессын проектлаштыруга интеграцияле якын килүне куллануның үз өстенлекләре бар: үсеш һәм белем бирү бурычлары эчтәлекле-мәгънәви кырның үзәге булып тора, бу – бала эшчәнлегенең нигезен ныгыта, үсеш нәтиҗәлелеген көчәйткәндә балаларга булган психологик йөкләнешне киметүне тәэмин итә; мөстәкыйльлек һәм активлык дәрәҗәләренең көчәюенә, әйләнә-тирә турында тулы***

*күзаллаулар формалашуга мөмкинлек бирә. Педагогик процесста катнашучыларның үзара ярдәм итешүләре тәэмин ителә, баланың үсешенә бердәм караш булдырыла. Балаларның уңышы ата-аналарның казанышына әйләнә.*



## *Кечкенәләр төркеме*

### *(3 яшьтән 4 яшькә кадәр)*

### *Психолого-педагогик эш эчтәлеге*

### *Физик үсеш*

### *«Сәламәтлек» белем бирү өлкәсе*

***«Сәламәтлек» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның сәламәтлекләрен саклау, аларда сәламәтлек культурасы нигезләрен формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.***

***Балаларның физик һәм психик сәламәтлекләрен саклау һәм ныгыту; учреждение төрен һәм тибын, булган шартларны, төркем тулылыгын, балаларның сәламәтлек һәм үсеш торышы үзенчәлекләрен, шулай ук төбәкнең климатик шартларын һәм ел фасыллары үзенчәлекләрен исәпкә алып, бала организмын системалы чыныктыруга, хәрәкәтләрнең төп төрләре формалашуга һәм камилләшүгә шартлар тудыру.***

***Культура-гигиена процедураларының төп алгоритмнары белән таныштыру.***

***Балаларны гигиена процедураларын аңлы һәм мөстәкыйль рәвештә башкарырга гадәтләндерү. Сабынны дөрес куллану, кулларны, битне, колакларны чиста юу; юынгач коры итеп сөртенү, сөлгене урынына элү, тарак һәм кулъяулык куллану күнекмәләрен формалаштыру.***

***Өстәл янында үз-үзеңне дөрес тотуның иң гади күнекмәләрен формалаштыру: аш һәм чәй кашыкларын, чәнечке, салфетканы дөрес куллану.***

***Ипине вакламаска, азыкны түкми-чәчми ашарга, ризыкны авызны ябып чәйнәргә, ашап туйгач рәхмәт белдерергә күнектерү.***



***Милли ризыклар: токмачлы аш, шулпалы пилмән, чумар ашы, сөтле чәй һ. б. белән таныштыру.***

***Файдалы һәм зарарлы азык-төлек турында күзаллау булдыру; яшелчәләр һәм җиләк-җимеш, кеше организмы өчен файдалы сөт ризыклары: каймак, катык, эремчек һ. б. белән таныштыру.***

***Сәламәтлекнең әһәмиятен аңлату, сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү өчен шартлар тудыру. Үз сәламәтлегеңә һәм якын кешеләреңнең сәламәтлегенә сакчыл караш тәрбияләү.***

***Көндәлек тормышта гигиена күнекмәләрен үтәүгә һәм***

*пөхтәлек булдыруга ихтыяҗ формалаштыру.*

*«Физик культура» белем бирү өлкәсе*

*«Физик культура» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда физик культура шөгыльләренә кызыксыну һәм аңлы караш, гармонияле физик үсеш формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.*

*Хәрәкәтле уеннарда балаларның хәрәкәт активлыгын формалаштыру.*

*Шуышу, үрмәләү күнекмәләрен үстерүче уеннарны, тупны ыргыту һәм тотып алу уеннарын хуплау. Акрынлап катлаулырак кагыйдәле һәм хәрәкәтләр алмашынулы уеннар уйнарга өйрәтү.*

*Уен үрнәкләре*

*Йөрүле һәм йөгерүле уеннар: «Миңа таба йөгерегез», «Песи һәм тычканнар», «Маэмай», «Флаг янына йөгерегез», «Аю урманында», «Кетәклектә төлке», «Атлар», «Такси», «Түгәрәктә».*

*Сикерүле уеннар: «Инеш аша», «Күбәләкне тот», «Чыпчыклар һәм песи», «Түмгәктән түмгәккә».*



*Шуышулы, үрмәләүле уеннар: «Тавык һәм чебиләр», «Йорт куяннары».*

*Тупны ыргыту һәм тотып алу уеннары: «Туплар», «Кызыл, зәңгәр...», «Төз ыргыт», «Тот, ыргыт, төшермә...».*

*Әйләнә-тирәдә ориентлашуга уеннар: «Чыпчыклар һәм автомобиль», «Трамвай», «Үз төсеңне тап», «Үз өеңне тап».*

*Аз хәрәкәтле уеннар: «Машина килә», «Куык», «Тигез юл буйлап», «Кошчыклар».*

*«Куркынычсызлык» белем бирү өлкәсе*

*«Куркынычсызлык» белем бирү өлкәсе эчтәлеге үз тормышыңның куркынычсызлыгы нигезләрен һәм экологик аң (әйләнә-тирә дөнья куркынычсызлыгы) алшартларын формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.*

*Тормыш куркынычсызлыгы нигезләрен формалаштыру*

*Балаларны балалар бакчасында үз-үзләрен тотуның иң гади кагыйдәләре белән таныштыру.*

*Тормышта була торган куркыныч чыганаклары (кайнар су, ут, кисә һәм чәнчи торган очлы предметлар, электр приборлары һ. б.) турында беренчел күзаллаулар булдыру.*

*Бассейн һәм сулыкларда коенганда сак булырга күнектерү.*

*Юлларда хәвеф-хәтәрсез йөрү тәртибе формалаштыру*

*Балаларны юлларның машиналар һәм җәяүлеләр йөри торган өлешләре (тротуар) белән таныштыру; светофорның кы-*

зыл, сары һәм яшел төсләренең мәгънәләрен аңларга ярдәм итү. Күрү сигналлары ярдәмендә йөрергә өйрәтү.
Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү өчен кирәкле булган ситуация һәм объектларны аерып карап, урам, транспорт чаралары турында бербөтен күзаллау формалаштыру.

Хәрәкәт итү чараларының атамалары һәм аларны файдалану максатлары белән таныштыру. Җиңел һәм йөк машиналарының охшаш һәм аермалы якларын табарга, мөһим детальләрен (автомобильдә: кабина, руль, тәгәрмәчләр һ. б.), тору урынын (тәрәзә артында, биек, ерак) әйтә белергә өйрәтү. Хәрәкәт итү чараларының (трамвай, троллейбус, автобус) кайбер охшаш якларына игътибар итәргә, аларны аерым үзенчәлекләре, бурычлары буенча төркемли белергә күнектерү.
Транспорт төрләре (җир өсте, су, һава һ. б.) турында беренчел күзаллаулар булдыру.
Тавыш чыганагының (хәрәкәт итә торган транспорт, автомобиль сигналы, светофорның яшел төсе вакытындагы тавыш сигналы һ. б.) урынын билгели белү, төрле яңгырашлы тавышны кабул итү, хәрәкәт итүче самолёт, поезд, трамвай һ. б. ның тавышларын аера белү күнекмәләрен үстерү. Ишетү игътибарлылыгын үстерү.
Өлкәннәр хезмәте (машина йөртүче, ЮХИДИ инспекторы, кондуктор (билет сатучы) һ. б.) турында күзаллау формалаштыру, аларның эш-гамәлләренә һәм эш нәтиҗәләренә игътибар итү.
«Автобус», «Трамвай», «Такси» һ. б. сюжетлы-рольле уеннар үсеше өчен предметлы-уенлы мохит булдыру; балаларга образлы уенчыкларны, аларны алмаштыручы предметларны, уен мохите тудыра торган модульләрне иркен куллану мөмкинлеге бирү.
Сюжетлы-рольле уеннарны, яки шәхси, аерым бер уенны мөстәкыйль оештыруны хуплау.
Балалар арасында роль алу, рольләр бүлешү, уеннарда берләшә белү һәм рольдә аралашу осталыкларын үстерү; җәмәгать транспортында аралашу культурасы белән бәйле рольле репликаларны хуплау.
Балаларның дидактик материал белән булган мөстәкыйль уеннарына шартлар тудыру. Су һәм ком белән (көймәчекләр җибәрү, юллар төзү һ. б.) уйнауларны хуплау. Хәрәкәтле уен

(«Чыпчыклар һәм автомобиль», «Поезд» һ. б.) кагыйдәләрен үтәргә өйрәтү.
Өч тәгәрмәчле велосипедта турыга, түгәрәк буйлап, борылышлар ясап йөрергә өйрәтү.
Әдәби әсәрләр эчтәлеген балаларның үз тәҗрибәләре,

*көндәлек тормышлары һәм әйләнә-тирәләре белән бәйле белүләренә ирешү. Баланың «Ә минем өемдә мондый машина бар» тибындагы җөмләләренә актив җавап бирү.*
*Балаларның инициативалы сөйләмен үстерү, хәрәкәт итү чаралары турында күзаллауларын киңәйтү һәм ачыклау максатыннан, мөстәкыйль карау өчен төрле рәсемле китаплар, реклама буклетлары, техник уенчыклар тупланмасын карарга мөмкинлек бирү; балаларның сорауларын хуплау.*
*Әйләнә-тирәдә гади закончалыклар һәм бәйләнешләр булуына игътибар итү, мәсәлән, әгәр караңгы икән – ут кабызырга, урамда тайгак икән – кеше үтеп йөри торган җирләрдә ком сибәргә һ. б.*
*Экологик аң алшартларын формалаштыру*
*Табигатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре белән таныштыру. Табигатьтә куркыныч тудыру чыганаклары (таныш булмаган хайваннар, бөҗәкләр, үсемлек җимешләре, сулыклар һ. б.) турында беренчел күзаллаулар формалаштыру.*
### *Социаль-шәхси үсеш*
### *«Социальләштерү» белем бирү өлкәсе*
*«Социальләштерү» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның социаль характердагы беренчел күзаллауларын үзләштерү һәм балаларны социаль мөнәсәбәтләр системасына кертү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.*

*Тирә-юньдәгеләргә карата кызыксыну һәм дусларча мөнәсәбәт тәрбияләү. Туган телдә ышанычлы аралашу шартлары тудыру. Әйләнә-тирә дөнья, туган шәһәр (авыл), республика вакыйгалары турындагы төрле мәгълүмат чыганагы буларак, балаларның өлкәннәр белән аралашуга ихтыяҗын хуплау.*
*Культуралы аралашу күнекмәләре булдыру (әңгәмәдәшенең милләтенә карап, ачык йөз белән шул телдә исәнләшү һәм сабуллашу; үтенеч, тәкъдимнәрне әдәпле итеп белдерү; ярдәм, сый-хөрмәт өчен рәхмәт белдерү; яшьтәшенә исеме белән ягымлы итеп эндәшү, килешмәү яки канәгать булмауны әдәпле генә аңлата белү).*
*Балаларны республиканың истәлекле төп бәйрәмнәре белән таныштыру. Балалар бакчасы тормышы, республикадагы, илдәге вакыйгаларга мөнәсәбәтле булу хисе тәрбияләү.*
*Әйләнә-тирә тормыш, әдәби әсәрләр һәм мультфильмнарның эчтәлегеннән чыгып, күңеленә ошаган ике-өч бала белән уеннар оештыра; «Чәкчәк пешерәбез» һ. б. типтагы уен күнегүләрендә уен гамәлләрен башкара белергә өйрәтү.*
*Балаларның тормыш тәҗрибәсен, предметлы-уенлы мохит-*

*не, уйнау культурасын баетып, татар һәм рус халыкларының көндәлек тормышын чагылдыра торган сюжетлы-рольле уеннар оештыру өчен шартлар булдыру. Балаларга уен өчен мөстәкыйль рәвештә милли уенчыклар, бизәнү-ясану әйберләре, киемнәр һ. б. сайларга ярдәм итү.*

*Персонаж белән бәйләнешкә керүнең беренче тәҗрибәсен (курчак Алсу концерт күрсәтә), өлкәннәр белән аралашу даирәсен киңәйтү (әби авылга кунакка чакыра) юлы белән, сәхнәләштерелгән уеннарга кызыксыну уяту.*

*Авазлар белән башкарыла торган уен-гамәлләргә җавап бирү, татар композиторлары музыкасы астында һәм яңгыраган сүзгә (татар поэзиясе һәм кече фольклор әсәрләрендәге) хайван һәм кошларга охшатып хәрәкәтләр ясау теләге уяту.*



*Халык уенчыклары, курчак театры персонажлары, музыкаль уенчыклар (курай, гармун һ . б.) белән күңел ачу уеннары оештыру.*

*Гаилә әгъзалары (әти-әни, бабай-әби, абый-эне, апа-сеңел), аларның исемнәре, бер-берләрен кайгырту ысуллары турында күзаллаулар формалаштыру; өлкәннәрнең үтенеч һәм йомышларын үтисе, гаилә әгъзалары белән уртак хезмәттә катнашасы килү теләкләрен хуплау. Ата-ана һәм башка якын кешеләргә карата игътибарлы мөнәсәбәт тәрбияләү.*

## *«Хезмәт» белем бирү өлкәсе*

*«Хезмәт» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда хезмәткә уңай мөнәсәбәт формалаштыру максатын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.*

*Кече фольклор жанрлары ярдәмендә балаларда хезмәт эшчәнлеге турында кайбер күзаллаулар формалаштыру. Балаларның үз-үзләренә хезмәт күрсәтү һәм хезмәт эшчәнлекләре (хуҗалык-көнкүреш хезмәте, табигатьтәге хезмәт) барышында татар халык мәкальләрен файдалану.*

*Әти-әниләрнең балалар аңлый торган һөнәрләре (табиб, сатучы, шофёр, төзүче һ. б.) белән таныштыру.*

## *Танып белү-сөйләм үсеше*

## *«Танып белү» белем бирү өлкәсе*

*«Танып белү» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда танып белү ихтыяҗларын һәм акылны үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.*

*Баланы үзе яши торган урам, шәһәр (авыл) исемнәрен әйтергә өйрәтү. Әйләнә-тирә (шәһәр яки авылның төп объ-*



*ектлары), янәшәдәге предметлар, аларның билгеләнешләре*

*белән таныштыруны дәвам итү. Кешеләр яши торган йортларның төзелеше, өй кирәк-яраклары турындагы күзаллауларын үстерү.*

*Балалар бакчасында, өйдә була торган вакыйгаларда (бәйрәм иртәләрендә, якын кешеләренең һәм яшьтәшләренең туган көннәре һ. б. бәйрәмнәр уңаеннан бүләк әзерләүдә, гаилә бәйрәмнәрендә катнашу һ. б.) актив катнашасы килү теләге уяту.*

*Үз-үзләрен кунакта, дусларының туган көннәрендә, халык бәйрәмнәрендә, балалар бакчасында әдәпле тоту кагыйдәләренә өйрәтү. Урамда, юлларда, җәмәгать транспортында тәртип кагыйдәләре белән таныштыру.*

*Балаларда ял (бәйрәм) көннәрен кем белән, кайда (циркта, «Кырлай» аттракцион паркында, үзәк мәйданда, шәһәр урамнарында, шәһәрдән читтә) үткәрүләре турында сөйләргә теләк уяту. Вакыйгаларга уңай эмоциональ мөнәсәбәт чагылышын, алган тәэсирләрен өлкәннәр һәм балалар белән бүлешүгә омтылышларын хуплау.*

*Туган якның кайбер үсемлекләре: агачлар (каен, имән, чыршы), куаклар (сирень, гөлҗимеш), чәчәк атучы үлән үсемлекләр (тузганак, үги ана яфрагы), бүлмә гөлләре (яран, фикус) белән таныштыру. Бөҗәкләр (күбәләк, камка, энә карагы) турындагы күзаллауларын киңәйтү.*

*Үзләре яшәгән җирлектәге йорт һәм кыргый хайваннар, аларның үзенчәлекләре белән таныштыру эшен дәвам итү. Хайваннар дөньясына, барлык тереклек ияләренә, табигатькә карата кызыксыну уяту. Балаларны тәүлек бүленеше һәм табигатьтәге сезонлы үзгәрешләрне, кешеләрнең ел фасыллары белән бәйле хезмәт эшчәнлеген күрә белергә өйрәтү. Әйләнә-тирә табигатьнең матурлыгына (салават күпере, агачлардагы бәс, беренче чәчәкләр күренү һ. б.га) соклана белү күнекмәләре үстерү.*



## *«Аралашу» белем бирү өлкәсе*

*«Аралашу» белем бирү өлкәсе эчтәлеге әйләнә-тирәдәге кешеләрнең үзара мөгамәләсенең конструктив ысул һәм чараларын үзләштерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.*

*Баланы туган телендә төрле темаларга сөйләшергә, аралашырга өйрәтү; күргәннәре турында күзаллап сөйләргә генә түгел, тормышында булган вакыйгалар, башкарган эшгамәлләре, үзен кызыксындырган күренеш һәм предметлар, туган як табигате объектлары турында да сөйләргә күнектерү. Сорауларга җавап бирергә өйрәтү. Үз фикерләрен әйтү, үтенеч һәм тәкъдимнәр белән өлкәннәргә мөрәҗәгать итү ом-*

тылышларын хуплау.

Таныш булган татар (рус) халык әкиятләреннән өзекләр, шигырьләрне сәхнәләштереп сөйли белү күнекмәләре бирү; 2–3 җөмләдән торган хикәяләр төзергә өйрәтү. Җөмләдәге сүзләрне дөрес бәйләр өчен, кушымчаларны дөрес файдаланырга өйрәтү.

Балаларның уен барышында үзара мөнәсәбәтләрен (уендагы үзләренең эш-гамәлләре турында сөйлиләр, уенчыклар, аларны алмаштыручы предметларны сүзләр белән атыйлар) җайга салырга булышу. Балаларның сөйләмен барлык белем бирү өлкәләрен үзләштерү өчен кирәкле сүзләр белән баету.

Туган телдәге авазларны дөрес әйтергә өйрәтү, аваз культурасы тәрбияләү.

## «Матур әдәбият уку» белем бирү өлкәсе

«Матур әдәбият уку» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда китап укуга кызыксыну һәм ихтыяҗ формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.



Көчле хис-кичерешләр чыганагы булган китапка һәм өлкәннәр белән әдәпле аралашуга кызыксыну формалаштыру.

Яшьтәшләре белән бергәләп тәрбиячenең сәнгатьле уку яки сөйләмен тыңлау күнекмәләре булдыру.

Татар халык әкиятләрендә, язучы һәм шагыйрьләрнең әдәби әсәрләрендә вакыйгалар барышын күрсәтмәлелек (уенчыклар, рәсемнәр, хәрәкәтләр) ярдәмендә күзәтергә, аларның эчтәлеген сүзләр, хәрәкәтләр, ишарәләр белән белдерергә өйрәтү. Уен гамәлләрендә катнашасы килү теләге булдыру, кыен булмаган сорауларга җавап бирергә, персонажларга үз мөнәсәбәтен белдерергә, кара-каршы сөйләшүләр алып барырга күнектерү.

Әдәби әсәрләргә карата хисси кичерешләр булдыру, әдәби сүзгә кызыксыну уяту.

Китаптагы иллюстрацияләрне караганда, әдәби әсәр геройларын һәм аларның гамәлләрен танырга булышу. Татар халык авыз иҗаты үрнәкләре (юаткычлар, әйтемнәр, бармак уеннары) белән таныштыру. Кече фольклор формаларын көндәлек тормышта куллануны хуплау.

### Тәкъдим ителә торган әсәрләр

#### Балаларга уку өчен

Җырлар, такмаклар, эндәшләр, бармак уеннары: «Әллибәлли итәрсең…», «Тилгән...», «Салкын су, чиста су...», «Бас, кызым, Әпипә...», «Әтисе дә ярата…», «Әйдә, әйдә, Зөбәйдә...», «Песи, песи, пескәем...», «Минем кызым дәү кебек», «Көзгегә карыйм әле...», «Чәбәк-чәбәк әбкәсе...», «Там, там, тамчы,

*там…», «Гөлдергү, гөлдергү...», «Суы сарыксын…», «Минем кызым бик иркә…», «Бармак, бармак, кайда булдың?», «Олыга утын ярырга...».*
*Әкиятләр: Татар халык әкиятләре: «Аю белән бабай», «Кыз һәм икмәк», «Аю белән хатын», «Мәче белән Аю», «Кем нәрсә ярата?», «Төлке белән Каз»; рус халык әкиятләре: «Шалкан», «Чуар тавык» «Өч аю».*

*Шигърият: М. Фәйзуллина. «Көзге яңгыр»; Р. Харис. «Лап-лап»; Ә. Исхак. «Чишмә»; Н. Каштан. «Безнең сыер»; Ә. Исхак. «Беренче рәхмәт»; З. Туфайлова. «Шофёр булам»; З. Гомәрова. «Ул шуңа кечкенә»; Э. Мөэминова. «Үз телендә сөйләшә»; Р. Харис. «Ботка»; Р. Вәлиева. «Минем сеңлем»; М. Мазунов. «Энесенә ул апа»; Б. Рәхмәт. «Су», «Ләлә чана шуа»; Һ. Такташ. «Ләйлә»; Ә. Рәшит. «Кыш бабай»; Җ. Тәрҗеманов. «Үзен бик чиста йөртә»; М. Мазунов. «Кәҗә»; Д. Гарифуллин. «Тавыклар белән Таһир»; Х. Халиков. «Зиләнең курчагы»; Җ. Дәрзаман. «Алмаз»; М. Фәйзуллина. «Тәти кул»; Ә. Ерикәй. «Тышта яз»; З. Гомәрова. «Минем бүләк»; Ә. Кари. «Ике кыз»; Х. Вахит. «Уңган сыерчык»; Г. Насыйбуллин. «Әнигә булышам»; Ә. Бикчәнтәева. «Минем бакчам»; Г. Таһирова. «Йокла, курчак»; Ә. Кари. «Курчак»; Р. Вәлиева. «Сүз тыңлаучан булыгыз»; Р. Харис. «Башмак кигәндә»; Ф. Яруллин. «Ап-ак иткән» А. Барто. «Әни белән сөйләшү», Ә. Юныс тәрҗемәсе.*
*Чәчмә әсәрләр. Әдәби әкиятләр: Д. Аппакова. «Рөстәм»; Г. Бакир. «Сания инде зур үсте»; М. Әмир. «Бәби әйтә»; Р. Гыйззәтуллин. «Кечкенә Ринат»; А. Алиш. «Куян кызы»; Р. Батулла. «Елак әтәч»; Р. Гыйззәтуллин. «Айсылу»; Р. Ишморатова. «Яңа чана»; Г. Лотфи. «Песнәк белән Әнисә»; Г. Бакир. «Сания бакчага бара»; А. Әхмәт. «Минеке, тимә»; Җ. Тәрҗеманов «Йокы бабай»; А. Алиш. «Чукмар белән Тукмар»; И. Шәймөхәммәтов. «Мактанчык бака»; Ш. Перро. «Кызыл калфак», З. Садыйкова тәрҗемәсе; К. Ушинскийдан. «Әтәч үзенең гаиләсе белән», «Дару», «Бергә җайсыз, аерым күңелсез».*
*Яттан өйрәнү өчен*
*Татар халык авыз иҗаты: «Яңгыр, яу!», «Бу бармак…», «Песи-Нечкәбил…»; Ә. Ерикәй. «Көз»; Ә. Бикчәнтәева. «Туп»; Ш. Маннур. «Яратам»; Ә. Бикчәнтәева. «Салкын, саф һава»; Б. Рәхмәт. «Кыш бабай»; Н. Исәнбәт. «Куянкай»; З. Туфайлова. «Әни сүзе»; Б. Рәхмәт. «Яз»; Г. Лотфи. «Әтәч».*

*Нәфис-нәфасәти үсеш*
*«Иҗади сәнгать» белем бирү өлкәсе*

*«Иҗади сәнгать» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда әйләнә-тирәдәге матурлыкка кызыксыну уятуны һәм үзүзләрен күрсәтү ихтыяҗларын канәгатьләндерүне формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.*

*Нәтиҗәле эшчәнлек төрләрен үстерү*

*Рәсем ясау*

*Балаларга рәсемнәрдә әйләнә-тирә табигатьнең матурлыгын (миләш тәлгәшләре, җиргә коелучы төрле төстәге яфраклар һ. б.ны) сурәтләп бирергә тәкъдим итү.*

*Балаларны сәнгать әсәрләрен кабул итәргә әзерләү. Татар декоратив-гамәли сәнгатенең иң гади бизәк элементлары һәм алар белән бизәлгән көнкүреш предметлары белән таныштыру. Сәнгать әсәрләренең матурлыгына уңай эмоциональ караш тәрбияләү.*

*Балаларны декоратив эшчәнлеккә тарту: милли орнамент элементларын (лалә, күкчәчәк, кыңгырау чәчәк, яфраклар һ. б.ны) буяу ысулларын күрсәтү. Сурәтләнә торган предметка туры килгән төсне сайлап алырга өйрәтү.*

*Татар орнаментына хас булган төс исемнәрен (кызыл, зәңгәр, яшел, сары, ак, кара) белүләрен ныгыту. Бер, ике яки берничә төсне кулланып, сурәтләр тасвирларга өйрәтү.*

*Балаларны төрле юнәлештә туры сызыклар (кыска, озын, вертикаль, горизонталь, авыш) сызарга өйрәтү. Төрле формадагы (түгәрәк, турыпочмаклы) предметлар сурәтләүгә өйрәтү. Гади сурәтләр (Казан сөлгесе, тастымал, кечкенә тәлинкә һ. б.) иҗат итү күнекмәләрен үстерү.*

*Татар гамәли сәнгате мотивлары буенча коллектив композицияләр төзегәндә, өлкәннәр белән бергәләп эшләү тәҗрибәсе формалаштыру.*



*Әвәләү*

*Әвәләү эшчәнлегенә кызыксыну уяту. Балчык, пластилин, тозлы камырның үзлекләре һәм аларны әвәләү ысуллары турындагы күзаллауларын ныгыту.*

*Балчык, пластилин кисәкләрен туры һәм әйләнүле хәрәкәт белән әвәләү; ике кулның уч төпләре белән басып, шарны яссыландыру. Уйнау өчен гади генә формалар – коймак, кабартма, мич күмәчләре әвәләргә дәртләндерү.*

*Балчык, камыр белән пөхтә эш итү күнекмәләрен ныгыту; әвәләп ясалган әйберләрне һәм кисәкләрне әвәләү тактасына кую.*

*Әвәләнгән фигуралардан күмәк композиция төзергә тәкъдим итү (подностагы пәрәмәчләр, чәй сервизы һ. б.). Күмәк эшчәнлекнең нәтиҗәсен күреп, шатлану хисләре тудыру.*

*Кисеп ябыштыру*

*Балаларны аппликация сәнгатенә тарту, бу эшчәнлек төренә кызыксыну уяту. Татар орнаментының алдан ук әзерләнгән чәчәк-үсемлек формаларын (лалә, кыңгырау чәчәк, ромашка (акчәчәк), гөлҗимеш, миләш тәлгәшләре һ. б.) башта кәгазь битенә таратып салырга, аннары тар кәгазь кисәгендә билгеле бер тәртиптә тезеп куярга, уртага, квадрат, түгәрәк кырыйларына урнаштырырга өйрәтү.*
*Татар декоратив-гамәли сәнгате мотивлары буенча шәхси һәм күмәк композицияләр иҗат итү күнекмәләрен үстерү.*
*Сынлы сәнгатькә тарту*
*Татар халык декоратив-гамәли сәнгате әсәрләренә (милли киемдәге курчак, Шәмәрдән, Актүбә уенчыклары һ. б.га) кызыксыну уяту.*
*Балаларга якын, таныш булган хис-кичерешләр чагылдырылган сынлы сәнгать әсәрләренә, халык әкиятләре, татар язучылары һәм шагыйрьләренең хикәя-шигырьләреннән торган рәсемле китапларга уңай эмоциональ мөнәсәбәт булдыру.*

### *«Музыка» белем бирү өлкәсе*
*«Музыка» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис-тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.*
*Татар халык музыкасы һәм татар композиторларының музыкасына, музыка астында башкарылган хәрәкәт импровизацияләренә (үзлектән яки тәрбияче ярдәмендә) уңай мөнәсәбәт тәрбияләү.*
*Курай, тальян гармун һ. б. музыкаль инструментларны яңгырау тавышыннан таный белү күнекмәләре формалаштыру.*
*Татар биюләренә хас булган гади хәрәкәтләр («аяк очларында атлап йөрү», «бер аяк белән тыпырдау», «борма» (гади вариант), «култыклашып әйләнү» һ. б.) белән таныштыру. Биисе килү теләге уяту.*
*Музыканы балалар эшчәнлегенең барлык төрләрендә файдалану. Кәефкә туры килерлек һәм хис-кичерешләргә булышлык итәрлек музыка астында матур әдәбият һәм сынлы сәнгать әсәрләре кулланып, катнаш музыкаль шөгыльләр үткәрү.*
*Тәкъдим ителгән музыкаль әсәрләр*
*Музыка тыңлау*
*«Әпипә», татар халык көе, Ю. Виноградов эшкәрт.; «Көз», Р. Еникеева муз., К. Нәҗми сүз.; «Көзге яңгыр», Р. Латыйпов муз., Л. Лерон сүз.; «Марш», И. Шәмсетдинов муз.; «Сүзсез җыр», татар халык көе, А. Вәлиуллин эшкәрт.; «Песи», М. Мозаффаров муз., Ә. Ерикәй сүз.; «Шаян кыз», Н. Җиһанов муз.; «Усал малай», Р. Зарипов муз.; «Кыш бабай җыры»,*

*Л. Шиһабетдинова муз., Г. Зәйнашева сүз.; «Курчаклар маршы», Р. Еникеев муз.; «Буран», М. Мозаффаров муз., Ә. Ерикәй сүз.; «Бию», А. Вәлиуллин муз.; «Өммегөлсем», татар халык көе, Ф. Фәизова эшкәрт.; «Яз», Р. Ахиярова муз., Г. Рах-*



*манколый сүз.; «Куян биюе», «Аю», Р. Еникеев муз.; «Яңгыр», Л. Хисмәтуллина муз.; «Үҗәтлек», Р. Еникеев муз.; «Шук малай», Ә. Шәрәфиев муз.; «Ат булып уйнау», Х. Әхмәтов муз.; «Марш», А. Монасыйпов муз.; «Тамчылар бии», А. Батыршин муз., З. Нури сүз.; «Карлыгач», Р. Еникеева муз., Г. Тукай сүз.; «Бишек җыры», З. Хәбибуллин муз.; «Ялгыз бию», татар халык көе, А. Ключарёв эшкәрт.; «Каз бәбкәләре», Ә. Бакиров муз., Ә. Бикчәнтәева сүз.; «Бал корты», И. Шәмсетдинов муз., Җ. Тәрҗеманов сүз.; «Прогулка», В. Волков муз.; «Дождик», Н. Любарский муз.; «Грустный дождик», Д. Кабалевский муз.; «Плясовая», рус халык көе; «Пляска Петрушки», М. Раухвергер муз.; «Капризуля», В. Волков муз.; «Солдатский марш», Р. Шуман муз.; «Дождик и радуга», П. Прокофьев муз.; «Воробей», А. Руббах муз.; «Колыбельная», Т. Назарова муз.; «Баюбаю», М. Красев муз., М. Чарная сүз.*

*Җырлау*

*Музыкаль ишетү һәм тавыш үстерү күнегүләре: «Чәбәкчәбәк», Р. Гатина, Ф. Батыршина муз. һәм сүз.; «Сәгать», Г. Гыйләҗетдинова муз. һәм сүз.; «Су», Ф. Җәләлетдинова муз., Б. Рәхмәт сүз.; «Дәү әнигә», Н. Мөхетдинова муз., Р. Вәлиева сүз.; «Яңгыр, яу!», балалар фольклорыннан, Н. Бакиева эшкәрт.; «Кояш, чык!», балалар фольклорыннан, Р. Зарипов эшкәрт.; «Чебиләрем», Л. Шиһабетдинова муз., Җ. Дәрзаман сүз.; «Барабан», Н. Бакиева, З. Шәйхетдинова муз. һәм сүз.; «Әлли-бәлли-бәү», Ф. Җәләлетдинова муз., татар халык сүз.; «Кәккүк», Н. Бакиева, З. Шәйхетдинова муз. һәм сүз.*

*Җырлар: «Тату бармаклар», Ф. Җәләлетдинова муз., татар халык сүз.; «Бәйрәмгә барабыз», Г. Гыйләҗетдинова муз., Н. Бакиева, З. Шәйхетдинова сүз.; «Тек-тек», Т. Вафина муз., Г. Вафина сүз.; «Көз килде», Л. Шиһабетдинова муз., Ә. Ерикәй сүз.; «Бишек җыры», татар халык җыры, Р. Тимершина эшкәрт.; «Ап-ак карлар», Г. Гәрәева муз. һәм сүз.; «Чыршыкай», М. Бикбова муз. һәм сүз.; «Әнием», Ф. Җәләлетдинова*



*муз., Р. Гыйләҗева сүз.; «Әбекәй», Т. Вафина муз., татар халык сүз.; «Яз килә», Т. Вафина муз., татар халык сүз.; «Йоклыйсым килә», М. Шәмсетдинова муз., Ш. Җиһангирова сүз.; «Үзен бик чиста йөртә», Н. Зарипова муз., Җ. Тәрҗеманов сүз.; «Чебиләр», Л. Шиһабетдинова муз., М. Хөсәен сүз.; «Тукран», З. Гыйбадулла муз., Р. Хафизова сүз.; «Җиләкләр», Р. Еникеева*

муз., Л. Лерон сүз.; «Мәче, кил юышырга», Р. Еникеева муз., Н. Гайсин сүз.; «Кәккүк җыры», Н. Зарипова муз., Г. Таһирова сүз.; «Әтәчкәй», Г. Гыйләҗетдинова муз., Р. Гыйләҗева сүз.
Җыр иҗаты: «Исемең ничек?», Ф. Җәләлетдинова муз.; «Әлли-бәлли», Ф. Җәләлетдинова муз. һәм сүз.; «Тукран», Н. Бакиева муз., татар халык сүз.; «Куян», Ф. Җәләлетдинова муз. һәм сүз.; «Әтәч», Ф. Җәләлетдинова муз., Г. Лотфи сүз.; «Без уйныйбыз», Ф. Җәләлетдинова муз., татар халык сүз.; «Урманда бәйрәм», Н. Мөхетдинова муз., Р. Вәлиева сүз.
Музыкаль-ритмик хәрәкәтләр
Уен күнегүләре: «Чәбәкәй», Р. Ахиярова муз., Х. Халиков сүз.; «Йөрибез», Ф. Шәймәрданова муз.; «Күңелле», А. Монасыйпов муз.; «Марш», Л. Шиһабетдинова муз.; «Йөгердек», А. Монасыйпов муз. («Этюд»); «Куллар өчен күнегү», Л. Хисмәтуллина муз.; «Без бердәм атлыйбыз», Н. Бакиева, З. Шәйхетдинова муз. һәм сүз.; «Ай, матур гөл генә», татар халык көе, Р. Еникеева эшкәрт.; «Баскычтан – баскычка», Р. Еникеева муз.; «Бию», Җ. Фәйзи муз.; «Атта», Ф. Әхмәтов муз.; «Марш», Ә. Шәрәфиев муз.; «Кошлар оча», И. Сафин муз.; «Чәчәкләр белән күнегү», Л. Шиһабетдинова муз.; «Паровоз», Р. Ахиярова муз.; «Ладушки», Н. Римский-Корсаков муз.; «Гуляем и пляшем», М. Раухвергер муз.; «Пружинка», рус халык көе, Т. Ломова эшкәрт.; «Марш и бег», Ан. Александров муз.; «Лошадка», М. Симанский муз.; «Сапожки», рус халык көе, Т. Ломова эшкәрт.; «Топатушки», М. Раухвергер муз.; «Маленький танец», Н. Александрова муз.
Этюд-драматизацияләр: «Самолёт», Р. Зарипов муз.; «Куяннар һәм төлке», Ф. Шәймәрданова муз.; «Күк күгәрчен»,

татар халык көе, М. Мозаффаров эшкәрт.; «Аю баласы», Ә. Шәрәфиев муз.; «Мәче балалары», Р. Зарипов муз.; «Чыпчыклар», Ф. Шәймәрданова муз.; «Чебиләр зарядкасы», Л. Хәйретдинова муз., М. Фәйзуллина сүз.; «Птички летают», А. Серов муз.; «Мышки», Н. Сушен муз.; «Самолёт», Е. Тиличеева муз.; «Жуки», венгр халык көе, Л. Вишкарев эшкәрт.; «Лошадки скачут», В. Витлин муз.; «Хитрый кот», рус халык көе; «Смело идти и прятаться», И. Беркович муз. («Марш»).
Уеннар: «Аю баласы», Ф. Әбүбәкеров муз., Н. Исәнбәт сүз.; «Яңгыр», Р. Гатина, Ф. Батыршина муз. һәм сүз., Г. Гыйләҗетдинова эшкәрт.; «Туп-туп, тубыбыз», Л. Шиһабетдинова муз., Ә. Бикчәнтәева сүз.; «Качышлы», татар халык көе, Ф. Җәләлетдинова эшкәрт.; «Кар бөртекләре», Р. Гатина, Ф. Батыршина муз. һәм сүз., Г. Гыйләҗетдинова эшкәрт.; «Бу куянга ни булган?», Л. Хисмәтуллина муз., татар халык сүз.; «Качышлы уены», В. Вәлиева муз. һәм сүз.; «Курчак белән уен», Ф. Шәймәрданова муз.; «Песи һәм чыпчыклар»,

М. Әндерҗанова муз. һәм сүз.; «Аткаем», «Карусель», Р. Гатина, Ф. Батыршина муз. һәм сүз., Г. Гыйләҗетдинова эшкәрт.; «Бөҗәкләр», Т. Вафина муз., Г. Вафина сүз.; «Мячи», Т. Ломова муз.; «Игра с погремушками», рус халык көе, А. Быканов эшкәрт.; «Кошка и котята», В. Витлин муз.; «Ловишки», Й. Гайдн муз.; «Цыплята», А. Филиппенко муз., Т. Волгина сүз.; «Игра с цветными флажками», рус халык көе; «Воробышки и автомобиль», М. Раухвергер
муз.; «Солнышко и дож-
дик», М. Раухвергер муз., А. Барто сүз.

Түгәрәк уеннары һәм биюләр: «Яфрак бәйрәме», Р. Еникеева муз., Л. Лерон сүз.; «Көз белән балалар җыры», Г. Гәрәева муз. һәм сүз.; «Яфраклар белән бию», Т. Вафина муз.; «Бөтерчек», татар халык көе, Л. Шиһабетдинова эшкәрт.; «Шылтыравык», М. Бикбова муз. һәм сүз.; «Шылтыравыклар белән бию», татар халык көе, Л. Шиһабетдинова эшкәрт.; «Кыш бабай белән күмәк җыр», Ф. Шәймәрданова муз., М. Әндерҗанова сүз.; «Кар кызы, кил безгә», Ф. Шәймәрданова муз., М. Ән-



дәрҗанова сүз.; «Чыршы янында бию», Ф. Җәләлетдинова муз.; «Курчаклар белән бию», Ф. Шәймәрданова муз.; «Кыю бас», Н. Бакиева муз. һәм сүз.; «Бию», татар халык көе, Ф. Җәләлетдинова эшкәрт.; «Төсле яулыклар», татар халык көе, Р. Еникеева эшкәрт., Р. Гатина, Ф. Батыршина сүз.; «Нәниләр», Ф. Шәймәрданова муз., М. Әндерҗанова сүз.; «Дустым бар», Л. Хисмәтуллина муз. һәм сүз.; «Без җиләккә барабыз», М. Әндерҗанова муз. һәм сүз., Ф. Җәләлетдинова эшкәрт.; «Татарча бию», татар халык көе, Л. Шиһабетдинова эшкәрт.; «Кара-каршы бию», Ф. Фәизова муз.; «Болында», татар халык көе һәм сүз., Ф. Җәләлетдинова эшкәрт.; «Поезд», М. Бикбова муз., К. Кинҗебулатова сүз.; «Полянка», рус халык көе, Г. Фрид эшкәрт.; «По улице мостовой», рус халык көе, Т. Ломова эшкәрт.; «Пляска с листочками», А. Филиппенко муз., Т. Волгина сүзләре; «Потанцуем вместе», рус халык көе, Т. Ломова эшкәрт.; «Ходит Ваня», рус халык җыры, Н. Метлов эшкәрт.; «Помирились», Т. Вилькорейская муз.; «Весёлый танец», М. Сатуллина муз.

Характерлы биюләр: «Гөмбәләр биюе», Г. Гыйләҗетдинова муз. һәм сүз.; «Фонарьлар», Ф. Шәймәрданова муз. һәм сүз.; «Кар бөртекләре оча», Р. Гыйләҗева муз. һәм сүз.; «Куяннар бииләр», М. Әндерҗанова муз. һәм сүз.; «Чәчәкләр биюе», Ф. Фәизова муз.; «Воробушки», венгр халык көе; «Зайчики», Е. Тиличеева муз.; «Танец Петрушек», латыш халык полькасы; «Вышли куклы танцевать», В. Витлин муз.

Биюле уен иҗатын үстерү: «Апа белән без дуслар», Л. Шиһабетдинова муз. һәм сүз.; «Әпипә», татар халык көе,

*Р. Еникеева эшкәрт.; «Көзге вальс», Ф. Шәймәрданова муз.; «Куяннар биюе», Л. Хисмәтуллина муз.; «Кырдан килә Кыш бабай», Ф. Шәймәрданова муз., И. Салахова сүз.; «Парлы бию», татар халык көе, Л. Шиһабетдинова эшкәрт.; «Сөмбел», С. Садыйкова муз.*



## Урт анчылар төркеме

## (4 яшьтән 5 яшькә кадәр)

## Психолого-педагогик эш эчтәлеге

### Физик үсеш

### «Сәламәтлек» белем бирү өлкәсе

*«Сәламәтлек» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның сәламәтлеген саклау, аларда сәламәтлек культурасы нигезләрен формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлдерелә һәм белем бирү бурычларын билгели.*

*Балаларның физик һәм психик сәламәтлекләрен ныгыту буенча эшне; учреждение төрен һәм тибын, булган шартларны, төркем тулылыгын, балаларның сәламәтлек һәм үсеш үзенчәлекләрен, шулай ук төбәктәге климатик һәм ел фасыллары үзенчәлекләрен исәпкә алып, бала организмын чыныктыру эшен дәвам итү.*

*Шәхси гигиена процесслары турындагы күзаллауларын баету. Гигиена нормалары һәм кагыйдәләрен аңлы һәм мөстәкыйль рәвештә үтәүләренә ирешү.*

*Гади һәм чиста киенү, киемнәрне тәртипләп төрү, бүлмәдә чиста аяк киемендә йөрү күнекмәләрен үстерү.*

*Ашаганчы һәм ашагач, пычрангач, туалеттан соң кулларын мөстәкыйль рәвештә юарга, тешләрен чистартырга, ашаганнан соң авызны чайкарга, йоклар алдыннан аякларны юарга гадәтләндерү.*

*Пөхтә ашау күнекмәләрен камилләштерү: ризыкны азлап кына алу, тавышсыз гына ашау, бик кайнар ризык ашамау, коймау, савыт-сабаны дөрес файдалану.*

*Милли ризыклар һәм эчемлекләр (умач, татарча азу, казан*



*пылавы, кара җимеш һәм өрекле чәй, хуш исле чәй һ. б.) белән таныштыру.*

*Бала организмы өчен кирәк булган витаминнар турында күзаллау булдыру. Ризык кабул итү режимын үтәү, җиләк-җимеш, яшелчә, балык һәм сөт ризыкларын (кайнаган сөт, кефир, корт), ит һәм башка файдалы ашамлыкларны куллануга ихтыяҗ тәрбияләү.*

*«Сәламәтлек» һәм «авыру» төшенчәләре, халык медицинасының кайбер чаралары белән таныштыру. Бәрелгәндә, киселгәндә үз-үзеңә һәм башка балаларга элементар ярдәм*

күрсәтү, үз сәламәтлегең турында кайгырту күнекмәләре фор-
малаштыру.
### «Физик культура» белем бирү өлкәсе
«Физик культура» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда
физик культура шөгыльләренә кызыксыну һәм аңлы караш, гар-
монияле физик үсеш формалаштыру максатларын тормышка
ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.
Балаларда хәрәкәт активлыгына ихтыяҗ формалаштыру.
Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп,
татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү.
Кагыйдәләрне мөстәкыйль рәвештә үтәргә өйрәтү.
Хәрәкәтләнү тәҗрибәсен баету.
Хәрәкәтле уеннарда балаларның иҗади сәләтләрен (уен ва-
риантлары, катнаш хәрәкәтләр уйлап чыгару) үстерү.
Уен үрнәкләре
Йөрүле һәм йөгерүле уеннар: «Ябалак», «Төсле автомо-
бильләр», «Очкычлар», «Кыңгырау чәчәк», «Әбәкләшү»,
«Сиздермичә йөгереп үт», «Беренче булып бас», «Шылтыра-
выклар», «Песи һәм тычканнар», «Песи һәм кошчыклар».
Сикерүле уеннар: «Кетәклектә төлке», «Куяннар»,
«Хәйләкәр төлке», «Инеш аша сикереп чык», «Мин сикерәм,
син кул чап», «Курыкмыйм».

Шуышулы һәм үрмәләүле уеннар: «Көтүче», «Көчекләр
һәм песи балалары», «Кошлар кайту».
Ыргыту һәм тотып алу уеннары: «Ыргыт һәм тот»,
«Ераккарак ыргыт», «Божра», «Тупны сетка аша ыргыт».
Әйләнә-тирәдә ориентлашуга, игътибарлылыкка: «Үз
төсеңне тап», «Сыерчык оялары», «Көн-төн», «Үзеңә пар тап»,
«Көтүче һәм атлар», «Бүләкләр», «Үз чиләгеңне тап», «Кайда
шылтыраттылар?», «Кем тавышы?».
Татар халык уеннары: «Песием», «Яшелчәләр», «Каз-
лар-аккошлар», «Аю-бүре».
### «Куркынычсызлык» белем бирү өлкәсе
«Куркынычсызлык» белем бирү өлкәсе эчтәлеге үз тор-
мышыңның куркынычсызлыгы нигезләрен һәм экологик аң
(әйләнә-тирә дөнья куркынычсызлыгы) алшартларын форма-
лаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм бе-
лем бирү бурычларын билгели.
Тормыш куркынычсызлыгы нигезләрен формалаштыру
Балаларны балалар бакчасында көндәлек режим һәм үз-
үзләрен тотуның иң элементар кагыйдәләре белән, бүлмәдә
хәвеф-хәтәрсез йөрү кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам
итү.
Үз тормышың куркынычсызлыгы нигезләре турында бе-

*лемнәрне үзләштерү, саклык, сизгерлек хисе тәрбияләү. Кайчы, пычак, очлы предметлар белән эш итүдә, спорт инвентаре, пыяла предметлар кулланганда сак булырга күнектерү. Балаларны тормышта яңа, алар өчен гадәти булмаган очракларда, таныш булмаган кешеләр белән очрашканда үз-үзләрен дөрес тотарга өйрәтү.*



*Юлларда хәвеф-хәтәрсез йөрү тәртибе формалаштыру*

*Юл хәрәкәтендә светофорның кызыл, сары, яшел төсләренең урнашу тәртибе һәм мәгънәләре белән таныштыру. Светофор сигналы буенча хәрәкәт итәргә күнектерү.*

*Балаларны юнәлешләрне (алга – артка, өскә – аска, уңга – сулга) аерырга гына түгел, шулай ук күрсәтелгән юнәлештә йөрергә, үзеңә карата теге яки бу әйбернең торышын (миннән сул якта – өй, уңда – машина, алда – җәяүлеләр, артта – велосипедчы) билгеләргә өйрәтү.*

*Чагыштырмача хәрәкәт итү тизлеген (тиз, акрын) билгеләргә, транспорт чараларының (трамвай, автобус, янгын сүндерү машинасы, ашыгыч ярдәм машинасы һ. б.ның) тавыш сигналларын аерырга, тавыш чыганагының кайда булуын сиземләргә, кирәк очракта туктарга өйрәтү. Ишетү-хәрәкәт координациясен __________үстерү.*

*Кайбер җәмәгать транспортлары (троллейбус, автобус, трамвай, поезд, самолёт, теплоход һ. б.) турында күзаллауларны баету; маршрут транспорты (автобус, троллейбус, трамвай) тукталышы урыннарын билгеләү; «Автобус яки троллейбус тукталышы»н аңлатучы билге белән таныштыру. Җәмәгать транспортына утыру һәм аннан чыгу кагыйдәләренә игътибар итү.*

*Балаларга метрополитен, тимер юл, поезд, машинист хезмәте, тимер юлда һәм тимер юл транспортында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре турында сөйләү. Тимер юл макеты белән таныштыру.*

*Урамда үз-үзеңне тотуның иң элементар кагыйдәләрен (йөгермәү, кычкырмау, тротуар кырыеннан йөрмәү һ. б.) үтәүгә ирешү. Җәяүле юлы белән, «җәяүлеләр юлы» билгесе белән таныштыру; урамны кайда һәм ничек аркылы чыгу турында, велосипедта йөрү кагыйдәләре турында аңлату.*

*Уңга һәм сулга борылышлар ясап, түгәрәк буенча, предметларны әйләнеп үтеп, өч тәгәрмәчле велосипедта йөрергә өйрәтүне дәвам итү. Үз хәрәкәтләре белән идарә итә белү,*



*тормозга басып туктата алу күнекмәләрен үстерү. Спорт мәйданчыгында иркен ориентлаша белүне камилләштерү. Транспорт чараларының охшаш һәм аермалы якларын табарга, билгеләнгән үзлекләре һәм функциональ үзенчәлекләре*

*буенча чагыштырырга һәм төркемнәргә берләштерергә
өйрәтү, алынган мәгълүматны гомумиләштерергә тырышула-
рын («Охшашны җый», «Оча, йөзә, йөри» һ. б.) хуплау.
Өлкәннәр хезмәте турындагы белемнәрен киңәйтү: трол-
лейбус (автобус) йөртүче троллейбус (автобус) йөртә; кар җый-
гыч машинаны йөртүче юлларны кардан чистарта; ЮХИДИ
инспекторы юлларда автомобильләр хәрәкәтен җайга сала
һ. б.; эш төрләре һәм эш максаты арасында бәйләнешне ачы-
кларга ярдәм итү.
Балаларның, сюжетлы-рольле уенда юлда имин йөрү ка-
гыйдәләрен чагылдыру өчен, мөстәкыйль рәвештә пред-
метлы-уенлы мохит тудыруларын, модульләргә уен мәгънәсе
бирүләрен, образлы һәм техник уенчыкларны, аларны алыш-
тыручы алмаш предметларны куллануларын хуплау.
Балаларны уен ситуацияләрендә шартлы уйдырманың мак-
сатын аңларга, коллективта уен кагыйдәләренә яраклашып эш
итәргә, игътибарлы булырга, уен персонажларының (транс-
порт йөртүчеләр, җәяүлеләр, пассажирлар һ. б.) роль буенча
хәрәкәтләрен төгәлрәк башкарырга, ишетү һәм күрү сигнал-
ларына, әйләнә-тирәдәге көтелмәгән үзгәрешләргә тиз җавап
бирергә, мөстәкыйльлек күрсәтергә һәм мәйданда ориентла-
шырга өйрәтү.
Мөстәкыйль дидактик уеннарда балаларның алган тәҗ-
рибәләрен файдалануга шартлар тудыру. Төрле характердагы
ял итү уеннары оештыру; юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү өчен
әһәмиятле ситуацияләрне эченә алган уен-мавыгулар, курчак
театры, сәхнәләштерелгән гади әсәрләр, уеннар өйрәнү.
Балаларда, шартлар буенча һәм үзләре уйлап тапканча,
шәһәр (авыл) урамнары макетын төзү теләкләрен үстерү. Ба-
лаларны объектларның пространстводагы сурәтләмәләрен –*



*озынлыкларын (биеклекләр, киңлекләрен) аера белү; деталь
һәм аның өлешләренең урынын (өстән, астан, өстенә, астына
һ. б.) билгеләүгә; объектларны (деталь һәм аның өлешләрен
һ. б.ны) анализларга өйрәтү; тимер юллар, ике яклы хәрәкәт
итү юллары, күперләр, гаражлар һ. б.төзүгә омтылышларын
үстерү.
Балаларны табигать күренешләренә, тәүлектәге үзгәреш-
ләргә һәм аларның әйләнә-тирәдә чагылышына (кич – урамда
караңгы төшә – багана башларында фонарьлар яна, машина-
лар фараларын кабыза) игътибар итәргә өйрәтү.
Юлларда куркынычсыз йөрү кагыйдәләрен өйрәнү процес-
сына кызыксыну уяту.
Экологик аң алшартларын формалаштыру
Балаларны хайваннар белән очрашканда сак булырга өй-
рәтү, агулы үсемлекләрнең үзлекләре турында кисәтү.*

***Кайбер куркыныч сыеклыклар, газсыман матдәләр, ут, зарарлы ашамлыклар турында, витаминнар, дару препаратларын күп күләмдә кабул итүнең куркынычлыгы турындагы күзаллауларын үстерү.***

***Социаль-шәхси үсеш***

***«Социальләштерү» белем бирү өлкәсе***

***«Социальләштерү» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның социаль характердагы беренчел күзаллауларын үзләштерү һәм балаларны социаль мөнәсәбәтләр системасына кертү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.***

***Туган телдә аралашырга теләкләрен хуплау; башка кешеләр белән аралашканда, аларның тәкъдимнәренә әдәпле итеп җавап бирү; төрле эшчәнлек төрләрендә өлкәннәр һәм балалар белән телдән һәм телдән булмаган бәйләнешләр урнаштыру.***



***Әйләнә-тирә, туган шәһәр (авыл), республика вакыйгалары турында әңгәмәләрне хуплау.***

***Аралашу культурасы формалаштыру (сөйләшүченең милләтенә карап, ачык йөз күрсәтеп, шул телдә исәнләшү һәм саубуллашу; үтенеч һәм тәкъдимнәр белән ягымлы итеп мөрәҗәгать итү; күрсәткән хезмәте, ярдәме, сый-хөрмәте өчен рәхмәт белдерү).***

***Балаларны ил, республиканың күренекле төп бәйрәмнәрен билгеләп үтәргә өйрәтү. Балалар учреждениесе, республика, ил тормышына баланың мөнәсәбәте, катнашы булуын аңлавына ирешү.***

***Өлкәннәр һәм яшьтәшләре (өч-дүрт бала) белән күмәк уеннарда катнашуга теләк уяту; әйләнә-тирәдәге тормыш, халыклар яшәеше темасына татар язучылары һәм шагыйрьләренең әдәби әсәрләре, мультфильмнар буенча, уен өчен катлаулы булмаган сюжетлар тәкъдим итү.***

***Уендагы иптәшләр арасында рольләрне бүлә белергә, уен өчен кирәкле өй кирәк-ярагы (көянтә-чиләкләр, казан, уклау һ. б.), милли костюм, ювелир (зәркән) бизәнү әйберләре, читекләр һ. б., милли уенчыклар, музыка уен кораллары сайларга һәм аларны рольгә туры китереп файдаланырга өйрәтү.***

***Милли киемдәге курчакларны, образлы уенчыкларны, бибабо, кулдан ясалган уенчыклар һәм кайбер сәнгатьлелек чараларын, кул хәрәкәтләре, мимика, интонация кулланып, театральләштерелгән һәм режиссёр уеннарында катлаулы булмаган сюжетлар буенча (татар халык әкиятләре буенча куелган мультфильмнардан) ситуацияләрне уйнап күрсәтү.***

***Баланың үзе, әти-әниләренең милләте турындагы күзаллавын формалаштыру. Гаилә рәсемнәрен караганда, әти-әни-***

ләре белән охшаш чалымнары булуына игътибар итү. Фотосурәттәге кешеләрнең эмоциональ халәтен билгеләргә, аларның кәефләрен гаилә тормышындагы билгеле бер вакыйга белән бәйләргә өйрәтү.

Гаилә турында һәм үзенең шул гаилә әгъзасы булуы турын-

да; гаиләнең барлык әгъзаларының һәм баланың үзенең бурычлары, мавыгулары, яллары турында; гаилә гореф-гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәренең матурлыгы һәм әһәмияте турында күзаллаулар формалаштыру. Гаилә истәлекләренә сакчыл караш тәрбияләү.

### «Хезмәт» белем бирү өлкәсе

«Хезмәт» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда хезмәткә уңай мөнәсәбәт формалаштыру максатын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Татар халык әкиятләре («Дүрт дус», «Алтын бөртекләр» һ. б.) ярдәмендә хезмәт эшчәнлеге турында күзаллаулар формалаштыру. Баланың эш барышын татар шагыйрьләренең хезмәт турындагы шигырьләре белән бәйләү (Җ. Тәрҗеманов. «Таякка атланып», Ш. Маннур. «Күгәрченнәр гөрләшә» һ. б.).

Балаларга аңлаешлы һөнәрләр (төзүче, электрик, сантехник һ. б.) белән таныштыруны дәвам итү. Өлкәннәрнең хезмәт эшчәнлегенең мәгънәсе турында күзаллаулар формалаштыру.

## Танып белү-сөйләм үсеше

### «Танып белү» белем бирү өлкәсе

«Танып белү» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда танып белү ихтыяҗларын һәм акылны үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Баланы үзе яши торган урам, шәһәр (авыл), республика исемнәрен әйтергә өйрәтү. Шәһәрнең (авылның) истәлекле урыннары турында сөйләү.

Туган шәһәрдә (авылда) булган вакыйгалар турында әңгәмәләрдә ешрак катнашу тәҗрибәсе туплауларына ирешү. Туган як образлары белән бәйле буклетлар, журналлар, рәсемле китаплар, альбомнар, истәлекле урыннарда гаилә белән төшкән

фотосурәтләр, значоклар, открыткалар җыелмасы тупларга теләк тудыру.

Кеше яши торган торак төзелеше (шәһәрдә һәм авылда), йорт кирәк-яраклары турында күзаллаулар булдыру. Кеше кулы белән ясалган җайланмаларның төзелеше һәм билгеләнеше турында сораулар бирергә, һәр яңалык белән танышырга омтылыш тәрбияләү.

Кешенең хуҗалык эшчәнлеген – үзе, тору урыны, йорт хайваннары һәм үсемлекләр, ишегалдының, урамының

чисталыгын – кайгыртуы турында беренчел күзаллаулар формалаштыру. Шәһәр (авыл) урамнарын, торак йортларны тәртиптә тотарга теләк тудыру.

Бирелгән урынның кайбер үсемлекләре: агачлар (нарат, өрәңге), бүлмә гөлләре (бальзамин, фуксия), гөмбәләр (ак гөмбә, майлы гөмбә, баллы гөмбә), җимешләр (алма, слива), яшелчәләр (кыяр, помидор, суган, кишер, шалкан), җиләкләр (кура җиләге, миләш, чия, карлыган) белән таныштыруны дәвам итү. Өлкәннәргә җиләк-җимеш, яшелчәләр уңышын җыярга булышу теләге тудыру.

Бөҗәкләр (кырмыска, умарта корты, коңгыз, шөпшә) турындагы күзаллауларын баету; кыргый һәм йорт хайваннары, төркемдәге табигать почмагында яшәүчеләр белән танышуны дәвам итү. Балалар бакчасындагы участокка очып килүче кошларны (чыпчык, кызылтүш, песнәкне) күзәтү оештыру, аларны ел буена өстәмә ашатырга теләк уяту.

Балаларның кырда, урманда, елгада күргәннәрен сөйли алуларына ирешү. Үзләренә ошаган үсемлек, хайван, табигать почмагының рәсемен ясарга, фотога төшерергә омтылыш тәрбияләү.

### «Аралашу» белем бирү өлкәсе

«Аралашу» белем бирү өлкәсе эчтәлеге әйләнә-тирәдәге кешеләрнең үзара мөгамәләсенең конструктив ысул һәм ча-



раларын үзләштерү максатын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Балада рус теленә карата кызыксыну уяту. Уен ситуацияләре, мәгълүмати-аралашу технологияләре куллану, балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен (уен, аралашу, нәтиҗәле эшчәнлек төрләрен) оештыру аша сөйләмне аңлау һәм башка телдә сөйләшәсе килү теләге уяту.

Рус телендә беренчел аралашуны үзләштерү өчен шартлар булдыру.

Авазларны дөрес әйтү, сәнгатьле сөйләм нигезләрен формалаштыру.

### «Матур әдәбият уку» белем бирү өлкәсе

«Матур әдәбият уку» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда китап укуга кызыксыну һәм ихтыяҗ формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Әдәби әсәрләрнең төрле жанр һәм тематикасын – халык әкияте, татар язучылары һәм шагыйрьләренең хикәя, шигырьләрен, шигъри фольклорның кече формаларын тыңлау, аларның эчтәлегенә хисләрен белдерү сәләтен үстерү.

Әкият геройлары һәм аларның характерлары, чынбарлыкта

булган хәлләр, балалар һәм өлкәннәр эшләгән эшләр турындагы күзаллаулар ярдәмендә баланың эчке дөньясын баету, укыганны аңлар өчен сораулар бирү һәм фикер алышу.
Тәрбияче ярдәмендә татар әкиятләреннән өзекләрне сәхнәләштерергә өйрәтү.
Укыган әсәрдән аеруча кызыклы, сәнгатьле өзекләрне кабатлаганда, балаларга сүзләрне һәм катлаулы булмаган фразаларны әйтеп бетерергә мөмкинлек бирү.
Кечкенә күләмле шигырьләрне, шигъри фольклорның кече формаларын яттан сөйләүләрен хуплау.

Уен һәм сәнгать эшчәнлекләрен, конструкцияләү һ. б. ны әдәби образлар белән баету.

Тәкъдим ителә торган әсәрләр

Балаларга уку өчен

Җырлар, такмаклар, мавыктыргычлар, эндәшләр, бармак уеннары: «Кояшкаем, чык, чык...»; «Кәк-күк, кәк-күк...»; «Әтисенә ай кебек...»; «Бас, кызым, эзенә...»; «Баш бармак, балан ияк...»; «Чума үрдәк, чума каз…»; «Әй чулпысы, чулпысы…»; «Болыт, болыт, килмә син…»; «Әби коймак пешерә»; «Ай диләр, вай диләр…»; «Карга килер – казан асар…»; «Ябалак, ябалак…»; «Камка түти, оч, оч...».
Әкиятләр: Татар халык әкиятләре: «Ата каз», «Ике ялкау», «Ябалак», «Балыкчы аю», «Тавык, Тычкан һәм Көртлек», «Карт белән Төлке», «Торна белән Төлке»; рус халык әкияте «Йомры күмәч»; мари халык әкияте «Төлке белән Аю»; венгр халык әкияте «Комсызлык бәласе»; болгар халык әкияте «Тавык белән Сарык», Р. Гариф тәрҗемәсе; Корея халкы әкияте «Конфет ашап тамак туямы?», Р. Вәлиев тәрҗемәсе; чукот халык әкияте «Бөдрә чәчле кыз», Р. Вәлиев тәрҗемәсе; филиппин халык әкияте «Күбәләкләр ничек килеп чыккан?»; тибет халык әкияте «Әтәч һәм Бөркет»; абхаз халык әкияте «Кәҗә бәтие, Бәрән һәм Бозау».
Шигърият: Г. Тукай. «Көз»; Л. Лерон. «Яфрак бәйрәме», «Светофор – тәмле тамак?!»; М. Хөсәен. «Пескәем»; Я. Игәнәй. «Чебиләр сөенделәр»; Б. Рәхмәт. «Бакчага килгәч»; З. Туфайлова. «Аның өчен оялам»; Ә. Бикчәнтәева. «Минем әнием», «Сыерчыклар»; Р. Бәшәр. «Светофор»; Р. Вәлиева. «Уяталар»; Җ. Дәрзаман. «Әбием сүзләре»; Ә. Кари. «Кыш», «Тиен», «Кошлар туйдырам»; Г. Толымбай. «Буран»; Н. Мадьяров. «Шуабыз»; Б. Рәхмәт. «Уенчыклар»; Н. Гайсин. «Гөлсия»; К. Булатова. «Солдатлар»; Р. Миңнуллин. «Туган илнең улы мин»; Р. Корбан. «Оекбаш»; Г. Тукай. «Бу кайсы вакыт?»; С. Сөләйманова. «Әниләр бәйрәме»; Ф. Кәрим. «Яз җитә»;

Н. Гайсин. «Яз килә»; Х. Халиков. «Хәерле иртә»; З. Туфай-

*лова. «Нәни ташчылар»; Ш. Галиев. «Светофорның өч сүзе»; М. Фәйзуллина. «Сыер».*

*Төрле ил язучылары һәм шагыйрьләре әсәрләре: М. Әлимбаев. «Бәләкәй көчек», Р. Миңнуллин тәрҗемәсе; С. Маршактан. «Апрель»; А. Барто. «Кишер суы», Ә. Юныс тәрҗемәсе.*

*Чәчмә әсәрләр. Әдәби әкиятләр: Хәйдәр. «Керпе туны»; Ә. Хәсәнов. «Балалар бакчасында»; Г. Гомәр. «Чуар тавык»; Р. Батулла. «Аю Әппәс»; Л. Толстой. «Зирәк чәүкә»; В. Осеева. «Начарлык»; К. Ушинский. «Хайваннар бәхәсе», «Тавык һәм үрдәк бәбкәләре»; А. Алиш. «Бикбатыр белән Биккуркак»; Ә. Бикчәнтәева. «Тәмле сүз»; З. Хөснияр. «Куян күчтәнәче, яки тешсез малай»; М. Гафури. «Әби белән оnык»; З. Гомәрова. «Уйныйсы килә»; А. Толстой. «Төлке белән Кысла», Ә. Еники тәрҗемәсе; А. Алиш. «Эшче абый»; С. Сәүбанова. «Шифалы сөт»; Р. Вәлиева. «Кыңгырау чәчәк»; Ә. Гаффар. «Койрык»; Р. Батулла. «Шапшакларны бака ялый»; Ф. Садриев. «Ботка»; В. Осеева. «Бер әби»; К. Ушинский. «Куян белән Керпе», Ш. Шириязданов тәрҗемәсе.*

*Мәсәлләр: Г. Тукай. «Җил белән Кояш»; К. Насыйри. «Комсыз эт».*

*Яттан өйрәнү өчен*

*Татар халык авыз иҗаты: «Кояш, чык, болыт кач…», «Бас, кызым, Әпипә...»; «Яңгыркаем, яу, яу!», «Ак калач»; К. Нәҗми. «Көз»; Г. Тукай. «Бу кайчак була?»; «Бу кайчак, туган?»; Җ. Тәрҗеманов. «Йомшак су, йөгерек су», «Кыш»; М. Фәйзуллина. «Кыш бабай»; Р. Вәлиева. «Яз»; Ш. Галиев. «Дәү әнигә күчтәнәч»; Ә. Рәшит. «Кояшлы ил».*

## *Нәфис-нәфасәти үсеш*

### *«Иҗади сәнгать» белем бирү өлкәсе*

*«Иҗади сәнгать» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда әйләнә-тирәдәге матурлыкка кызыксыну уятуны һәм үз-*



*үзләрен күрсәтү ихтыяҗларын канәгатьләндерүне формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.*

*Нәтиҗәле эшчәнлек төрләрен үстерү*

*Рәсем ясау*

*Балаларның игътибарын табигать матурлыгына юнәлдерү, алар белән берлектә үсемлек һәм хайваннар дөньясы объектларының форма, төс, төзелеш камиллегенә соклану.*

*Татар декоратив-гамәли сәнгате әсәрләре белән танышуны дәвам итү.*

*Балаларны «орнамент» төшенчәсе белән таныштыру. Татар орнаментында оста итеп чагылдырылган чын чәчәк-үсемлек мотивларын карау. Бизәкнең өлешләрен аера белергә өйрәтү.*

***Балаларны декоратив эшчәнлеккә тарту: өч яфрак (бер ноктадан өч тапкыр буяу), күкчәчәк, ромашка (акчәчәк), миләш, гөлҗимеш һ. б. ны ясау ысулларын күрсәтү.***

***Бер, ике яки берничә төсне кулланып, гади элементлардан торган тасма (бордюр) бизәге ясый белүне формалаштыру.***

***Чәчәкле үсемлекләргә төсләрне туры китерү кирәклегенә игътибар итү.***

***Берничә өлештән (кош, күбәләк, умарта корты фигуралары) торган предметларның формасын һәм төзелешен чагылдырырга өйрәтү.***

***Төсмерләр (зәңгәрсу, соры, алсу, шәмәхә) белән таныштыру, төсләрне тою хисен үстерү.***

***Татар декоратив-гамәли сәнгате үрнәкләре буенча күмәк эшләрне үтәүгә тарту.***

***Туган шәһәр (авыл) тормышыннан матур вакыйгаларны рәсемгә төшерергә теләк уяту. Рәсемнәрне бергәләп карау һәм нәрсә ясаганны сөйләүләренә ирешү. Иҗади активлык тудырырга булышу.***



***Әвәләү***

***Әвәләп ясау белән кызыксынуны үстерү; балчыктан (тозлы камыр, пластилин) әвәләү күнекмәсен камилләштерү.***

***Зур кисәктән кечерәк кисәкләр өзеп яки чеметеп алу, аларны бармаклар ярдәмендә түгәрәкләп тәгәрәтү, өлешләрне тоташтыру (чәчәк, гранат, миләш җимешләре); янчелгән шарның өстен шомарту, җиңел генә тарттырып, кырыйларын чеметкәләп чыгу – бөрү (гөбәдия, вак бәлеш һ. б.) күнекмәләре формалаштыру. Махсус таякчык (стека) ярдәмендә ике яки дүрт кисәккә бүлеп (бәлеш кисәкләре), килеп чыккан формаларны үзгәртергә тырышуларын хуплау.***

***Яңа форма барлыкка китерү өчен, шарның уртасын янычеп, чокыр ясау ысулын куллану. Махсус таякчыкны файдалану ысуллары белән таныштыру. Әвәләп ясалган әйберләргә шушы таякчык ярдәмендә милли бизәкләр төшерергә омтылуларын хуплау.***

***Балчык (тозлы камыр, пластилин) белән пөхтә итеп эшләргә күнектерү.***

***Әвәләп ясалган әйберләрне күмәк композициягә (тәлинкәдәге сый, чәй сервизы һ. б.) берләштерү. Уртак эш нәтиҗәсен күреп шатлану хисләре уяту. Декоратив әвәләп ясауда халык уенчыклары үрнәкләре (Шәмәрдән, Актүбә һ. б. уенчыклар) буенча иң гади образлар тудырырга теләк уяту.***

***Өстәл театрында куллану өчен, татар халык әкиятләре буенча сюжет әвәләп ясауга кызыксыну һәм теләк тудыру. Балаларда өлкәннәр белән уртак эш нәтиҗәләрен күреп шатлану хисләре уяту.***

*Кисеп ябыштыру*

*Кисеп ябыштыру сәнгатенә кызыксыну уяту, аның эчтәлеген катлауландыра һәм төрле сурәтләү мөмкинлекләрен киңәйтә бару.*

*Туры сызык буенча башта кыска, аннары озынрак тасмалар кисәргә өйрәтү. Төсле кәгазьдән киселгән тасмалардан пред-мет сурәтләргә өйрәтү. Сирень, артыш чәчәкләреннән торган*



*композиция төзү өчен, өзек-өзек аппликация техникасы белән таныштыру.*

*Чәчәкләр, җиләк-җимешләр һ. б. ны ясау өчен, квадрат-тан түгәрәкләр һәм турыпочмаклыктан оваллар кисәргә күнектерү. Бизәү максатыннан полосада, квадрат, түгәрәктә декоратив бизәкләр төшерергә өйрәтү. Ритм-тоемлау хисен уяту.*

*Бер бит кәгазьдә берничә предметны кисеп ябыштыру юлы белән (урам, шәһәр), балаларны сюжетлы аппликация төзүгә якын китерү. Пөхтә эшләү күнекмәләре булдыру.*

*Татар декоратив-гамәли сәнгатенең үрнәкләре буенча әзер формалардан (чәчәкләр, күбәләкләр, кошлар) коллектив ком-позиция төзегәндә, үзара ярдәмләшеп эшләү теләге уяту.*

*Сынлы сәнгатькә тарту*

*Халык һөнәрләре, декоратив-гамәли сәнгать предметлары белән танышканда, балаларның эстетик хис һәм тойгыларын чагылдыруларын хуплау.*

*Сынлы сәнгать музеена баруны оештыру (ата-аналар белән берлектә). Сәнгать әсәрләрен тиешенчә кабул итү, образны эз-лекле рәвештә карау, сурәткә тойгылар белән мөнәсәбәтләрен белдерү, күргәнне үз тәҗрибәләре белән чагыштыру күнек-мәләре булдыру.*

*Балаларны традицион татар костюмы (бер төстәге киң күлмәк, бәрхет камзол, матур күкрәкчә, киң адымлы чалбар, чигүле алъяпкыч, калфак, мозаикалы читек яки туфлиләр, түбәтәй һ. б.) белән таныштыру.*

*Балаларның игътибарын милли костюмда кисү, туку, чигү, ювелир (зәркән) әйберләр һәм күн мозаикасы сәнгатьләре ча-гылыш тапканына юнәлтү. Заманча киемнәрдә үткәннең эле-ментларын табарга булышу.*

*«Нәфис керамика», «рәссам», «рәссам-керамик», «чүлмәк ясау һөнәре» төшенчәләрен аңлату. Балаларга аңлаешлы формада чүлмәк ясаучыларның үзенчәлекле иҗаты турында сөйләү («зоодиңгез» керамикасы – төрле кошлар һәм хайван-*



*нар сурәтләнгән савытлар, уенчык сыбызгылар; Питрәч кера-мика кәсебе).*

*Хәзерге заман керамик рәссамы Б. А. Шубин иҗаты белән*

*таныштыру («Алтынчәч», «Шүрәле», «Су анасы» статуэт-калары, «Сабантуй» вазасы, «Татар биюе», «Утырып торучы хатын-кыз» исемле көнкүреш сюжетлары сурәтләнгән декоратив тәлинкәләр).*
*«Архитектура» (балалар бакчасы, мәктәп, библиотека, цирк, курчак театры – архитектура корылмалары) төшенчәсе белән таныштыру. Төрле биналарның охшаш һәм аермалы якларына игътибар итү, аларның өлешләрен, үзенчәлекләрен мөстәкыйль рәвештә таба белүләрен хуплау.*
*Китап, китаптагы рәсемнәр турындагы белемнәрне ныгыту. Татар язучылары һәм шагыйрьләренең китапларын саклаучы үзәк – мәктәп китапханәсе белән таныштыру. Сәнгать әсәрләренә сакчыл караш тәрбияләү.*

### *«Музыка» белем бирү өлкәсе*

*«Музыка» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис-тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.*
*Татар музыкасына карата кызыксыну уяту, аны тыңларга теләк белдерү. Аның хисле-образлы эчтәлеге турында сөйләү, кичерешләр белән бүлешү.*
*Татар композиторларының музыкаль әсәрләрен тыңлап, музыканың төп өч жанры: «җыр», «бию», «марш» төшенчәләрен бирү. Балаларның музыка характерын, настроениесен бирә белү сәләтләрен үстерү.*
*Музыка уен кораллары (курай, кубыз, тальян гармун һ. б.) һәм аларның яңгырашы белән танышуны дәвам итү. Татар җырларын дөрес, сәнгатьле итеп һәм аңлап башкарырга, сүзләрен ачык итеп әйтергә күнектерү.*

*Татар биюенә хас гади хәрәкәтләр («аяк очларында атлап йөрү», «чүгү», «аяк очларында күтәрелү», «берле бишек», «баш-үкчә», «култыклашып әйләнү», «борма» (гади вариант) һ. б.) белән таныштыруны дәвам итү.*
*Музыка характерына туры китереп, ритмлы хәрәкәтләр башкаруны формалаштыру.*
*Хәрәкәтле импровизацияләрдә музыкаль образны чагылдырырга омтылуны хуплау, балалар белән бергә гәүдәләнеш вариантларын («тәкәббер» әтәч, «кайгыртучан» тавыклар, тик-тормас чебиләр һ. б.) тикшерү, музыкаль әкият эчтәлеге һәм характерына дөресрәк туры килә торган образны сайларга булышу, һәр иҗади табышны хуплау.*
*Балалар эшчәнлегенең төрле структурасына музыка өстәү; матур әдәбият, сынлы һәм театр сәнгатьләре әсәрләрен файдаланып, кәефкә туры килерлек һәм хис-кичерешләргә ярдәм*

итәрлек музыка астында катнаш музыкаль шөгыльләр үткәрү.

Тәкъдим ителгән музыкаль әсәрләр

Музыка тыңлау

«Хәерле йокы», А. Монасыйпов муз.; «Курчаклар маршы», Н. Җиһанов муз.; «Шома бас», татар халык җыры, Р. Еникеева эшкәрт.; «Көз көне», М. Мозаффаров муз., Н. Гайсин сүз.; «Куянкай», Л. Батыр-Болгари муз., Н. Исәнбәт сүз.; «Балалар ярдәм итә», З. Хәбибуллин муз., Л. Лотфи сүз.; «Күңелле бию», А. Леман муз.; «Вальс», Н. Җиһанов муз. («Балалар өчен пьесалар» альбомыннан); «Сәгать», Ф. Әхмәтов муз.; «Бабай», Җ. Фәйзи муз.; «Безнең дәү әни», С. Сәйдәшев муз., Г. Насрый сүз.; «Әни кирәк», М. Шәмсетдинова муз., Р. Миңнуллин сүз.; «Авыру куян», Р. Ахиярова муз.; «Куян биюе», Р. Еникеев муз.; «Яз килгән», Л. Батыр-Болгари муз., Н. Яхина сүз.; «Ләйсән яңгыр», И. Байтирәк муз.; «Туган тел», татар халык көе, Г. Тукай сүз., Р. Еникеева эшкәрт.; «Күбәләк», «Колын», Р. Ахиярова муз. («Балаларга фортепиано өчен пьесалар» циклыннан);



«Марш», Н. Җиһанов муз.; «Сандугач», Ә. Шәрәфиев муз.; «Сабан туе», татар халык көе, М. Садри сүз., Р. Еникеева эшкәрт.; «Ат чабышы», Л. Батыр-Болгари муз.; «Күңелле дә, моңсу да», Р. Кәлимуллин муз.; «Торналар биюе», И. Шәмсетдинов муз.; «Үпкәләгән аю баласы», И. Якупов муз.; «Как у наших у ворот», рус халык көе, Т. Ломова эшкәрт.; «Марш», С.Прокофьев муз.; «Колыбельная», А. Гречанинов муз.; «Вальс снежных хлопьев», П. Чайковский муз. («Щелкунчик» балетыннан); «Вальс-шутка», Д. Шостакович муз.; «Клоуны», Д. Кабалевский муз.; «Новая кукла», «Болезнь куклы», П. Чайковский муз. («Балалар альбомы»ннан); «Ласковая просьба», Г. Свиридов муз.; «Мамины ласки», А. Гречанинов муз.; «Смелый наездник», Р. Шуман муз. («Яшьләр өчен альбом»нан ); «Всадник», Р. Шуман муз. (фрагмент).

Җырлау

Музыкаль ишетү сәләте һәм тавыш үстерүгә күнегүләр: «Гөмбәгә», Ф. Җәләлетдинова муз. һәм сүз.; «Карга», Н. Бакиева муз., татар халык сүз.; «Буранда», Ф. Кәримуллина муз., Р. Миңнуллин сүз.; «Физзарядка», Ф. Җәләлетдинова муз., Р. Вәлиева сүз.; «Саескан», Ф. Шәймәрданова муз., Х. Гарданов сүз.; «Әтәч», Г. Гыйләҗетдинова муз., Дәрдемәнд сүз.; «Бишек җыры», татар халык көе, Р. Миңнуллин сүз.; «Курчакка күлмәк», Н. Бакиева муз., Р. Вәлиева сүз.; «Каен җиләге», Ә. Бакиров муз., Ә. Бикчәнтәева сүз.; «Аткаем», М. Әндерҗанова муз. һәм сүз.; «Цветики», В. Карасева муз., Н. Френкель сүз.; «Кто проснулся рано?», Г. Гриневич муз., С. Прокофьев сүз.; «Две тетери», рус халык сүз., М. Щеглов муз.; «Колыбельная зайчонка», В. Карасева муз., Н. Френкель

сүз.; «Кукушечка», рус халык җыры, И. Арсеев эшкәрт.
Җырлар: «Балалар бакчасында», Н. Зарипова муз.,
Н. Гайсин сүз.; «Көз килде», Л. Хисмәтуллина муз. һәм сүз.;
«Сөмбелә», Ф. Шәймәрданова муз., М. Мөэминова сүз.;
«Кыш», Ф. Җәләлетдинова муз., Җ. Тәрҗеманов сүз.; «Яңа
ел», Р. Ахиярова муз., Л. Әмирханова сүз.; «Кыш бабай»,

Ф. Әбүбәкеров муз., Р. Миңнуллин сүз.; «Песи баласы»,
Л. Хәйретдинова муз., М. Фәйзуллина сүз.; «Әниләр өчен
бию», Ф. Шәймәрданова муз. һәм сүз.; «Әбием – дәү әнием»,
Р. Гыйләҗева муз. һәм сүз.; «Тыныч йокы», Ф. Шәймәрданова
муз., Ш. Галиев сүз.; «Яз килә», Ф. Шәймәрданова муз.,
Ш. Галиев сүз.; «Сыерчык», И. Шәмсетдинов муз., Г. Лот-
фи сүз.; «Яңгыр», М. Бикбова муз. һәм сүз.; «Бу – мин»,
Л. Таһирова муз., Р. Ураксин сүз.; «Колын бара каладан»,
М. Шәмсетдинова муз., Ш. Галиев сүз.; «Яратам», Э. Зиннә-
туллина муз., З. Вәлиева сүз.; «Песи-Нечкәбил», С. Сабирова
муз. һәм сүз., Л. Хисмәтуллина эшкәрт.; «Бака», Ф. Әбүбәкеров
муз., Н. Исәнбәт сүз.; «Күлмәк юам», Р. Еникеев муз.,
Җ. Дәрзаман сүз.; «Баю-бай», М. Красин муз., М. Чёрная
сүз.; «Ёлка-ёлочка», Т. Попатенко муз., И. Черницкая сүз.;
«Кошечка», В. Витлин муз., Н. Найденова сүз.; «Мы запели
песенку», Р. Рөстәмов муз., Л. Миронова сүз.; «Подарок
маме», А. Филиппенко муз., Т. Волгина сүз.; «Воробей»,
В. Герчик муз., А. Чельцов сүз.; «Дождик», рус халык җыры,
Ю. Слонов эшкәрт.
Музыкаль-ритмик хәрәкәтләр
Уен күнегүләре: «Марш», Л. Шиһабетдинова муз.; «Аллы-
гөлле гөлчәчәк», татар халык көе, М. Мозаффаров эшкәрт.;
«Марш», Л. Хисмәтуллина муз.; «Якты таң», Җ. Фәйзи муз.,
«Сәрия», татар халык көе, Р. Еникеева эшкәрт.; «Сикерү»,
Р. Кәлимуллин муз.; «Марш»,Ф. Фәизова муз.; «Аю»,
Р. Еникеев муз.; «Әйлән-бәйлән», татар халык көе; «Йомшак
куллар», Р. Гыйләҗева муз.; «Марш», М. Салихов муз.;
«Полька», И. Якубов муз.; «Ат», Ф. Шәймәрданова муз.;
«Түгәрәктә бию», татар халык көе; «Тыпыр-тыпыр», татар
халык көе; «Уфа-Чиләбе», татар халык көе, Л. Шиһабетдинова
эшкәрт.; «Төймә», татар халык көе, Ә. Фәттах эшкәрт.; «Гөрләп
үсәбез», М. Мозаффаров муз., Ә. Ерикәй сүз.; «Әтәчкәем»,
И. Шәмсетдинов муз.; «Курчак», татар халык көе, Ш. Мона-
сыйпов эшкәрт.; «Чәчәкләр белән күнегү», Р. Еникеев муз.

(«Вальс»); «Ах вы, сени мои, сени», рус халык җыры,
М. Раухвергер эшкәрт.; «Вертушки», украин халык көе,
Я. Степовой эшкәрт.; «Весёлые мячики», М. Сатуллина муз.;
«В садике», А. Майкапар муз.; «Сапожки скачут по дорожке»,

***А. Филиппенко муз., Т. Волгина сүз.; «Маленький танец», Н. Александрова муз.; «Полька», М. Глинка муз.***

***Сәхнәләштерелгән этюдлар: «Барабанчы», З. Хәбибуллин муз.; «Кыелган яфраклар вальсы», Ф. Шәймәрданова муз.; «Яшь солдатлар без», М. Мозаффаров, З. Хәбибуллин, Р. Ахиярова муз.; «Кем саный», Р. Ахиярова муз.; «Уен», М. Мозаффаров муз.; «Санау», Л. Хәйретдинова муз.; «Тигез юл буйлап», татар халык көе, З. Ибраһимова эшкәрт.; «Шаян мәче», Ә. Шәрәфиев муз.; «Оча шарлар», Җ. Фәйзи муз., М. Мазунов сүз.; «Атлар», башкорт халык көе, Р. Сәлмәнов эшкәрт.; «Аланда», Ф. Шәймәрданова муз.; «Күбәләкләр», Л. Хисмәтуллина муз.; «Әтәч һәм тавыклар», С. Сәйдәшев муз. («Бию»); «Без урманга барабыз», татар халык җырына «җиләк җыю» күренеше; «Весёлая прогулка», П. Чайковский муз.; «Танец осенних листочков», А. Филиппенко муз., Е. Макшанцева сүз.; «Всадники», В. Витлин муз.; «Барабанщик», М. Красев муз.; «Наседка и цыплята», Т. Ломова муз.***

***Түгәрәк уеннары һәм биюләр: «Яңгыр», татар халык уен җыры; «Яфраклар белән бию», Ф. Шәймәрданова муз.; «Парлы бию», Л. Шиһабетдинова муз.; «Күңелле биибез», башкорт халык көе, А. Кобагошев эшкәрт.; «Кәрия, Зәкәрия», татар халык җыры, Р. Еникеева эшкәрт.; «Чыршы янында», И. Шәмсетдинов муз., С. Урайский сүз.; «Чыршы», Л. Хисмәтуллина муз., Ә. Ерикәй сүзләре; «Һай, Кыш бабай», И. Шәмсетдинов муз., Җ. Тәрҗеманов сүз.; «Яулыклар тотып бию», Л. Хисмәтуллина муз.; «Туган көн», М. Бикбова муз. һәм сүз.; « Күңелле бию», Ф. Фәизова муз.; «Матур уен», татар халык көе һәм сүз., Р. Сабитов эшкәрт.; «Ак калач», Р. Еникеева муз., татар халык сүз.; «Бергәләшеп биик», Р. Гыйләҗева муз. һәм сүз.; «Әйдә, биибез», Ә. Абдуллин муз.; «Бу дустың белән***



***күреш», татар халык көе һәм сүз.; «Чума үрдәк, чума каз», татар халык җыры, Р. Еникеева эшкәрт.; «Яшел бакча», татар халык җыры; «По улице мостовой», рус халык көе, Т. Ломова эшкәрт.; «Приглашение», украин халык көе, Г. Теплицкий эшкәрт.; «Пляска парами», латыш халык көе, Т. Попатенко эшкәрт.; «Весёлый Новый год», Е. Жарковский муз., М. Лаписова сүз.; «Танец около ёлки», Ю. Слонов муз., И. Михайлова сүз.; «Парный танец», Е. Тиличеева муз.***

***Характерлы биюләр: «Кар бөртекләре биюе», Л. Хисмәтуллина муз.; «Аю балалары», Р. Гыйләҗева муз. һәм сүз.; «Бәбкәләр», Ф. Шәймәрданова муз., Р. Вәлиева сүз.; «Әнкә куян һәм куяннар», А. Батыршин муз.; «Петрушкалар биюе», Л. Хисмәтуллина муз.; «Мәрҗән бөртекләре биюе», Ф. Шәймәрданова муз.; «Курочки и петушок», рус халык көе, Г. Фрид эшкәрт.; «Танец зайчат», И. Штраус муз. («Полька»); «Котята-***

*поворята», Е. Тиличеева муз., М. Ивенсен сүз.*
*Музыкаль уеннар*
*«Үз кәрзинеңне тап», Х. Вәлиуллин муз. («Вальс»); «Кайсыбыз юк?», Р. Еникеев муз. («Пьеса»); «Очкычлар», А. Монасыйпов муз., («Этюд»); «Ат тоту», Л. Шиһабетдинова муз.; «Кем беренче?», татар халык көе, Р. Сабитов эшкәрт.; «Куяннар һәм аю», Ф. Шәймәрданова, Л. Хисмәтуллина муз.; «Тычканнар», Р. Зарипов муз.; «Сыерчык оялары», М. Салихов муз. («Полька»); «Үзеңә пар тап», Р. Зарипов муз.; «Бәр шөлдерле барабанга», татар халык көе, В. Вәлиева эшкәрт.; «Весёлая карусель», рус халык көе, Е. Тиличеева эшкәрт.; «Ищи игрушку», рус халык көе, В. Агафонников эшкәрт.; «Жмурки», Ф. Флотов муз.; «Игра Дед Мороза со снежками», П. Чайковский муз. («Спящая красавица» балетыннан); «Займи домик», М. Магиденко муз.; «Лётчики, на аэродром!», М. Раухвергер муз.; «Цветные платочки», Т. Ломова муз.*
*Җырлы уеннар: «Көз», Ф. Шәймәрданова муз., С. Сабирова сүз.; «Куянкай, сорыкай», татар халык уены; «Алтын капка», Ф. Шәймәрданова муз., татар халык сүз.; «Яулык биреш»,*

*татар халык уены, В. Вәлиева эшкәрт.; «Кырдан килә Кыш бабай», Ф. Шәймәрданова муз., И. Салахова сүз.; «Куяннар һәм бүре», М. Әндерҗанова муз. һәм сүз.; «Күңелле туп», татар халык уены; «Автобуска утырдык», Л. Хисмәтуллина муз. һәм сүз.; «Тилгән», Г. Гыйләҗетдинова муз., татар халык сүз.; «Миңлебай», Р. Еникеева муз., татар халык сүз.; «Колын», Ә. Бакиров муз., Ә. Бикчәнтәева сүз.; «Җиләк җыям», татар халык уены; «Паровоз», Л. Шиһабетдинова муз., С. Әхмәтов сүз.; «Аю белән уен», Л. Хисмәтуллина муз., татар халык сүз.; «Качыш», Р. Еникеев муз.; «Оркестр», татар халык көе, Г. Гыйләҗетдинова эшкәрт.; «Ну-ка, угадай-ка», Е. Тиличеева муз., Ю. Островский сүз.; «Огородная-хороводная», Б. Можжевелов муз., А. Пассов сүз.; «Узнай по голосу», Е. Тиличеева муз., Ю. Островский сүз.; «Мы на луг ходили», А. Филиппенко муз., Т. Волгина сүз.; «Гуси, лебеди и волк», Е. Тиличеева муз., М. Булатов сүз.*
*Балалар музыка уен коралларында уйнау*
*«Тукран», татар халык көе, Д. Хәсәншин эшкәрт.; «Кура җиләк», Л. Шиһабетдинова муз., Н. Арсланова сүз.; «Бишек җыры», М. Яруллин муз.; «Поезд», Р. Гатина, Ф. Батыршина муз. һәм сүз.; «Тышта яз», Л. Шиһабетдинова муз., Ә. Ерикәй сүз.; «Кәккүк», Ф. Җәләлетдинова муз., Ә. Исхак сүз.; «Әпипә», татар халык көе, Р. Еникеева эшкәрт.; «Тыпыр-тыпыр», Н. Бакиева муз., татар халык сүз.; «Небо синее», «Андрей-воробей», Е. Тиличеева муз., М. Долинов сүз.; «Новогодняя полька», А. Александров муз.*

## Зурлар төркеме
(5 яшьтән 6 яшькә кадәр)

## Психолого-педагогик эш эчтәлеге

## Физик үсеш

### «Сәламәтлек» белем бирү өлкәсе

«Сәламәтлек» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның сәламәтлеген саклау, аларда сәламәтлек культурасы нигезләрен формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлдерелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Балаларның хоккей буенча «Ак Барс», футбол буенча «Рубин», баскетбол буенча «Уникс » спорт командалары турындагы күзаллауларын киңәйтү.

2013 елда узачак XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиадасы өчен төзелгән спорт комплексларының төрләре белән таныштыру. Балалар олимпиада хәрәкәтен хуплау.

Ярыш элементлары кергән милли уеннар («Капчык киеп йөгерү», «Көянтә-чиләк күтәреп йөгерү», «Кашыкка йомырка куеп йөгерү», «Катык», «Чүлмәк вату» һ. б.) белән таныштыру. Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнергә теләк уяту.

Сәламәт яшәү рәвешен тәшкил итүче (актив хәрәкәт, йокы, ял, дөрес туклану һ. б.) һәм сәламәтлеккә зарар китерүче факторлар турындагы күзаллауларны киңәйтү.

«Эчү режимы», «ашау режимы» төшенчәләре белән таныштыру.

Милли камыр ашлары (өчпочмак, бәлеш, бөккән, кыстыбый, кабартма), шифалы эчемлекләр (әйрән – катыктан ясалган эчемлек, сөзмә (сөзелгән катык), кымыз) белән таныштыру.



Сенсор тоемлауларга нигезләнеп, ашамлык сыйфатын билгели белү күнекмәләре формалаштыру.

Кайбер дәвалау-профилактика процедураларының тәэсире, аерым авыруларның сәбәпләре һәм аеруча киң таралганнарына профилактика чаралары турында гади күзаллаулар булдыру. Экстремаль хәлләрдә (борыннан кан киткәндә, эссе яки кояш сукканда һ. б.) беренче ярдәм күрсәтүнең гади ысулларын өйрәтү.

Авыру кешенең хәленә керә белү хисе тәрбияләү. Үз хәлен тасвирлый белергә өйрәтү. Баланың авыру кешене караүда хәленнән килгәнчә ярдәм итүен (дару, су бирү, өстенә ябу, аралашу һ. б. ны) игътибарсыз калдырмау.

### «Физик культура» белем бирү өлкәсе

«Физик культура» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда физик культура шөгыльләренә кызыксыну һәм аңлы караш, гар-

*монияле физик үсеш формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.*
*Татар халык уеннары белән таныштыру. Таныш уеннарны мөстәкыйль оештыруны, ярыш элементлары кергән уеннарда катнашуларын хуплау. Уен кагыйдәләрен үти белү күнекмәләрен үстерү. Яшьтәшләре белән уйнаганда, гадел көндәшлек культурасы тәрбияләү.*
*Хәрәкәтле уеннарда җитезлек, тизлек, сыгылмалылык, чыдамлылык кебек сыйфатларны үстерү.*
*Уен үрнәкләре*
*Йөгүле уеннар: «Әбәкләшү», «Карусель», «Почмак алыш», «Урындыкны тап», «Балалар һәм этәч», «Песи һәм тычканнар», «Шат балалар», «Төлке һәм тавыклар», «Балыклар», «Куяннар һәм төлке», «Чыпчык, чык!», «Чәчәк бәйләме», «Мин качам, син тот», «Яулык».*

*Сикерүле уеннар: «Кармак», «Бау аша сикер», «Бүре һәм куяннар», «Идәндә калма», «Күчтек», «Эздән сикерү».*
*Шуышулы һәм үрмәләүле уеннар: «Аю һәм бал кортлары», «Янгын сүндерүчеләр», «Кем беренче?».*
*Тупны ыргыту уеннары: «Аучылар һәм куяннар», «Кыршау эченә ыргыт», «Тупны ыргыт», «Кегляны аудар», «Туп мәктәбе», «Серсо».*
*Эстафеталар. Ярыш элементлары белән: «Кем тизрәк?», «Флаг янына», «Кем биеккәрәк?», «Парлы эстафета», «Каршылыклар юлы», «Кем беренче?».*
*Татар халык уеннары: «Кемдә йөзек?», «Ак, димә, кара, димә», «Буяучы һәм буяулар», «Очтылар, очтылар...».*
*«Куркынычсызлык» белем бирү өлкәсе*
*«Куркынычсызлык» белем бирү өлкәсе эчтәлеге үз тормышының куркынычсызлыгы нигезләрен һәм экологик аң (әйләнә-тирә дөнья куркынычсызлыгы) алшартларын формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.*
*Тормыш куркынычсызлыгы нигезләрен формалаштыру*
*Балаларда мөстәкыйльлек, җаваплылык хисе үстерү; тормыш һәм сәламәтлекләрен саклау өчен, үз-үзеңне дөрес тотуның әһәмиятен аңлауларына ирешү.*
*Таныш булмаган кешеләр белән мөмкин булган һәм очраклы очрашулар һәм аралашу барышында балаларда үзләрен ничек тотарга кирәклеге турында ачык күзаллау булдыру. Таныш булмаган кеше белән үзең генә калу һич тә ярамавына һәм куркынычлыгына игътибарларын юнәлтеп, балалар белән шундый очраклы очрашулар вакытында килеп чыккан хәлләрне бергәләп карау һәм фикер алышу.*

***Юлларда хәвеф-хәтәрсез йөрү***
***тәртибе формалаштыру***
***Хәрәкәт юнәлешен (сүзле яки җаваплы) сигнал буенча алыштырып, «үзеңнән» һәм «үзеңә таба», бирелгән юнәлештә хәрәкәт итү; бер урыннан икенче урынга мөмкин булган күчешләр турында килешеп, әйләнә-тирәне үзләштерү; уен барышында объекттан (хәрәкәт итүче машина, поезд) хәрәкәт чагыштырмалылыгын билгеләргә өйрәтү.***
***Әйләнә-тирәдәге предметларның бер-берсенә карата булган урыннарын мөстәкыйль ачыклый белүләренәирешү: өстенә – өстендә, буенча – астында, сулда – уңда, артында – алдында, янында, янәшәсендә, арасында, уртасында, өстәрәк – астарак. Тирә-юньдәге кешеләр һәм предметлар арасында үзеңнең торган урыныңны билгеләү күнекмәләре үстерү.***
***Светофорның төсләрен (ике яклы, җәяүле өчен), «Балалар», «Хәрәкәт тыела», «Җәяүлеләрнең хәрәкәте тыела», «Велосипедлар хәрәкәт итү тыела», «Велосипед юлы», «Хастаханә» һ. б. юл хәрәкәте билгеләренең зурлыгын, төсен һәм формасын, регулировщик таягының төсен ачыклау нигезендә, сенсор сиземләү күнекмәләре формалаштыру.***
***Балаларга югары куркынычлык зоналары турында сөйләү. «Тайгак юл», «Куркыныч борылыш», «Юл эшләре», «Кыргый хайваннар», «Шлагбаумлы тимер юл чаты» һ. б. кисәтүче юл билгеләре белән таныштыру, аларның охшаш һәм аермалы якларына игътибар итү.***
***Балаларны берничә полосалы хәрәкәт булган юлны чыгу алгоритмы белән таныштыру; юлларда, юл аркылы чыкканда, тәртипкә салына торган урам чатларын чыкканда ориентлашырга күнектерү. Балаларны «юл билгесе» төшенчәсе, юл чатларында җәяүлеләр хәрәкәтен тәртипкә сала торган «Җәяүлеләрнең җир асты юлы», «Җәяүлеләрнең җир өсте юлы» билгеләре белән таныштыру.***
***Хәрәкәтне сигналлар ярдәмендә җайга салучы ЮХИДИ***

***инспекторы эшчәнлеге белән таныштыру, җәмгыять өчен аның хезмәтенең әһәмиятлелеген бәяләү күнекмәләре үстерү.***
***Балаларның махсус транспорт чаралары билгеләнеше («ашыгыч ярдәм» машинасы, «полиция» машинасы, «янгын сүндерү» машинасы һ. б.) турындагы белемнәрен ачыклау; сигнал тавышларына игътибар итәргә, аларны аера белергә өйрәтү; кайбер аерым очракларда махсус транспорт чараларының юл йөрү кагыйдәләрен бозу мөмкинлегенә игътибар иттерү.***
***Метрода: вагонда (ишекләргә сөялмәү, чыгарга алдан әзерләнү), станциядә (бер юнәлештә хәрәкәт итү, тыелган***

сызыкка басмау), эскалаторда (уң якта басу, үз хәрәкәтеңне эскалатор хәрәкәтенә яраклаштырып керергә һәм чыгарга әзерләнү); турникетлар аша үткәндә үз-үзеңне куркынычсыз тоту кагыйдәләре белән таныштыру.

Метрода, юлларда, шәһәр (авыл) урамнарында үз-үзеңне куркынычсыз тотуның мөһимлеген аңларга ярдәм итү; әхлакый аралашу үрнәкләре («рәхмәт», «рәхмәтлемен сезгә», «гафу итегез», «рәхимле булыгыз», «мөмкин булмасмы» һ. б.) биреп, гади этикет кагыйдәләрен үзләштерергә булышу.

Җәмәгать урыннарында үз кыланышыңны һәм башка кешеләрнең үз-үзләрен тотышын күзәтү, чагыштыру, каршы кую, бәяли белү күнекмәләрен үстерү; балаларның юлларда үз-үзеңне куркынычсыз тоту кагыйдәләрен үтәмәгән очракта килеп чыккан күңелсез хәлләрне, аларның башка кешеләрнең эмоциональ халәтенә йогынтысын аңлауларына ирешү.

Үзең яшәгән җирлектә транспорт чараларының төрлелегендә ориентлашу күнекмәләрен үстерү: өйдән балалар бакчасына кадәр, үзәк мәйданга һ. б. җирләргә кадәр нинди маршрут автобусы белән барырга мөмкин, әти-әниләр нинди транспорттан файдалана һ. б.

Балаларны машинада утырып йөрү кагыйдәләре белән таныштыру: балалар урындыгында (креслосында) утыру һәм каеш белән эләктереп кую, машина йөртүченең игътибарын

читкә юнәлдермәү, тәрәзәдән башны чыгармау, үзең белән очлы предметлар алмау; үз хәрәкәтләреңне контрольдә тотарга өйрәнү.

Баланы үз фамилиясен, тулы исемен, яшен әйтергә өйрәтү. Тору урынының адресын, телефонын, якындагы тукталыш исемен әйтү һәм полиция хезмәткәренә ярдәм сорап эндәшү күнекмәләрен булдыру.

Уңга һәм сулга борылышлар ясап, түгәрәк буйлап, елансымак, ике яки өч тәгәрмәчле велосипедта йөрергә өйрәнүне дәвам итү; үз хәрәкәтләрең белән идарә итә белергә, велосипедта, самокатта йөрү урыннарын билгеләргә өйрәтү.

Балаларның хәрәкәтле уеннар, спорт һәм эстафета уеннары («Каршылыклы юл», «Күңелле ярышлар» һ. б.) оештыру инициативасын хуплау.

Балаларга таныш булган юл билгеләрен, урам чатлары, тукталышлар, ике яклы хәрәкәт, төрле билгеләнештәге транспорт хәрәкәтен файдаланып, җәяүлеләр һәм пассажирлар булып уйнарга мөмкинлекләр бирә торган уен ситуацияләре тудыру һәм юл йөрү кагыйдәләрен үзләштерү өстендә эшләү.

Танып белү бурычларын үтәгәндә модельләштерү ысулын куллану: күләм һәм киңлек бәйләнешләрен билгеләү («Бүлмә буйлап сәяхәт», «Бала кая киткән?» һ. б.).

*Чынбарлыкта булган, вербаль һәм вербаль булмаган уй-
лап чыгаруларга таянып, эчке программалаштыруның гади
операцияләренә өйрәтү: ситуацияләрне уйнап күрсәтү, про-
странствода биналарның, транспорт чараларының, җәяүлеләр,
юл билгеләренең урнашу макетын һәм моделен ясау
күнекмәләре формалаштыру.*
*Алынган мәгълүматны (су, җир өсте, тимер юл, һава,
җигүле транспорт) гомумиләштерергә һәм аны мөстәкыйль
эшчәнлектә файдалана белергә өйрәтү («Нәрсә артык?», «Ав-
тоюллар лотосы», «Юл доминосы» һ. б.).*
*Балаларның проблемалы характердагы сораулар бирүләрен
хуплау, укыганнары буенча фикер алышуга теләк тудыру*

*(«Светофор эшләмәсә, нәрсә булырга мөмкин?», «Әгәр туп
транспорт йөри торган юлга тәгәрәп чыкса, нишләргә?» һ. б.).*
*Балаларны проблемалы ситуацияләрне чишәргә генә түгел,
ә бәлки үз фикерләрен әйтеп бирергә өйрәтү.*
*Юлларда үз-үзеңне куркынычсыз тоту кагыйдәләренең
кайберләрен ныгыту максатыннан, уйлап чыгарган әкият-
ләрдән, тормыш тәҗрибәләреннән алынган хикәяләр,
шигырьләрдән, үзләре ясаган рәсемнәрдән (аппликацияләр-
дән) китап-җыентык төзүләрен хуплау.*
*Мәгълүматны мөстәкыйль рәвештә эзләп табарга мөм-
кинлек бирү.*
*Экологик аң алшартларын формалаштыру*
*Табигатьтә үз-үзеңне тоту культурасын формалаштыруны
дәвам итү. Туган як табигате өчен куркыныч булган кайбер чы-
ганаклар турында сөйләү (агачларны кисү, урман янгыннары,
көчле салкыннар, сулыкларны пычрату һ. б.).*
*Табигать белән кешенең үзара бәйләнеше, әйләнә-тирәнең
кешенең сәламәтлегенә йогынтысы турында күзаллаулар бул-
дыру.*
*Балаларны хуҗасыз хайваннар белән очрашканда мөмкин
булган куркыныч хәлләр турында искәртү.*

## Социаль-шәхси үсеш

### «Социальләштерү» белем бирү өлкәсе

*«Социальләштерү» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның
социаль характердагы беренчел күзаллауларын үзләштерү
һәм балаларны социаль мөнәсәбәтләр системасына кертү
максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү
бурычларын билгели.*
*Балалар бакчасында балаларның (кечкенәләр, үзеннән
зурраклар, яшьтәшләре, малайлар-кызлар, төркемгә килгән*

*«яңа» балалар белән) туган телдә аралаша белү күнекмәләрен*

үстерү.
Төрле эшчәнлек төрләрендә балаларга туган телдә үзара
һәм өлкәннәр белән бай, эчтәлекле аралашу өчен шартлар ту-
дыру.
Элементар әхлак кагыйдәләренә өйрәтү, әхлак буенча
аралашу үрнәкләре бирү, сөйләмдә татар халык фольклорын
(мәкальләр, әйтемнәр, юаткычлар һ. б.) куллануга теләк уяту.
Бөтен кешелек өчен уртак байлык булган патриотизм
хисләренең әхлакый нигезен булдыру өчен шартлар тудыру
(гаиләсенә, балалар бакчасына, туган ягына, иленә, әйләнә-
тирәдәгеләргә мәхәббәт).
Гаиләң һәм аның тарихы турындагы күзаллауларны
тирәнәйтү. Гаилә составы, туганнар (әти-әни, әби-бабай,
абый-эне, апа-сеңел, туганнан туган абый-апалар), гаиләдәге
урыны, туганлык җепләре һәм гаилә эчендә бәйләнешләр
(«Мин әтигә – ул, ә әбигә – оньк», «Газизә апа – минем Фатый-
ма әбиемнең кызы»), әти-әниләрнең һәм туганнарның һөнәр
һәм шөгыльләре турында күзаллаулар булдыру; туганнарның
фотографияләрен карап, баланың әти-әниләре һәм башка ту-
ганнары белән тышкы охшашлыгына басым ясау.
Үзенең уңыш һәм казанышларына, әти-әниләренең,
якын кешеләренең, дусларының, Олимпия уеннары спорт-
чыларының, артистларның халыкара конкурсларда яула-
ган уңыш һәм казанышларына шатлык, горурлык хисләре
тәрбияләү.
Сюжетлы-рольле уеннар өчен темалар төрлелеген хуп-
лау; әйләнә-тирәдән, татар язучылары һәм шагыйрьләре-
нең әсәрләреннән, телетапшырулардан, шәһәр (авыл) буенча
экскурсияләрдән, күргәзмәләрдән, походлардан алган бе-
лемнәргә нигезләнеп, сюжет үсешенә ярдәм итү.
Балаларның шартлы формада милли уенчыкларны, кул-
дан ясалган уенчыкларны файдаланган; тормышта бул-
ган хәлләрне, Идел буе халыклары әкиятләре сюжетларын,

мультфильмнарны һ. б.ны чагылдырган шәхси һәм күмәк ре-
жиссёрлык уеннарына булышлык күрсәтү.
Балаларның артистлык сәләтләрен үстерү, аларны сәхнә
сәнгатенә тарту: концертлар кую, татар җырларын җырлау,
Идел буе халыклары биюләрен башкару, спектакльләрдән
күренешләр күрсәтү. Яшьтәшләре, әти-әниләр һәм кунаклар ал-
дында чыгыш ясарга мөмкинлекләр булдыру.
Инициативалылыкны, халык уеннары кагыйдәләрен үтәү-
не, тигез хокуклы партнёр позициясен ала белүне хуплау.
«Хезмәт» белем бирү өлкәсе
«Хезмәт» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда хезмәткә

*уңай мөнәсәбәт формалаштыру максатын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.*

*Татар халык әкиятләре («Өч кыз», «Үги кыз», «Һөнәрле үлмәс» һ. б.) ярдәмендә хезмәт эшчәнлеге турында күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү. Балаларның игътибарын әкияттә хезмәт итүче геройларга юнәлдерү. Балаларның эш барышларын Г. Тукай шигырьләрендәге («Кызыклы шәкерт», «Шаян песи» һ. б.) юллар белән бәйләү.*

*Туган шәһәрдәге (авылдагы) укытучы, нефтьче, сыер савучы һ. б. һөнәр ияләре турында күзаллауларын формалаштыру.*

*Балалар бакчасы участогында тәрбияче белән эшләгәндә, балаларның актив катнашуын булдыру: яфраклар коелгач, кулларыннан килгәнчә участокны җыештыру, шәһәрдә яшәүче кошларга өстәмә азык бирү.*

*Гаилә бәйрәмнәренә әзерләнгәндә, өлкәннәргә кулларыннан килгәнчә булышу, өйдә үз вазифаларын үтәүгә тарту.*



## *Танып белү-сөйләм үсеше*

## *«Танып белү» белем бирү өлкәсе*

*«Танып белү» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда танып белү ихтыяҗларын һәм акылны үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.*

*Татарстан – күпмилләтле республика. Казан – эре промышленность үзәге, Россиянең борынгы шәһәрләреннән берсе. Казан – республиканың һәм бөтендөнья татарларының башкаласы. Казанда Президент, Татарстан Хөкүмәте һәм шәһәр мэры эшлиләр. Шулар турында балаларда күзаллаулар булдыру.*

*Балаларга туган як турында мифлар, легендалар, тарихлар сөйләү. Туган шәһәрнең (авылның) истәлекле урыннары, бик күптәнге вакыйгалары, тарихи истәлекләре, музейлары, урамнары белән таныштыру.*

*Татарстан Республикасының төп символикасы (флаг, герб, гимн) белән таныштыру. Балаларга үз халкыңның бер өлеше булуларын аңлату.*

*Татарстан Республикасының географик урыны белән таныштыру (картада яки глобуста республиканың территориясен, Кама һәм Идел елгаларын, Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларын, Кабан күлен, тирә-як күл һәм елгаларын билгеләү).*

*Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның традицияләре, гореф-гадәтләре, йолалары белән таныштыру. Милли бәйрәмнәр (Нәүрүз бәйрәме, Корбан бәйрәме, Сабантуй, Нардуган һ. б.) турында күзаллаулар булдыру. Башка милләтләргә карата хөрмәт һәм дусларча мөнәсәбәт тәрбияләү.*

*Милли һәм бөтендөнья культураларының үткәне һәм*

бүгенгесе белән танышуга тарту. Әдәбият һәм сәнгать
өлкәсендәге күренекле эшлеклеләрнең (шагыйрьләр: Г. Ту-
кай, М. Җәлил, Р. Миңнуллин һ. б., язучылар: А. Алиш, Р. Ба-
тулла һ. б., рәссамнар: Х. Якупов, Х. Казаков һ. б., скульптор

Б. Урманче һ. б.) тормыш һәм иҗатлары белән таныштыру.
Аларның тормышлары һәм эшчәнлекләренә карата кызыксы-
ну уяту.

Балаларның кызыксынуларын исәпкә алып, туган як таби-
гате турындагы белемнәрен киңәйтү.

Кешеләрнең табигатьне саклау буенча эшчәнлеге белән та-
ныштыру. Идел-Кама дәүләт тыюлыгы, «Түбән Кама» милли
паркы, республиканың табигатен саклауда аларның әһәмияте
турында сөйләү.

Тере һәм тере булмаган табигатькә сакчыл караш тәрбия-
ләү, табигатьтә үзеңнең катнашыңнан соң туган уңай һәм
тискәре нәтиҗәләрне алдан күрә белергә өйрәтү, туган як
табигатенә үз ихтыяҗыңны канәгатьләндерү өчен дип ка-
рау ярамаганлыгын аңлату, аны файдалануның беренчел
күнекмәләрен булдыру («Әгәр мин һәм башка кешеләр дару
үләннәрен тамырлары белән җыйса...»).

Туган якта ешрак очрый торган үсемлек һәм хайваннарга
карата кызыксынуны үстерү. Табигать объектларын үзен-
чәлекләре буенча классларга һәм төркемнәргә бүләргә өйрәтү
(ылыслы һәм яфраклы агачлар, куаклар, үлән үсемлекләр; ур-
ман, болын, бакча үсемлекләре; урман җиләкләре, гөмбәләр,
бүлмә үсемлекләре (гөлләре); кыргый һәм йорт хайваннары,
кышлаучы һәм күчмә кошлар, балыклар, бөҗәкләр һ. б.).

Республика территориясендәге хайваннарның яшәү рә-
вешен, аларның тышкы кыяфәт үзенчәлекләрен (гәүдә өлеш-
ләре, тәне нәрсә белән капланган), хәрәкәт итү ысулларын
(шуыша, оча, йөзә), азыкларын; кайбер бөҗәкләрнең, җир-су
хайваннарының, сөйрәлүчеләрнең яшәү мохитенә яраклашу-
ларын күзәтергә өйрәтү. Хайваннарны тавышларыннан таныр-
га булышу.

Туган як табигатенең матурлыгын, аның форма, төс, исләр
байлыгын күрә һәм тоя белү күнекмәләрен үстерү.



## «Аралашу» белем бирү өлкәсе

«Аралашу» белем бирү өлкәсе эчтәлеге әйләнә-тирәдәге
кешеләрнең үзара мөгамәләсенең конструктив ысул һәм ча-
раларын үзләштерү максатын тормышка ашыруга юнәлтелә
һәм белем бирү бурычларын билгели.

Рус теленә карата, шул телдә сөйләшү, җырлау, аудиоязма-
лар тыңлау, мультфильмнар, телетапшырулар карауга кызык-

*сынуларын үстерү.*
*Уен ситуациясе, проблемалы-эзләнүле уен ситуацияләре барлыкка китереп, күрсәтмә әсбаплар, мәгълүмати-аралашу технологияләрен файдаланып, аралашу сәләтләрен үстерү.*
*Балаларны үзара кара-каршы сөйләшергә, үзләренә юнәлгән сөйләмне аңларга һәм шулай ук тиешле репликалар кулланып җавап бирергә өйрәтү.*
*Чынбарлыктагы тел мохитендә рус телен (сүзләр, әйтемнәр сайлау, фикереңне аңлап сөйләү) куллануларын хуплау.*
***«Матур әдәбият уку» белем бирү өлкәсе***
*«Матур әдәбият уку» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балада китап укуга кызыксыну һәм ихтыяҗ формалаштыру максатларын ____________тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.*
*Балаларны танып белү әдәбиятына һәм матур әдәбиятка, халык авыз иҗатына тарту, әдәби кичерешләр байлыгын формалаштыру.*
*Китапның белем чыганагы икәнлегенә төшендерү. Китапка сакчыл караш тәрбияләү, мөстәкыйль рәвештә китапның рәсемнәрен карарга, эчтәлеген яңадан тыңларга теләк уяту.*
*Зур булмаган проза текстларының эчтәлеген ачып бирә белергә һәм кечкенәрәк шигырьләрне сәнгатьле итеп ят-*

*тан сөйләргә, текстларны рольләргә бүлеп укуда, әсәрләрне сәхнәләштерүдә катнашырга өйрәтү.*
*Татар халык мәкаль-әйтемнәре белән таныштыру, аларның мәгънәләрен аңларга ярдәм итү. Балаларның иҗат чагылышлары, иҗат итү башлангычлары өчен (күрсәтмә материалга нигезләнелгән такмазалар, юаткычлар, хикәяләр) шартлар тудыру.*
*Балаларга әкиятләрнең (шулай ук татар халык әкиятләренең) жанр үзенчәлекләрен аңлатуны дәвам итү. Әкият геройларының эш-гамәлләренә бәя бирергә теләк уяту, аларның үз-үзен тотышларындагы яшерен мотивларны аңларга булышу.*
*Тәкъдим ителә торган әсәрләр*
*Балаларга уку өчен*
*Җырлар, такмаклар, тел көрмәкләндергечләр, эндәшләр, әйтешләр, бармак уеннары: «Түбәтәеңне кигәнсең…»; «Исәнмесез, саумысыз...»; «Бака, бака, бакырган...»; «Мич башында биш мәче...»; «Без уйныйбыз, уйныйбыз…»; «Ямьле бәйрәм көн иде…»; «Барыр идем урманга…»; «Карга килде – казан асты…»; «Саескан сары май китерә…»; «Тамчы, там…»; «Миңлебай»; «Абагага бага-бага…»; «Әйт әле, чикерткә…»;*

*«Тор-тор, торналар…»; «Карга әйтә...»; «Торыгыз, тор, хуҗалар…»; «Яңгыр ява, томан төшә…».*
*Әкиятләр һәм легендалар: Татар халык әкиятләре: «Кем көчле?»; «Батыр әтәч»; «Күгәрченнәр ни өчен гөрләшеп яшиләр, яки гөрләмеш уены каян килеп чыккан?»; «Куркак юлдаш»; «Ике кыз»; «Ни өчен Эт белән Песи бер-берсенә дошман булганнар?»; «Өч кыз»; «Шүрәле»; Литва халкы әкияте «Итагатьле Мәче»; болгар халык әкияте «Бүре аларны нигә ашаган?»; украин халык әкияте «Башак»; башкорт халык әкияте «Карга ни өчен исемен әйтеп бетерми?»; калмык халык әкияте «Күңелле Чыпчык белән Күңелсез Карга»; болгар халык әкияте «Хәйләкәр әтәч».*

*Әдәби әкиятләр: Г. Тукай. «Шүрәле» (өзек); С. Сәүбәнова. «Мактанчык алма», «Керпе»; Р. Батулла. «Әбү булган аягы»; И. Дәүләтша. «Алпамыш шәһәргә килде»; Ә. Гаффар. «Суалчан кунакка бара»; А. Алиш. «Каз белән Аккош»; Р. Вәлиева. «Ялкау Карга баласы».*
*Шигърият: Х. Халиков. «Көз»; Р. Вәлиева. «Без игенчеләр булдык»; Ф. Яруллин. «Көзге табын»; Ш. Галиев. «Кунаклар»; Ә. Рәшит. «Банан тәмле буламы?»; Э. Шәрифуллина. «Шофёр буласым килә»; Г. Латыйп. «Кар яуды»; Г. Лотфи. «Балалар ярдәм итә»; Х. Шабанов. «Кадерлә син китапны»; Э. Шәрифуллина. «Яшел чыршы, яшь чыршы»; Ә. Кари. «Кыш бабай бүләкләре»; Г. Гыйльманов. «Ярый әле…»; Н. Исәнбәт. «Иң матур сүз»; Б. Рәхмәт. «Яз килә»; Й. Җамалетдинова. «Бүләк»; Ә. Кари. «Минем кунагым»; Г. Тукай. «Бала белән Күбәләк».*
*Төрле ил язучылары һәм шагыйрьләре әсәрләре: А. Барто. «Берүзем», Р. Вәлиева тәрҗемәсе; Н. Думбадзе. «Энә», Р. Миңнуллин тәрҗемәсе; А. Барто. «Елга», З. Мансур тәрҗемәсе; А. Тимиркаев. «Якшәмбе көн балыкта», Р. Миңнуллин тәрҗемәсе.*
*Чәчмә әсәрләр: А. Алиш. «Әбиләрдә кунакта»; Н. Фәттах. «Ирек, Алмас һәм Җәлил»; Г. Мөхәммәтшин. «Ак песи», «Велосипедлы Мөнир»; К. Ушинский. «Иртәнге нурлар», Ф. Басыйров тәрҗемәсе; К. Ушинский. «Сыер», А. Әхмәт тәрҗемәсе; Я. Тайц. «Сөт елгасы», К. Котдусова тәрҗемәсе; Р. Фәхреддин. «Ашау әдәпләре»; Г. Бакир. «Йорт салалар»; Җ. Дәрзаман. «Актырнак белән Назбикә»; М. Хәсәнов. «Көн җылынды»; Р. Мингалим. «Канатларың булса…»; З. Әхмәров. «Агачлар да авырый»; Ф. Сафин. «Кызык итте…»; Ф. Зариф. «Татлы җәй»; Ә. Хәсәнов. «Бал дәвалый».*
*Рольләргә бүлеп сөйләү өчен: Р. Вәлиева. «Керпе белән бала»; Х. Халиков. «Онытткан»; Р. Миңнуллин. «Авыл малае белән шәһәр малае…»; М. Хөсәен. «Безнең дусларыбыз».*
*Яттан өйрәнү өчен*

*М. Мазунов. «Октябрь»; М. Фәйзуллина. «Өлкән группага күчкәч»; Г. Тукай. «Безнең гаилә»; Г. Зәйнашева. «Кыш кил-*

*де»; Җ. Тәрҗеманов. «Якын дус»; Ш. Галиев. «Туган тел»; Н. Баян «Яз»; Ш. Маннур. «Кояш, чык, чык!»; Р. Корбан. «Бәйрәм бүген»; Р. Миңнуллин. «Нәүрүз»; З. Туфайлова. «Тукай абый».*

*Өстәмә ______________әдәбият*

*Шигърият: Г. Гыйльманов. «Чишмәгә бардык»; Ә. Ерикәй. «Чисталык сөябез»; В. Хәйруллина. «Шифа чәе»; Д. Гарифуллин. «Үстем»; И. Иксанова. «Иртә»; Н. Мадьяров. «Әниемә булышам»; Р. Фәйзуллин. «Миләш»; Л. Шәех. «Безнең ишегалдында»; Р. Корбан. «Ыграк авыртыр иде»; Ф. Зыятдинова. «Татарча белмәүче кәҗәләр»; Ш. Җиһангирова. «Кем хаклы?»; М. Ногман. «Кыш килде»; Р. Миңнуллин. «Почмакта торам»; Г. Зәйнашева. «Әбиемне яратам», «Сабан туе»; Г. Морат. «Туган тел»; М. Фәйзуллина. «Бал корты».*

*Чәчмә әсәрләр. Әдәби әкиятләр: Ә. Бикчәнтәева. «Өстәл янында»; Н. Кәримова. «Кое чыпчыгы»; Р. Мингалим. «Дөресе аның шулай…»; В. Монасыйпов. «Шифалы табиблар»; Г. Таһирова. «Кечкенә миләш»; Г. Мөхәммәтшин. «Гап-гади Инсаф»; Т. Әйди. «Дачада».*

*Нәфис-нәфасәти үсеш*

*«Иҗади сәнгать» белем бирү өлкәсе*

*«Иҗади сәнгать» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда әйләнә-тирәдәге матурлыкка кызыксыну уятуны һәм үзүзләрен күрсәтү ихтыяҗларын канәгатьләндерүне формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.*

*Нәтиҗәле эшчәнлек төрләрен үстерү*

*Рәсем ясау*

*Милли орнамент элементлары белән таныштыруны дәвам итү. Чәчәк-үсемлек мотивларын (кыр, болын, бакча); паль-*

*метт һәм ярымпальметт, лотоссыман, яфраклар һ. б. мотивларны карау. Балаларның игътибарын композиция үзенчәлегенә (симметрик һәм симметрик булмаган), шул ук вакытта төрле чәчәкләр мотивы кулланылган чәчәк бәйләменә юнәлтү. Балаларны декоратив эшчәнлеккә тарту: вертикаль сабакка карата бизәкнең ике ягы да бертөрле булган симметрик чәчәк бәйләмен ясау ысулын күрсәтү.*

*Декоратив рәсем буенча алган белем һәм күнекмәләрне өс, баш, аяк киемнәрендә (түбәтәй, алъяпкыч, читек һ. б.), көнкүреш әйберләрендә (сөлге, орчык һ. б.) иҗади куллануда гы милли орнамент элементларын төрләндерергә булышу.*

*Балаларны татар гамәли сәнгатенең үрнәкләре буенча кўмәк эшләр башкарырга өйрәтү. Уртак эшнең эчтәлеге буенча уртак фикергә килергә ярдәм итү.*
*Яңа төсләр (шәмәхә) һәм төсмерләр (куе шәмәхә, аксыл шәмәхә) белән таныштыру. Яңа төсмерләр табу өчен, төсләрне кушарга өйрәтү. Төсләр кушылмасын мөстәкыйль сайларга күнектерү.*
*Рәсемнәрдә көнкүреш предметларын, татар халык әкиятләре персонажларын чагылдыра белүне камилләштерү. Балаларда Г. Тукай, А. Алиш әкиятләре («Сертотмас үрдәк», «Кем көчле?», «Шүрәле», «Кәҗә белән Сарык») буенча сюжетлы композицияләр иҗат итәргә теләк тудыру.*
*Туган шәһәр (авыл) тормышында булган истәлекле вакыйгаларны рәсемдә чагылдыруларын хуплау. Рәсемнәрне балалар белән бергәләп карау һәм ясалган рәсем буенча сөйләргә теләк уяту. Балаларның иҗади активлыклары үсешенә ярдәм итү.*
*Әвәләү*
*Әвәләүгә карата кызыксыну үстерүне дәвам итү; балчыктан (камыр, пластилиннан) әвәли белүне камилләштерү. Актүбә һәм Шәмәрдән уенчыкларына карап әвәләү, аларның характерлы үзенчәлекләрен бирә белү күнекмәләрен үстерү.*

*Рельефлы сурәтләү техникасы белән таныштыру. Табигый үзенчәлекләрен исәпкә алып һәм дөрес пропорцияләр белән, тукранбаш әвәләргә өйрәтү. Әвәләүне плинтустан – нигездән башларга, шуның өстенә махсус пычак очы белән рельефның контурлы рәсемен төшерергә кирәклегенә балаларның игътибарын юнәлтү.*
*Савыт-сабаны (кувшин, ваза, чүмеч, комган һ. б.) тасма ысулы белән әвәләүне камилләштерү: бербөтен балчык кисәгеннән әвәләү, вак детальләр белән тулыландыру, махсус таякчык, штамп ярдәмендә бизәү.*
*Балаларның уйлап чыгара белүләрен, катлаулы булмаган сюжет һәм образлар («Сабантуйда», «Көянтәле кыз», «Өч кыз» һ. б.) тудырырга тырышуларын күрә белү һәм хуплау. Әдәби әсәрләр геройларын (Су анасы, Шүрәле, Камыр батыр һ. б.) күзаллап әвәләргә өйрәнү. Балаларның теләкләрен, иҗатка омтылышларын үстерү.*
*Кисеп ябыштыру*
*Аппликация сәнгатенә карата кызыксынуны үстерү, аның эчтәлеген катлауландыру һәм төрле сурәтләр тудыру мөмкинлекләрен киңәйтү. Кәгазьне гармун кебек бөкләп, милли бизәкнең бертөрле элементларын (гөлҗимеш, кукчәчәк, акчәчәк таҗларын һәм яфракларын һ. б.ны) һәм, кәгазьне урта-*

лай бөкләп, симметрик фигуралар (тукранбаш, ярымпальметт, лалә, кыңгырау чәчәкләре һ. б.) кисә белү күнекмәләрен формалаштыру. Чәчәкләр композициядә матур, ачык итеп чыксын өчен, аппликацияне кәгазьләрне ертып төзү техникасын файдалану. Төрле сурәтләү чараларын яраштыра белүләрен хуплау. Георгин (дәлия), пион, астра (кашкарый) чәчәкләреннән композиция төзү өчен, күләмле аппликация ысуллары белән таныштыру. Балаларның композицияне төрле детальләр (кошлар, бал кортлары, күбәләкләр һ. б.) белән тулыландырырга теләүләрен хуплау.

Бер бит кәгазьдә төзү һәм ябыштыру ысулы кулланып, төрле билгеләнештәге архитектура корылмаларыннан (цирк, вокзал,



супермаркет, өйләр һ. б.) торган сюжетлы аппликацияләр ясарга өйрәтү.

### Сынлы сәнгатькә тарту

Балаларны сынлы сәнгатькә якынайту һәм аңа карата кызыксыну уяту. Республика сынлы сәнгате эшлеклеләренең (Х. Якупов, И. Зарипов, Р. Шәмсетдинов һ. б.) танылган әсәрләре белән таныштыру.

Балаларны «пейзаж» төшенчәсе, Алабуга шәһәрендә туган күренекле рус пейзажчысы И. И. Шишкинның иҗаты («Иртәнге нарат урманы», «Арышлар», «Аланлык» һ. б.) белән таныштыру. Сурәткә карата хис-кичерешләрен чагылдыра белергә, аны аңлап сөйләргә, тормышларында булган вакыйгалар белән чагыштыра белергә өйрәтү.

Сәнгатьнең борынгы төре булган керамика һөнәре белән, хәзерге рәссам-керамикларның (А. Шубин, А. Абзгилдин, Р. Миргалимов, А. Миңнуллина) иҗаты белән таныштыруны дәвам итү. Балаларның игътибарын керамик эшләнмәләрнең милли үзенчәлеге силуэт формасында гына түгел, ә орнамент бизәлешендә дә чагылуга юнәлдерү. Милли орнамент элементларын аера белергә ярдәм итү.

Балаларның игътибарын рус милли костюмының үзенчәлекләренә юнәлтү, татар традицион костюмы белән (баш, өс, аяк киемнәре, бизәнү әйберләренең үзенчәлекләре) чагыштыру. Милли киемнәрдә охшаш һәм аермалы якларны табарга булышу.

Балаларны күн мозаикасы сәнгате белән таныштыру. Күн туфли, башмаклар, читекләрне; читекләрнең ал һәм балтыр өлешләрендәге бизәкләрне карау. Бер-берсенә матур туры килеп торган элементларны бөтен бер композициягә җыйган төсле фонга, кәкре сызыклы ябык формаларга, аларны капма-каршы төстәге ефәк җепләр белән тегүгә һ. б. га игътибар итү.

Балаларны туган шәһәр архитектурасы белән таныштыруны дәвам итү. Бинаның конструкциясе аның билгеләнешенә

*(торак йорт, мәчет, кинотеатр һ. б.) бәйле булганын аңлату.*

*Бер билгеләнештәге архитектура корылмаларының охшаш һәм аермалы якларына игътибар итү. Агачны кисеп бизәкләр төшерелгән иске агач өйләр, өй тирәсендәге каралты-куралар (капка, коймалар) сакланып калган Иске Татар бистәсенә (Казанның борынгы бер өлешенә) экскурсия оештыру. Кисеп ясалган бизәкләрнең үзенчәлегенә, аларның пропорция һәм төсләр чишелешенә (татар чигүенә, күн мозаикасына охшашлыкка) игътибар итү. Кремльнең архитектура ансамбле (Спас башнясы, Сөембикә манарасы, Кол Шәриф мәчете, Преображенск башнясы, Благовещенск соборы һ. б.) белән таныштыру. Тарих һәм культура объектларын аңга алу тәҗрибәсе формалаштыру. Кремль тарихын өйрәнүгә теләк уяту.*
*Китап иллюстрациясе турындагы белемнәрне ныгыту. Балаларны Р. Миңнуллин, Ш. Галиев, Р. Вәлиева һ. б.ның шигырьләренә образлар тудырган рәссам-иллюстраторларның иҗаты белән таныштыру. Бер үк әдәби әсәргә төрле рәссамнар иҗат иткән иллюстрацияләрне чагыштыра белү, аларны ничек кабул итүләре турында сөйли белү күнекмәләрен үстерү.*

### *«Музыка» белем бирү өлкәсе*

*«Музыка» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис-тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.*
*Татар композиторларының музыкаль әсәрләрен тыңлауга кызыксынуларын, аларга карата эмоциональ мөнәсәбәтләрен белдерүне хуплау. Әсәрнең аерым фрагментлары буенча көйне танулары аша музыкаль хәтерне үстерү. Музыканың характерын таный белү, әсәр турында әңгәмәдә катнашу күнекмәләрен үстерү.*
*Музыка сәнгатендәге «жанр» төшенчәсен бирү (җыр, бию, марш). Татар композиторларының кайбер музыкаль әсәрләре жанрын билгеләргә, музыка уен коралларының (думбра, ку-*

*рай, кубыз, тальян гармун һ. б.ның) яңгырашларын танырга өйрәтү.*
*Татарстан Республикасының Дәүләт гимны көе белән таныштыру, горурлык хисләре уяту.*
*Милли репертуар нигезендә балаларның җырлау күнекмәләрен камилләштерү. Җыр характерын хисләр аша күрсәтү, табигый тавыш типларын исәпкә алып җырлауларын оештыру.*
*Бию хәрәкәтләрен башкару техникасын камилләштерү; аларның катлауландырылган вариантларын: «тыпырдау», «борма», «баш-үкчә», «төп йөреш», «үкчәдә йөреш», «кырын йө-*

***реш», «бер аяктан чалыштыру», «култыклашып әйләнү» һ. б. ны өйрәнүне камилләштерү. Бию хәрәкәтләрен өйрәнгәндә, балаларның шәхси иҗади башлангычларын үстерү. Балаларны татарларның (русларның) әйлән-бәйлән уеннары, Идел буе халыкларының биюләре белән таныштыру. Бию хәрәкәтләре аша башка халыкларның музыка характерын, хис һәм образ эчтәлеген чагылдыру күнекмәләрен үстерү.***

***Тәкъдим ителгән музыкаль әсәрләр***

***Музыка тыңлау***

***«Уракчы кыз», татар халык көе, Р. Еникеева эшкәрт., Н. Исәнбәт сүз.; «Марш», Р. Еникеев муз.; «Бишек җыры», Н. Җиһанов муз.; «Гармунчы егет», «Авылда таң ату», «Көтүче малай уйный», «Авыл бәйрәме», Л. Батыр-Болгари муз. («Авыл күренешләре» циклыннан); «Марш», Л. Хәйретдинова муз. («Мәкерле песи» операсыннан); «Көзге җыр», М. Мозаффаров муз.; «Полька», З. Хәбибуллин муз.; «Кояш гомере», Ф. Әхмәдиев муз., Г. Зәйнашева сүз.; «Туган җирем Татарстан», А. Ключарёв муз., Г. Зәйнашева сүз.; «Вальс», С. Сәйдәшев муз.; «Кыш бабай белән аю русча бииләр», Р. Яхин муз.; «Клоун биюе», Ю. Виноградов муз.; «Караужа авылы көе», татар халык җыры, Р. Еникеева эшкәрт.; «Хикәя», М. Мозаффаров муз.; «Ямьле көн», «Моңлы көй», А. Монасыйпов муз. («Дүрт пьеса» циклыннан); «Язгы тамчылар», Р. Еникеев муз.***



(«Табигать күренешләре» циклыннан); «Яз», И. Шәмсетдинов муз.; «Шүрәле», А. Ключарёв муз.; «Бишек җыры», М. Яруллин муз.; «Урман күбәләге», Л. Батыр-Болгари муз.; «Иртә», Н. Җиһанов муз.; «Уйлану», И. Якубов муз.; «Куркыныч төш», А. Монасыйпов муз. («Дүрт пьеса» циклыннан); «Кунакларны каршылау», С. Сәйдәшев муз., Р. Рахмани сүз.; «Осенняя песня», П. Чайковский муз. («Времена года» циклыннан); «Игра в лошадки», «Марш деревянных солдатиков», «Баба-Яга», П. Чайковский муз. («Балалар альбомы»ннан); «Утро», «Вечер» С. Прокофьев муз. («Балалар музыкасы» җыентыгыннан); «Мамин праздник», Е. Тиличеева муз., Л. Румарчук сүз.; «Пляска птиц», Н. Римский-Корсаков муз.; «Раздумье», С. Майкапар муз.; «Тревожная минута», С. Майкапар муз. («Бирюльки» альбомыннан); «Детская полька», А. Жилинский муз.; «Марш», Д. Шостакович муз.; «Мотылёк», С. Майкапар муз.; «Музыка», Г. Струве муз.; «Жаворонок», М. Глинка муз.

***Җырлау***

*Музыкаль ишетү сәләте һәм тавыш үстерүгә күнегүләр:* «Баскыч», Н. Бакиева, З. Шәйхетдинова муз. һәм сүз.; «Саный беләм», Р. Еникеев муз., Җ. Дәрзаманов сүз.; «Кар ява», З. Ибраһимова муз., Х. Халиков сүз.; «Буран», Р. Еникеева муз., Г. Толымбай сүз.; «Песнәк», Г. Гыйләҗетдинова муз., Р. Закирова сүз.; «Яз килә», Ә. Гайсамова муз., Н. Гайсин сүз.; «Беренче яңгыр», Ә. Бакиров муз., Ә. Бикчәнтәева сүз.; «Чишмә», Р. Еникеева муз., Ә. Исхак сүз.; «Зәңгәр чәчәк», Р. Еникеева муз., Р. Фәйзуллин сүз.; «Бакчада», Ф. Җәләлетдинова муз., Х. Халиков сүз.; «Күбәләк», Р. Еникеева муз., Л. Лерон сүз.; «Үрдәк», М. Әндерҗанова муз. һәм сүз.; «Зайка», «Колыбельная», В. Карасева муз., Н. Френкель сүз.; «Андрей-воробей», рус халык җыры, Ю. Слонова эшкәрт.; «Гармошка», Е.Тиличеева муз., М. Долинов сүз.; «Паровоз», В. Карасева муз., Н. Френкель сүз.; «Барабан», Е. Тиличеева муз., Н. Найденова сүз.; «Горошина», В. Карасева муз., Н. Френкель сүз.



*Җырлар:* «Яфрак бәйрәме», Р. Еникеева муз., Л. Лерон сүз.; «Көзге яңгыр», Р. Латыйпов муз., Л. Лерон сүз.; «Балалар ярдәм итә», З. Хәбибуллин муз., Г. Лотфи сүз.; «Тауда», Р. Еникеева муз., Л. Лерон сүз.; «Кар кызы җыры», Р. Еникеев муз., Г. Зәйнашева сүз.; «Кыш бабай», Л. Шиһабетдинова муз., М. Фәйзуллина сүз.; «Солдат буласым килә», Ә. Гайсамова муз. һәм сүз.; «Әниләр бәйрәме», Ф. Шәймәрданова муз., И. Салахова сүз.; «Мияу», Ф. Шәймәрданова муз., Р. Миңнуллин сүз.; «Яз бүләге», Ә. Бакиров муз., Ә. Бикчәнтәева сүз.; «Туган тел», татар халык көе, Г. Тукай суз.; «Яз җитә», Җ. Фәйзи муз., Ф. Кәрим сүз.; «Бииләр итек, читекләр», Л. Батыр-Болгари муз., Ш. Галиев сүз.; «Яңгыр, яу!», И. Якубов муз., Р. Вәлиева сүз.; «Песи», Ф. Әбүбәкеров муз., Н. Исәнбәт сүз.; «Без үстергән гөлләр», Л. Таһирова муз., Ә. Кари сүз.; «Үсәсем килә минем», М. Имашев муз., Л. Әмирханова сүз.; «Дәү әнигә бүләккә», Н. Яхина муз. һәм сүз.; «Журавли», А. Лившица муз., М. Познанская сүз.; «Весёлая дудочка», М. Красев муз., Н. Френкель сүз.; «Сегодня мамин праздник», А. Филиппенко муз., Т. Волгина сүз.; «Весенняя песенка», А. Филиппенко муз., Г. Бойко сүз.; «Песенка друзей», В. Герчик муз., Я. Аким сүз.

*Җыр иҗаты:* «Әлли-бәлли», татар халык җыры; «Пескәем», «Биш мәче», халык авыз иҗатыннан; «Сыерчыклар», М. Укмаси сүз.; «Хайваннар авазыннан», татар халык уен җыры; «Куян, син кайда булдың?»; «Ракетада», Р. Миңнуллин сүз.; «Саный беләм», Ф. Җәләлетдинова муз., Б. Рәхмәт сүз.; балалар фольклорыннан: юаткычлар, үртәвечләр, санамышлар һәм татар халкының кыска башка җырлары.

***Музыкаль-ритмик хәрәкәтләр***

*Күнегүләр:* «Сандугач-күгәрчен», татар халык көе, М. Мозаффаров эшкәрт.; «Марш», Н. Җиһанов муз.; «Сыгылу», татар халык көе, Л. Шиһабетдинова эшкәрт.; «Бию», Ф. Җәләлетдинова муз.; «Яшь физкультурачылар», Ә. Бакиров

муз.; «Вальс», Х. Вәлиуллин муз.; «Эрбет», татар халык көе,

Б. Мулюков эшкәрт.; «Болында», Р. Ахиярова муз.; «Алтын-көмеш», «Бию», татар халык көйләре, Р. Сабитов эшкәрт.; «Шаг и бег», Ф. Надененко муз.; «Хороводная», рус халык көе, Т. Ломова эшкәрт.; «Канава», рус халык көе, Р. Рөстәмов эшкәрт.; «Плавные руки», Р. Глиэр муз. («Вальс»); «Кто лучше скачет», Т. Ломова муз.; «Учись плясать по-русски!», Л. Вишкарев муз. («Из-под дуба, из-под вяза» рус халык көенә вариацияләр).
*Предметлар белән күнегүләр:* «Уңыш бәйрәмендә», Л. Хәмиди муз.; «Әләмнәр тотып», М. Мозаффаров муз.; «Шылтыраваыклар белән күнегү», Ф. Шәймәрданова муз.; «Яулык биреш», татар халык көе («Матур булсын»); «Туплар белән күнегү», Ә. Шәрәфиев муз.; «Вальс», Р. Яхин муз.; «Вальс», Д. Кабалевский муз.; «Упражнения с цветами», А. Жилин муз. («Вальс»); «Упражнения с ленточками», украин халык көе, Р. Рөстәмов эшкәрт.
*Этюдлар:* «Лирик бию», татар халык көе; «Каз канаты», татар халык көе, А. Ключарёв эшкәрт.; «Гөлнара полькасы», Р. Халиков муз.; «Кечкенә балыкчы», Р. Зарипов муз.; «Күңелле безгә», Р. Кәлимуллин муз.; «Табигать кочагында», Р. Кәлимуллин муз.; «Тихий танец», В. Моцарт муз.; «Ау» («Игра в лесу»), Т. Ломова муз.; «Наши кони чисты», Е.Тиличеева муз.
*Биюләр:* «Авыл полькасы», И. Байтирәк муз.; «Шаян бию», Ә. Абдуллин муз.; «Парлы бию», татар халык көе, З. Хәбибуллин эшкәрт.; «Күмәк бию», татар халык көе, А. Ключарёв эшкәрт.; «Чыршы янында», И. Шәмсетдинов муз.; «Яулыклар тотып», Ф. Шәймәрданова муз.; «Күңелле бию», Л. Хисмәтуллина муз.; «Суга», татар халык көе, Р. Еникеева эшкәрт.; «Такыялар белән бию», Ф. Шәймәрданова муз.; «Гөлкәй», башкорт халык көе, А. Кобагошев эшкәрт.; «Чакыру», башкорт халык көе, А. Кобагошев эшкәрт.; «Русская пляска», рус халык көе («Во саду ли, в огороде»); «Круговая пляска», рус халык көе, С. Разоренов эшкәрт.; «Дружные пары», И. Штраус муз.; «Озорная полька», Н. Вересокина муз.; «Весёлые дети», литва халык көе, Т. Ломова эшкәрт.

*Характерлы биюләр:* «Миләшләр биюе», Л. Хисмәтуллина муз.; «Гөмбәләр биюе», Ф. Шәймәрданова муз.; «Аю баласы биюе», Н. Җиһанов муз.; «Петрушкалар биюе», Л. Шиһабетдинова муз.; «Кышкы вальс», Ф. Шәймәрданова муз.; «Пингвиннар биюе», Л. Хисмәтуллина муз.; «Чылдыр-чылдыр», А. Ключарёв муз.; «Яңгыр вальсы», М. Кәшипов муз., Р. Еникеева эшкәрт.; «Без – үрдәкләр», Л. Батыр-Болгари муз., Р. Вәлиева сүз.; «Вальс», С. Сәйдәшев муз.; «Мышки», А. Жилинский муз.; «Танец бусинок», Т. Ломова муз.; «Танец гномов», Ф. Черчел муз.; «Матрёшки», Б. Мокроусов муз.
*Түгәрәк уеннары:* «Яңгыр», татар халык җыры; «Көнбагыш», Ә. Бакиров муз., Ә. Бикчәнтәева сүз.; «Чыршы, чыршыкай», Л. Хисмәтуллина муз. һәм сүз.; «Кыш бабай», татар халык көе, Р. Еникеева эшкәрт., Ә. Кари сүз.; «Яшел чыршы», З. Хәбибуллин муз., Җ. Тәрҗеманов сүз.; «Әйдә, дустым,

биергә», В. Вәлиева муз. һәм сүз.; «Өммегөлсем», татар халык җыры; «Әйлән-бәйлән уйныйбыз», Л. Батыр-Болгари муз., Р. Батулла сүз.; «Куш кулым», татар халык уен җыры; «Түгәрәк алан», татар халык көе, Р. Сабитов эшкәрт.; «Зәңгәр чәчәк», татар халык уен җыры; «Болында», М. Әндерҗанова муз. һәм сүз.; «Урожайная», А. Филиппенко муз., Т. Волгина сүз.; «Новогодний хоровод», Т. Попатенко муз., Н. Найденова сүз.; «А я по лугу», «Земелюшка-чернозём», «Пошла млада за водой», рус халык җыры, В. Агафонников эшкәрт.

***Уеннар***

*Музыкаль уеннар:* «Ачык авыз», татар халык көе, Р. Еникеева эшкәрт.; «Буш урын», татар халык көе, Ш. Монасыйпов эшкәрт.; «Җитез бул», Р. Ахиярова муз.; «Почмак алыш», М. Әндерҗанова муз.; «Кемдә калды?», татар халык көе; «Түбәтәйле», Ф. Шәймәрданова муз.; «Шылтыравык бир», Р. Еникеев муз.; «Үзеңә пар тап», татар халык көе; «Чәчәк бәйләме», Б. Мулюков муз. («Шаян фикер»); «Оясыз кош», И. Шәмсетдинов муз. («Яз»); «Мәче һәм тычкан», Л. Шиһабетдинова муз.; «Ябалак», Р. Кәлимуллин муз. («Уен»);



«Кем юк?», С. Сәйдәшев муз. («Ямьле җәй»); «Төрле төстәге кульяулыклар», башкорт халык көе, А. Кобагошев эшкәрт.; «Чей кружок скорее соберётся?», рус халык көе, Т. Ломова эшкәрт.; «Не опоздай», рус халык көе, М. Раухвергер эшкәрт.; «Найди себе пару», латыш халык көе, Т. Попатенко эшкәрт.; «Ищи игрушку!», рус халык көе, В. Агафонников эшкәрт.; «Игра с бубном», М. Красев муз.; «Не выпустим», Т. Ломова муз.; «Передача платочка», Т. Ломова муз.; «Игра парами», удмурт халык көе; «Уступи своё место», мари халык уены.

*Җырлы уеннар:* «Диңгез сурәтләре», Ф. Шәймәрданова муз., татар халык сүз.; «Куянкай», татар халык уен җыры; «Мәче», Г. Ильина муз. һәм сүз.; «Кем беренче?», татар халык көе, Г. Гыйләҗетдинова сүз.; «Башмакчы», татар халык уены; «Атларны без яратабыз», татар халык җыры; «Мәликә», Ф. Шәймәрданова муз., татар халык сүз.; «Песи һәм тычканнар», Г. Гыйләҗетдинова муз., татар халык сүз.; «Кечкенә күл», Р. Гатина, Ф. Батыршина муз. һәм сүз., Г. Гыйләҗетдинова эшкәрт.; «Керпе белән уен», татар халык көе, Р. Вәлиева сүз., Г. Гыйләҗетдинова эшкәрт.; «Яулык салыш», татар халык көе, Р. Еникеева эшкәрт.; «Без бардык урманга», Ш. Мәҗитов муз. һәм сүз.; «Яңгыр», И. Байтирәк муз.; «Тавышымнан таны», В. Вәлиева муз. һәм сүз.; «Тирмә», башкорт халык көе, Ю. Тугаринов эшкәрт.; «Заинька», рус халык көе, Н. Римский-Корсаков эшкәрт.; «Гори, гори ясно», рус халык көе; «Две тетери», рус халык көе, В. Агафонников эшкәрт.; «Что нам нравится зимой?», Е. Тиличеева муз., Л. Некрасова сүз.; «Васька-кот», рус халык көе, Г. Лобачёв эшкәрт.; «Ворон», рус халык көе, Е.Тиличеева эшкәрт.; «Ласточка», чуваш халык уены; «Гусь плывёт», удмурт халык җыры, Г. Матвеев эшкәрт.; «Сорока», В. Алексеев муз., С. Чевайн сүз. (мари халык уены).

*Биюле уеннар:* «Мәче», татар халык көе, Р. Зарипов эшкәрт.; «Курчак», М. Бикбова муз.; «Нәни төлке», татар халык көе,

А. Монасыйпов эшкәрт.; «Шаян каз бәбкәсе», татар халык көе, Р. Еникеев эшкәрт.; «Бию», татар халык көе, Л. Шиһабетдинова

эшкәрт.; «Бүре һәм кәҗә бәтиләре», татар халык көе, А. Монасыйпов эшкәрт.; аудиоязмадагы бию көйләренә ирекле биюләр.

*Сәхнәләштерү һәм музыкаль спектакльләр:* «Күбәләк», Ф. Шәймәрданова муз., М. Әндерҗанова сүз.; «Уңыш җыйдык», Н. Лотфуллина муз., Р. Асрутдинова сүз.; «Сәгать», Ф. Әхмәтов муз., М. Җәлил сүз.; «Әтәчем, ник иртә торасың?», Л. Батыр-Болгари муз., Б. Рәхмәт сүз.; «Кем уяткан Ләйләне?», С. Сабирова муз., С. Сөләйманова сүз.; «Асия», И. Шәмсетдинов муз., Ә. Фәйзи сүз.; «Каз бәбкәләрен саклыйм», Н. Яхина муз. һәм сүз.; «Наза йөри бакчада», Р. Еникеев муз., Җ. Дәрзаман сүз.; «Урожайная», А. Филиппенко муз., Т. Волгина сүз.; «Где ты был, Иванушка?», рус халык көе, М. Иорданский эшкәрт.

***Балалар музыка уен коралларында уйнау***

«Тукран», Н. Бакиева, З. Шәйхетдинова муз., татар халык сүз.; «Гөмбә җыям», Ф. Җәләлетдинова муз., Х. Халиков сүз.; «Кояш, чык», балалар фольклорыннан, Ф. Җәләлетдинова эшкәрт.; «Бию», татар халык көе, Р. Сабитов эшкәрт.; «Бишек җыры», Л. Лерон сүз., татар халык көе, Р. Еникеева эшкәрт.; «Аткаем», М. Әндерҗанова муз. һәм сүз., Р. Зарипов эшкәрт.; «Безнең песи», Г. Гыйләҗетдинова муз., Г. Зәйнашева сүз.; «Чебиләр», Н. Бакиева муз., Р. Миңнуллин сүз.; «Кура җиләк», Л. Шиһабетдинова муз., Н. Арсланова сүз.; «Звенящий треугольник», Р. Рөстәмов муз.; «Дон-дон», рус халык җыры, Р. Рөстәмов эшкәрт.; «Гори, гори ясно», рус халык көе; «Петушок», рус халык көе, М. Красев эшкәрт.


## Мәктәпкә әзерлек төркеме
## (6 яшьтән 7 яшькә кадәр)
## Психолого-педагогик эш эчтәлеге
### Физик үсеш
### «Сәламәтлек» белем бирү өлкәсе

*«Сәламәтлек» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның сәламәтлекләрен саклау, аларда сәламәтлек культурасы нигезләрен формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм* ***белем бирү бурычларын*** *билгели.*

Балаларның физик һәм психик сәламәтлекләрен ныгыту һәм саклау. Эре, урта, вак моторика дәрәҗәсендә сенсомотор координацияне формалаштыру. Баш мие ярымшарларының үзара йогынтысы үсешенә тәэсир итүче төрле хәрәкәтләрнең актив үтәлешен булдыру. Балаларның мускулларын ныгыту, матур сынлы, төз гәүдәле булырга омтылыш формалаштыру. Максатлы прогулкаларда, шәһәр (авыл) буенча экскурсияләрдә катнашу ярдәмендә, балаларда оптималь хәрәкәт активлыгы булдыру.

Учреждениенең тибын һәм төрен, булган шартларны, төркемнең тулылыгын, балаларның үсеш һәм сәламәтлек үзенчәлекләрен, шулай ук төбәкнең климаты һәм ел фасыллары үзенчәлекләрен исәпкә алып, бала организмын чыныктыру

өстендә эшләү. Чыныгу кагыйдәләре һәм төрләре, чыныктыру процедураларының файдасы турындагы күзаллауларын киңәйтү.
Балаларның рациональ туклану (артыгын ашамау, баллы, майлы һәм камыр ашлары белән кирәгеннән артык мавыкмау) турындагы күзаллауларын үстерү.

Чәй янына бирелә торган милли камыр ризыклары: гөбәдия (дөге, йөзем һәм йомырка белән), кабартма, бавырсак, талкышкәләвә, чәкчәк, кош теле белән таныштыру.
Балаларга республикадан читтә дә танылган дәвалану-ял итү урыннары һәм санаторийлар («Васильево», «Сосновый бор» («Нарат урманы»), «Крутушка», «Бакирово», «Санта» һ. б.) белән танышу мөмкинлеге бирү.
Хәрәкәтле халык уеннарын үзгәртеп төрләндерү күнекмәләре бирү. Милли уен-ярышларда («Таяк тартыш», «Аркан тартыш», «Капчык белән сугыш» һ. б.да) катнашасы килү теләге уяту.
Кеше тормышында спортның әһәмияте турында күзаллау формалаштыру. Милли спорт төре – көрәш белән таныштыру. Спорт өлкәсендәге билгеле уңыш-казанышлар белән таныштыру.

## «Физик культура» белем бирү өлкәсе

*«Физик культура» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда физик культура шөгыльләренә кызыксыну һәм аңлы караш, гармонияле физик үсеш формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм* ***белем бирү бурычларын*** *билгели.*
Идел буе халыкларының төрле эчтәлекле уеннарын мөстәкыйль эшчәнлек вакытларында файдалана белү күнекмәләрен ныгыту. Хәрәкәтле уеннарда балаларда көч, җитезлек, кыюлык, тәвәккәллек, түземлек кебек сыйфатлар тәрбияләү.
Уен нәтиҗәсен гадел бәяли белүләрен хуплау. Халык уеннары белән кызыксынуларын үстерү.

***Уен үрнәкләре***

***Йөрүле һәм йөгерүле уеннар:*** «Әбәкче», «Йортсыз куян», «Ике суык», «Сыерчык оялары», «Ачкычлар», «Төлке», «Куышу», «Каршы төшүчеләр».

***Сикерүле уеннар:*** «Сикергечләр», «Бакалар», «Чикерткәләр», «Чыпчыклар», «Җирдә калма».
***Шуышулы һәм үрмәләүле уеннар:*** «Кошлар оча», «Маймыллар аулау», «Кем беренче?».
***Ыргыту һәм тотып алу уеннары***: «Тупны тапшыр», «Кем иң төз атучы?», «Куяннар», «Тупны югарыга», «Чыпчык».
***Эстафета уеннары:*** «Иң төз атучы», «Чикерткәләр».
***Ярыш элементлары белән уеннар***: «Кем тизрәк?», «Матур шарлар», «Поезд», «Кыргаяклар ярышы».
***Татар халык уеннары***: «Без унике кыз идек», «Тимербай», «Аксак төлке».

## «Куркынычсызлык» белем бирү өлкәсе

*«Куркынычсызлык» белем бирү өлкәсе эчтәлеге үз тормышыңның куркынычсызлыгы нигезләрен һәм экологик аң*

*(әйләнә-тирә дөнья куркынычсызлыгы) алшартларын формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм* ***белем бирү бурычларын*** *билгели.*

***Тормыш куркынычсызлыгы нигезләрен формалаштыру***

Балаларның балалар бакчасында, өйдә, җәмәгать урыннарында үз-үзләрен әдәпле тоту кагыйдәләрен үти белүләрен ныгыту; башкалардан да бу кагыйдәләрнең үтәлүен таләп итәргә өйрәтү. Кирәк булган очракта, мөстәкыйль рәвештә ашыгыч ярдәм чакыру телефоны номерын җыярга өйрәтү.

***Юлларда хәвеф-хәтәрсез йөрү тәртибе формалаштыру***

Балаларны әйләнә-тирәдәге бәйләнешләрне график юл белән сурәтләргә һәм аларны рәсем, план, схема аша модельләштерергә, хәрәкәтләрнең уклы күрсәткечләрен, маршрут планнарын, схемаларын файдаланып, пространствода хәрәкәт итәргә өйрәтү.



Билгеләр һәм символлар буенча пространствода ориентлашырга, үзлегеңнән билгеләр уйлап табарга һәм аларны уеннарда куллана белергә өйрәтү. Транспорт хәрәкәте картасын күрсәтү, хәрәкәт расписаниесе турында күзаллау формалаштыру.Модельләштерүне – яшерен элемтә һәм бәйләнешләрне танып белү чарасы буларак, план-схемаларны үз микрорайонында иң хәвефсез маршрут буенча («Кем тизрәк балалар бакчасыннан якындагы тукталышка кадәрге юлны таба?», «Өйдән мәктәпкә кадәрге юлны күрсәт», «Вакыйга булган урынны тап» һ. б.) бару өчен файдалана белү күнекмәләрен ныгыту.

Макетлар, вак уенчыклар, конструкторлар кулланып, әти-әниләр белән берлектә, өйдән балалар бакчасына (сырхауханәгә, даруханәгә һ. б.) һәм кирегә куркынычсыз хәрәкәт маршруты эшләү.

Карталар, схемалар, маршрутлар, расписание, таныш булмаган юл билгеләре буенча балаларның сораулар бирә белүләрен хуплау. Балаларда кызыксынучанлык тәрбияләү, кызыксындырган мәгълүматларга җавап аласы килү яки үзлегеннән уйлап табу теләкләрен үстерү.

Яңгыр, кар яуганда һәм томан төшкәндә, урамнан хәвефсез йөрергә өйрәтү. Күрү мөмкинлеген капламыйча, зонтикны дөрес тотып йөрергә күнектерү.

Үзенең тулы исемен, фамилиясен, туган көнен, әти-әнисенең исем-фамилиясен, балалар бакчасының телефон номерын һәм адресын, якындагы тукталышларның исемнәрен әйтә белүләрен ныгыту.

Тыючы билгеләр: «Сулга (уңга) борылу тыела», «Хәрәкәт тыела», «Җәяүлеләргә юл ябык», «Керү тыела», «Тукталу тыела» һ. б. белән танышуны дәвам итү. Балалар рәсемнәрендә юл билгеләре чагылышын хуплау.

Боеручы билгеләр: «Туры барырга», «Сулга (уңга) барырга», «Түгәрәк буенча барырга» һ. б. белән таныштыру. Гому-



ми кабул ителгән символик билгеләнешләрнең мәгънәләрен аңларга булышу.

Мәгълүмат бирүче-күрсәтүче билгеләр: «Берьяклы хәрә-
кәтле юл», «Берьяклы хәрәкәтле юлга керү», «Машиналар
юлы» һ. б. белән таныштыру. Гомуми кабул ителгән символик
билгеләнешләрнең мәгънәсен аңларга ярдәм итү.
Балаларга сервис билгеләренең: «Ашау-эчү пункты», «Ягу-
лык салу станциясе», «Телефон», «ЮХИДИ посты», «Ял итү
урыны» һ. б. ның ни өчен кулланылышын мөстәкыйль рәвештә
ачыкларга мөмкинлек бирү; аларның үзенчәлекләре (формасы,
төсе), куелган урыны, ерак юлга йөрүче машина йөртүчеләр
өчен аерым мәгънәләре белән таныштыру.
Юл билгеләрен реаль шартларда өйрәнү. Балаларның игъ-
тибарларын һәм хәтерләрен үстерү.
Ике тәгәрмәчле велосипедта йөрү техникасын (төрле тиз-
лектә, темпны үзгәртеп, түгәрәк буйлап, юл буенча) камил-
ләштерү. Юлдагы ситуациягә карап, тиз арада җавап кайтару,
вакытында тормоз бирергә, тиешле урында туктарга өйрәтү.
Самокатта (уң һәм сул аякта, турыга, түгәрәк буйлап, боры-
лышлар ясап), скейтбордта, роликлы тимераякларда саклану
чаралары кулланып (шлем, перчаткалар, терсәк, тез саклагыч-
лары) йөрү кагыйдәләре белән таныштыру.
Хәрәкәт итүдән канәгатьләнү, шатлык хисләре алу.
Экстремаль ситуацияләрдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре
белән таныштыру: ничек һәм нинди очракларда коткару
хезмәтенә (полициягә, «ашыгыч ярдәм» станциясенә) теле-
фоннан шалтыратырга мөмкин һ. б.
Җир, су, һава, җир асты транспорты һәм элемтә чаралары
(«Елга (диңгез) порты», «Автовокзал», «Аэропорт», «Вокзал»,
«Җир, һава, су транспорты», «Ерак илләргә сәяхәт» лотолары
һ.б.) турында күзаллаулар булдыру.
Сюжет линиясе үсешен куәтләп, сюжетлы-рольле һәм ре-
жиссёрлык уеннарының эчтәлеген («Шәһәрнең тарихи урам-
нары буйлап җәяүле прогулка», «Юл чаты», «Без шәһәрдән

читкә, дачага барабыз», «ЮХИДИ инспекторы һәм машина
йөртүчеләр» һ. б.) мөстәкыйль билгеләргә мөмкинлек бирү.
Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү өчен кирәкле булган
ситуацияләргә балаларның игътибарын җәлеп итеп, балалар
әдәбияты һәм шигъриятен өйрәнүне дәвам итү. Проблемалы
уен ситуацияләре тудыру: «Юлның икенче ягында әниеңнең
эштән кайтып килүен күрсәң, син нишләр идең?», «Бер әбинең
юлны чыкканда кәрзиндәге гөмбәләре коелганын күрсәң, син
нишләр идең?» һ. б. Балаларны юл-транспорт һәлакәтләренең
сәбәпләрен ачыкларга өйрәтү.
Проблемалы-уенлы мәсьәләләрне, юллардагы проблемалы
ситуацияләрне чишкәндә, үзидарә күнекмәләре үсешенә бу-
лышлык итү, үз-үзеңне бәяләү һәм үз-үзеңне контрольдә тоту
күнекмәләрен үстерү.
Фотография, рәсем, схемага карап яки үз теләкләре белән,
таныш объектлар (йортлар, күперләр, транспорт чаралары,
урамнар) төзүләрен хуплау. Төзү объектында механик элемент-
лар: хәрәкәтләнүче тәгәрмәчләр, күтәрү кранының әйләнмәле
нигезен файдаланырга, төзелгән конструкцияләрне уеннарда

кулланырга өйрәтү.

Балаларны юллар төзелеше, махсус билгеләнешле техника, машиналар, өлкәннәр хезмәте белән таныштыру. Барлыкка килгән үзгәрешләр, аларның машиналар һәм җәяүлеләрнең хәвефсез хәрәкәт итүләрендә чагылыш табуын (хәвефсез хәрәкәт юлларның сыйфаты белән бәйле булуын) күрә белергә өйрәтү.

Юлларда хәрәкәт ритмының тизлеге арта бару шартларында балаларны үз куркынычсызлыкларын (үз-үзләрен саклауны) булдырырга өйрәтү.

Юл хәрәкәте әлифбасын алга таба тирәнрәк аңлап өйрәнергә әзерләү.



***Экологик аң алшартларын формалаштыру***

Туган якның тере һәм тере булмаган табигатенә сакчыл караш тәрбияләү; үзеңнең катнашыңнан соң туган уңай һәм тискәре нәтиҗәләрне алдан күрә белергә өйрәтү, табигатьне кирәксезгә кулланмау һәм аны дөрес файдалануның беренчел күнекмәләрен формалаштыру.

**Социаль-шәхси үсеш**

**«Социальләштерү» белем бирү өлкәсе**

*«Социальләштерү» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның социаль характердагы беренчел күзаллауларын үзләштерү һәм балаларны социаль мөнәсәбәтләр системасына кертү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм* ***белем бирү бурычларын*** *билгели.*

Балаларда патриотизм хисләре; үзен туган шәһәре (авылы), республикасы, иленең гражданины итеп тану; шәһәр, республика, ил символикасына (флаг, герб, гимнга) хөрмәт белән карауны һәм горурлану хисе тәрбияләү.

Иҗтимагый чыгышы, расасы, теле, дине, җенесе һәм яшенә карамыйча, янәшәдә яшәүчеләргә (балаларга, өлкәннәргә) уңай мөнәсәбәт, түземлек (толерантлык); башка кешеләрнең хисләре, фикерләре, теләкләренә, карашларына хөрмәт тәрбияләү, үзенең башкалар фикере белән риза булмавын дәлилли яисә үз позициясен яклый белергә өйрәтү. Башка ил, этнос халыклары белән позитив аралашуның, хезмәттәшлек итүнең мәгънәсен аңлату.

Якындагы социумда үз урыны, теге яки бу төркемдәге кешеләргә нинди мөнәсәбәттә булуы (балалар бакчасындагы төркем яисә бию түгәрәге әгъзасы, спорт мәктәбе укучысы, булачак гимназист һ. б.) турында күзаллаулар формалаштыру. Гаилә тарихына (карт бабай, бабай, карт әби, әби) карата



кызыксыну тәрбияләү. Гаиләң белән горурлану хисләре, гаилә әгъзаларының уңышларына сөенү, бүләкләрен игътибарсыз калдырмау күнекмәләре тәрбияләү.

Идел буе халыкларының әдәби әсәрләре, нәфис һәм мультипликацион фильмнары, әйләнә-тирәдәге тормыш турындагы күзаллауларын сюжетлы-рольле һәм режиссёрлык уеннарында иҗади кулланууларына булышлык итү.

Балаларның сәхнәләштерү һәм кую өчен Идел буе ха-

лыкларының әкиятләрен, шигырьләрен, җырларын, биюләрен мөстәкыйль сайлап алуларын хуплау; куелачак спектакльгә кирәкле атрибутлар һәм декорацияләр әзерләргә, үзара вазифаларны билгеләргә һәм рольләр бүлешергә булышу.
Театральләшкән эшчәнлектә театрның төрле төрләрен (бибабо, бармак, курчак, рәсемнәр һ. б. театрлар) куллану. Сәхнә сәнгатенә карата кызыксыну үстерү.
Коллективта сүзле уеннар уйнарга омтылышларын хуплау.
Идел буе халыклары уеннарын уйнау тәҗрибәсен баету.

**«Хезмәт» белем бирү өлкәсе**

*«Хезмәт» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда хезмәткә уңай мөнәсәбәт формалаштыру максатын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм* ***белем бирү бурычларын*** *билгели.*

Татар халык әкиятләре («Бүләк кемгә?», «Ялкау малай», «Алтын бөртекләр» һ. б.) ярдәмендә балаларның хезмәт эшчәнлеге турында күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү. Хезмәт турындагы татар халык юморы («Ике ялкау», «Энә һәм җеп» һ. б.) белән таныштыру.
Балаларның кызыксынуларыннан чыгып, кул эшенең кайбер төрләренә өйрәтү. Чигүнең төрле ысулларын (тамбурлы җөй, сәйлән белән чигү) күрсәтү, балаларга якыннары өчен милли төсмерле бүләкләр әзерләргә булышу.
Өлкәннәрнең әйләнә-тирәдәге табигатьне кайгыртуга юнәлгән эшләрендә катнашырга мөмкинлекләр бирү: ишегал-

дында (балалар бакчасындагы участокта) агач утырту, клумбаларга чәчәк утырту, су сибү, кышын кошларга җимлекләр ясау һ. б.
Гаилә бәйрәмнәренә, тантаналарга әзерләнгәндә, балаларны өлкәннәргә көчләреннән килгән кадәр булышырга, өйдә, хуҗалыкта көндәлек вазифаларын үтәргә өйрәтү.

**Танып белү-сөйләм үсеше**

**«Танып белү» белем бирү өлкәсе**

*«Танып белү» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда танып белү ихтыяҗларын һәм акылны үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм* ***белем бирү бурычларын*** *билгели.*

Республиканың үткәне һәм бүгенге яшәеше, урнашу урыны, табигате, климаты, кешеләренең тормышы белән таныштыруны дәвам итү.
Үз шәһәренең (авылының) истәлекле урыннары, халык һөнәрләре, милли кухня, Татарстан Республикасы халыкларының тел культурасы белән таныштыру.
Картада туган шәһәрен, республикасын, башкаланы, Татарстандагы эре шәһәрләрне (Әлмәт, Яр Чаллы, Түбән Кама, Бөгелмә, Яшел Үзән һ. б. ны) күрсәтә һәм атый белергә өйрәтү.
Борынгы шәһәрләр (Биләр, Болгар), аларның тарихы, культурасы, көнкүреше белән таныштыру. Авыл һәм шәһәр кешеләренең көнкүрешен чагыштырырга өйрәтү. Татар һәм рус халкының яши торган өе, йорт кирәк-яраклары, өс киемнәре үзенчәлекләренә игътибар итү.
Туган шәһәрендә бара торган позитив үзгәрешләрне (ба-

лалар бакчалары, спорт комплекслары, театрлар һ. б. төзелү)
күрә белергә өйрәтү.
Казанның эре промышленность һәм сәүдә үзәге булуы,

татар халкының элек-электән игенчелек, терлекчелек, күн
эшкәртү, сәүдә белән шөгыльләнүе турында балаларга сөйләү.

Туган шәһәренең, башка шәһәрләрнең символикасын өй-
рәнүне дәвам итү, үз халкының бер өлеше булуын аңлый
белергә ярдәм итү.

Милли һәм дөнья культураларының үткәненә һәм бүгенге-
сенә балаларны якынайту. Музыка һәм театр сәнгатенең
күренекле шәхесләре, аларның тормыш һәм иҗат юллары
белән таныштыру (композиторлар: С. Садыйкова, С. Сәйдәшев,
Ф. Яруллин һ. б., җырчылар: Ф. Шаляпин, И. Шакиров,
Р. Ибраһимов һ. б., театр режиссёрлары: М. Сәлимҗанов,
К. Тинчурин һ. б., В. Качалов, Г. Камал исемендәге театр ак-
тёрлары һ. б.). Аларның тормышларына һәм эшчәнлекләренә
кызыксыну уяту.

Күренекле фән эшлеклеләренең тормышы һәм эшчән-
лекләре белән таныштыру (Н. И. Лобачевский, К. Ф. Фукс,
И. М. Симонов, Н. Н. Зинин, А. М. Бутлеров, А. Е. Арбу-
зов һ. б.). Балаларның танып белүгә карата кызыксынуларын
канәгатьләндерү, Казан (Идел буе) федераль университеты укы-
тучылары һәм аны тәмамлаучылар турында мәгълүмат бирү.

Милләтебез каһарманнарының Бөек Ватан сугышында
күрсәткән батырлыклары турында сөйләү (М. Җәлил, Г. Гафи-
ятуллин, М. П. Девятаев, П. М. Гаврилов, Н. Г. Столяров һ. б.).
Әти-әниләрне балаларга әби һәм бабаларының сугышта алган
бүләкләре турында сөйләргә җәлеп итү. Ватанны саклаучы-
ларга карата хөрмәт хисләре тәрбияләү (һәйкәлләр, обелиск-
ларга чәчәкләр кую һ. б.).

Табигатьне саклау буенча балаларның белемнәрен тирә-
нәйтү. Туган якның тере һәм тере булмаган табигатенә сак-
чыл караш тәрбияләү, табигатькә катнашуыңнан соң туган
уңай һәм тискәре нәтиҗәләрне алдан күрә белергә өйрәтү,
табигатьнең ресурсларына сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү, аны
рациональ файдалану күнекмәләре формалаштыру. Үсемлек
һәм җиләкләрне җыю кагыйдәләре белән таныштыру.


Дәүләт тыюлыклары, анда яшәүче тереклек ияләре, Татар-
стан Республикасының Кызыл китабына кертелгән үсемлек
(флора) һәм хайваннар (фауна) төрләре белән таныштыру-
ны дәвам итү. Хайваннар һәм үсемлекләр дөньясында сирәк
очрый торган төрләргә сакчыл караш кирәклеген балаларның
аңнарына җиткерү.

Татарстанның елга, күлләрендә яшәүче тереклек ияләре
белән таныштыру. Кеше тормышында чишмә, елгаларның тот-
кан урыны, әһәмияте турында сөйләү. Республика сулыкларын
чиста тотарга теләк уяту.

Туган як табигатенең матурлыгына, андагы форма, ис, төс
муллыгына игътибар итү. Табигатьтәге үзгәрешләрне күрә
белергә өйрәтү.

## «Аралашу» белем бирү өлкәсе

*«Аралашу» белем бирү өлкәсе эчтәлеге әйләнә-тирәдәге кешеләрнең үзара мөгамәләсенең конструктив ысул һәм чаралары үзләштерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм* ***белем бирү бурычларын*** *билгели.*

Рус теленә карата тотрыклы кызыксыну үстерү. Мәгълүмати-аралашу технологияләре, аудио- һәм видеоязмалар, укуукыту методик комплектлары ярдәмендә предметны, аның билгесен, хәрәкәтен белдерүче сүзләрне актив кулланышка кертү, гади аралашу өчен кирәк булган сөйләм берәмлекләре байлыгы булдыру. Балаларның сүз байлыгын арттыру.

Төзелеше ягыннан катлаулы булмаган хикәя һәм сорау җөмләләр төзү күнекмәләрен ныгыту.

Үзе турында, бер кеше гамәлләрен сурәтләгән ситуатив картиналар сериясе буенча, сюжетлы рәсемнәр, үз күзәтүләреннән чыгып, зур булмаган (3–5 җөмләле) хикәяләр төзи белергә өйрәтү.

Балаларның төрле эшчәнлек вакытында рус халык фольк-



лор әсәрләрен, еш кулланыла торган сүзләр һәм әйтемнәрне файдалануга омтылышларын хуплау.

Рус телендә сөйләүче әңгәмәдәшенең сөйләмен тыңлый белүне формалаштыру, нәрсә турында сөйләгәнен аңларга тырышу, телне аз белүенә карамастан, аның белән әңгәмәгә кереп, аралашырга омтылышын хуплау.

Балаларны рус телен киләчәктә (башлангыч мәктәптә) тагын да аңлабрак, төшенеп өйрәнергә әзерләү.

## «Матур әдәбият уку» белем бирү өлкәсе

*«Матур әдәбият уку» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда китап укуга кызыксыну һәм ихтыяҗ формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм* ***белем бирү бурычларын*** *билгели.*

Әдәби, танып белү, энциклопедик характердагы китаплар ярдәмендә уку эшчәнлеген киңәйтү.

Әкият, хикәя, шигырьнең төп билгеләре белән таныштыру. Укыганны аңлый, әдәби геройларның эш-гамәлләрен дөрес бәяли, булган вакыйгалар турында үз фикереңне әйтә белергә өйрәтү.

Кайбер проза текстларының эчтәлеген сәнгатьле итеп һәм кечерәк шигырьләрне яттан сөйләргә өйрәтү, татар халык экиятләрен сәхнәләштерүдә катнашырга теләк тудыру.

Идел буе халыкларының әкиятләрен файдаланып, әдәби образны үзләре аңлаганча күзаллау нигезендә, балаларның иҗади хыялларын үстерү.

Кече фольклор жанрына карата кызыксыну булдыру. Балаларны, үз әдәби тәҗрибәләреннән чыгып, стиль һәм жанр үзенчәлекләрен саклап, сүз сәнгатенә якынайту.

Татар халык юморы белән таныштыру. Юмор хисе үстерү.



### *Тәкъдим ителә торган әсәрләр*

### *Балаларга уку өчен*

*Җырлар, такмаклар, әйтенүләр, тел көрмәкләндергечләр,*

*санамышлар, алдавыч әкиятләр:* «Юл читендә зәңгәр чәчәк…»; «Кәҗә-кәҗә, Мәкәрҗә…»; «Сип-сип суганга…»; «Тилгән, тилгән…»; «Үрмәкүч, күч…»; «Саескан, саескан бүрәнәгә ябышкан…»; «Җепсез орчык…»; «Әлчи-бәлчи…»; «Каенда – карга…»; «Наза»; «Сания апа суга бара…»; «Их, төймә, төймә, төймә…»; «Бер аланда чәчәкләр күп…»; «Нардуган, Нардуган…»; «Әйләнәбез Нардуган…»; «Күпер башында күп күркә…»; «Ваттым мичкә, яктым мичкә…»; «Казандагы суны…»; «Чәйнеккә акча салдым…»; «Әти китте базарга…»; «Чар, чар, чыпчыклар…»; «Нәүрүз әйттек без сезгә…»; «Карга әйтә: карр, карр, туем җитте, бар бар!..»; «Исәнлеккә-саулыкка…»; «Тьфү-тьфү дияем…»; «Әүвәл заманда булган бер зур тау…»; «Борын-борын заманда…».
*Әкиятләр, легендалар:* Татар халык әкиятләре: «Ай белән Кояш»; «Кәкре каенга терәткән»; «Алтын бөртекләр»; «Бүләк кемгә?»; «Ялкау малай»; «Зөһрә йолдыз» (легенда); «Ни өчен бакалар бакылдык булып калганнар?» (легенда); «Ни өчен Чәберчек килмичә боз китми икән?» (легенда); «Үрдәк беренчелекне алган»; эстон халык әкияте «Куянның ирене нигә ерык?»; болгар халык әкияте «Хәйләкәр этәч»; һинд халык әкияте «Сандугач»; Корея халкы әкияте «Тату туганнар»; «Казлар-аккошлар», русчадан Т. Шакирова тәрҗемәсе; төрекмән халык әкияте «Икмәк», русчадан Р. Вәлиев тәрҗемәсе; инглиз халык әкияте «Пингвин баласы», русчадан Р. Вәлиев тәрҗемәсе; мари халык әкияте «Төлке белән Аю»; удмурт халык әкияте «Тычкан белән Чыпчык», Р. Вәлиев тәрҗемәсе.
*Әдәби әкиятләр:* А. Алиш. «Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар»; С. Гыйльметдинова. «Тузганак»; Г. Тукай. «Ташбака белән Куян»; Ә. Гаффар. «Кыңгырау чәчәкләр»; А. Хәсән. «Кыш бабай бүләк өләшә»; Р. Батулла. «Чыбык

ашату»; Ф. Яруллин буенча. «Иң бәхетле көн»; Н. Исәнбәт. «Һәркемнең үз эше»; В. Даль. «Кар кызы», русчадан Т. Шакирова тәрҗемәсе; К. Ушинский. «Җил белән Кояш», русчадан Т. Шакирова тәрҗемәсе; С. Сәүбанова. «Чәчәк»; С. Гаффарова. «Гөлгүзәл»; С. Әдһәмова. «Дуслар»; Ф. Зариф. «Чишмә».
*Шигърият:* Н. Думави. «Мәктәп»; Г. Тукай. «Чыршы»; С. Сүнчәләй. «Күңелсез көз»; Х. Халиков. «Кырдан кайткач»; Р. Бәшәр. «Бүген», «Сандугачлы ак инеш»; Ә. Бикчәнтәева. «Әлифбам»; Ф. Яруллин. «Татарстан байрагы»; Р. Вәлиева. «Ашлар солтаны»; Н. Думави. «Беренче кар»; М. Гафури. «Татар теле»; Б. Рәхмәт. «Кыш килде»; Җ. Дәрзаман. «Җепшек көндә»; Г. Тукай. «Ак бабай»; Җ. Тәрҗеманов. «Һай, Кыш бабай»; Л. Шагыйрьҗан. «Сөембикә манарасы»; Р. Миңнуллин. «Светофор»; Я. Игәнәй. «Әти кайтыр эштән…»; Ш. Җиһангирова. «Кайгырту»; Р. Корбан. «Муса Җәлил турында җыр»; М. Гафури. «Китап һәм балалар»; Р. Бәшәр. «Намаз»; Г. Тукай. «Бәйрәм бүген»; Р. Вәлиева. «Энҗе-мәрҗән калфагым»; Йолдыз. «Сәлам, Галәм!», «Карга боткасы»; Ф. Яруллин. «Әниләр бәйрәмендә»; Й. Җамалетдинова. «Тылсымлы түбәтәй»; Р. Корбан. «Кояш – безнең дустыбыз»; М. Әгъләмов.

«Тукай көне»; Р. Хафизова. «Нәүрүз килә»; Э. Мөэминова. «Моңсу бәйрәм»; Р. Фәйзуллин. «Кызыл китап»; А. Хәлим. «Биктырыш «Әлифба» укый».

*Төрле ил язучылары һәм шагыйрьләре әсәрләре:* С. Маршак. «Май», «Июнь»; А. Барто. «Катя», «Кабырчык», Ә. Исхак тәрҗемәсе; В. Романов. «Дуслашасым килә», удмуртча, русчадан Р. Миңнуллин тәрҗемәсе; Ю. Некрошюс. «Карга бичара», литвача, русчадан Р. Миңнуллин тәрҗемәсе; Р. Сарби. «Мин җырларга яратам», чувашча, русчадан Р. Миңнуллин тәрҗемәсе.

*Чәчмә әсәрләр:* Дәрдемәнд. «Өч угыл»; Н. Каштан. «Хәрәмләшү»; К. Ушинский. «Сабыр итә бел», Ш. Шириазданов тәрҗемәсе; Н. Каштан. «Кем тизрәк үскән?»; В. Осеева. «Тылсымлы сүз», А. Лотфуллина тәрҗемәсе; Р. Фәхреддин.



«Тәрбияле бала» (өзекләр); А. Әхмәт. «Ай-һай!»; Г. Хәсәнов. «Куян»; Р. Хафизова. «Песнәк»; Р. Вәлиева. «Туган көндә»; Г. Сабитов. «Кадерле бүләк»; Х. Халиков. «Витаминлы аш»; Р. Вәлиева. «Ак песи»; Н. Каштан. «Солтания белән күбәләк»; Ф. Яруллин. «Кояштагы тап»; Л. Толстой. «Кырмыска белән Күгәрчен» (мәсәл); М. Пришвин. «Туган илем» (истәлекләрдән), русчадан Х. Фәйзрахманова тәрҗемәсе; Н. Носов. «Җанлы эшләпә», русчадан Т. Шакирова тәрҗемәсе.

*Рольләргә бүлеп сөйләү өчен:* К. Тәхау. «Казлар, казлар…»; Х. Халиков. «Карак песи»; Р. Миңнуллин. «Малайлар сөйләшә»; А. Нигъмәтуллин. «Песи һәм Чыпчык».

***Яттан өйрәнү өчен***

М. Җәлил. «Көз җитте»; Г. Тукай. «Туган тел»; Н. Гайсин. «Уңыш җыелды», «Бер яшькә үстем»; Г. Латыйп. «Кыш килде»; Э. Мөэминова. «Туган телем»; Х. Туфан. «Казан»; М. Мазунов. «Яз килә»; Ж. Тәрҗеманов. «Иң матур җыр»; Ә. Бикчәнтәева. «Хуш, сөекле бакчабыз»; Р. Вәлиева. «Туган җир».

***Өстәмә әдәбият***

*Шигърият:* Г. Морат. «Хәрәкәттә – бәрәкәт»; Д. Гарифуллин. «Көмеш чишмә»; А. Хәлим. «Без ашыйбыз бишбармак»; В. Хәйруллина. «Татлы чир»; Йолдыз. «Тылсымлы сүзләр», «Рамазан аенда»; Р. Бәшәр. «Мин бит татар егете»; Р. Корбан. «Кояш – безнең дустыбыз»; Г. Тукай. «Кызыклы шәкерт»; Ә. Бикчәнтәева. «Нәни чакта һәм зур үскәч», «Үрли дә үрли генә»; Р. Фәйзуллин. «Табигать кочагында»; Ә. Кари. «Тәүлек»; Р. Фәйзуллин. «Кәгазь»; Б. Рәхимова. «Бәхәс»; Л. Әмирханова. «Чигүле читекләрем»; Л. Лерон. «Татар баласы»; Й. Җамалетдинова. «Кавын»; Н. Дәүли. «Минем дустым – Әлифба».

*Чәчмә әсәрләр. Әдәби әкиятләр:* К. Насыйри. «Табын әдәпләре»; Н. Каштан. «Хикмәтле чиләк»; В. Осеева. «Кем хуҗа?», русчадан Ф. Гайнанова тәрҗемәсе; М. Закир. «Кара төс ни өчен кирәк?»; Э. Шәрифуллина. «Әкияттәге кебек», «Ничек аңларга?»; Ф. Яруллин. «Хәтерсез Күке».



**Нәфис-нәфасәти үсеш**

**«Иҗади сәнгать» белем бирү өлкәсе**

*«Иҗади сәнгать» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда әйләнә-тирәдәге матурлыкка кызыксыну уятуны һәм үзүзләрен күрсәтү ихтыяҗларын канәгатьләндерүне формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм* ***белем бирү бурычларын*** *билгели.*

### *Нәтиҗәле эшчәнлек төрләрен үстерү*

### *Рәсем ясау*

Милли орнамент элементлары белән таныштыруны дәвам итү. Балалар белән «яшәү агачы» образын карау. Балаларның игътибарын композициянең үзенчәлегенә (симметриясез), шул ук вакытта төрле төсләр файдаланылган чәчәк бәйләменә юнәлдерү.

Балаларны декоратив эшчәнлеккә җәлеп итү: сабаклары, бөре, чәчәк, җимеш, яфрак, бөтеркә элементлары белән бизәлгән, нәфис бөгелгән ботакны хәтерләтүче симметриясез чәчәк бәйләме ясау ысулларын күрсәтү.

Бизәкне планлаштыру ысуллары (алдан эскиз ясау, каралама, композиция схемасы) белән таныштыру. Сурәтләү алымнарын уйлап табу, төрләндерүләрен хуплау (пумаласыз ясау ысулын кертеп). Композиция хисен үстерү.

Предметның формасына, билгеләнешенә, материалына карап, декоратив тукымалар, баш һәм аяк киемнәре, сөлгеләр өчен бизәкләр уйлап табу.

Яңа техникаларны үзләштерү һәм танышларын берләштерү өчен шартлар тудыру. Төрле материаллар кулланырга, реаль һәм әкияти образларны (Идел буе халыклары әкиятләрендәге геройларны да кертеп) сурәтләүнең төрле ысулларын берләштерергә мөмкинлекләр бирү. Көнкүреш предметлары, интерьер, костюмнарның характерлы үзенчәлекләрен сурәтләү ярдәмендә тарихи образларны тасвирлый белергә өйрәтү.



Коллектив белән сюжетлы һәм декоратив композицияләр башкарганда, күмәк иҗат итү күнекмәләрен үстерү. Балаларның инициатива, мөстәкыйльлек күрсәтүләрен, башланган эшне ахырына кадәр җиткерә белүләрен хуплау.

Республика тормышында булган истәлекле вакыйгаларны рәсемнәрдә чагылдыра белүләрен хуплау. Балаларның эшләрен бергәләп карау, нәрсә ясаганнары турында сөйли белергә өйрәтү. Балаларга эшләренең тематикасын киңәйтүгә булышлык итү.

### *Әвәләү*

Әвәләү эшчәнлеге белән кызыксыну үстерүне дәвам итү; балчыктан (тозлы камыр, пластилиннан) әвәләп ясый белү күнекмәләрен камилләштерү. Музейда алган кичерешләрен әвәләү эшчәнлегендә чагылдыру өчен шартлар тудыру. Савытсабаны (комган, кувшин, ваза һ.б. ны) тасма ысулы белән, өлешләрне модельләштереп һәм тарттырып, махсус таякчык (стека) ярдәмендә аларга хас үзенчәлекләрне күрсәтеп әвәли белү күнекмәләрен камилләштерү.

Рельефлы сурәтләү техникасын камилләштерү. Табигый үрнәк (натура) үзенчәлекләрен исәпкә алып, пропорцияләрен дөрес биреп, тукранбаш әвәли белү күнекмәләрен үстерү.

Балаларның игътибарын әвәләү эшен плинтустан – нигездән башларга кирәклегенә, аның өстенә махсус таякчык очы ярдәмендә рельефның контурлы рәсеме төшерелүенә юнәлдерү.
Актүбә һәм Шәмәрдән уенчыкларын натурадан карап әвәли һәм аларның характерлы үзенчәлекләрен бирә белергә өйрәтү.
Ике-өч фигурадан торган скульптура төркемнәрен катлаулы булмаган сюжетларга («Сабантуйда», «Чәй эчкәндә», «Ат чабышлары» һ. б.га) берләштерү. Нәрсә эшләячәкләрен мөстәкыйль рәвештә билгели белүләрен, фигураларның хәрәкәт һәм торышларын матур итеп бирергә тырышуларын хуплау.
Идел буе халыкларының әдәби әсәрләре геройларын күзаллау юлы белән әвәли белү күнекмәләрен формалаштыру.
Балаларның иҗади сәләт һәм инициативаларын үстерү.



### *Кисеп ябыштыру*

Балаларның аппликация сәнгатенә карата кызыксынуларын үстерү; кисеп ябыштыру эшчәнлегенең эчтәлеген катлауландыра барып, сюжетлы сурәтләр барлыкка китерергә өйрәтүне дәвам итү.
Симметрик, силуэтлы, катлы-катлы, ажурлы кисеп алу техникаларын, фонга детальләрне ябыштыруның күптөрле ысулларын, кәгазьне ертып-ертып (обрывание) һәм өсте-өстенә ябыштыру техникаларын куллануларын хуплау.
Балаларны коллектив белән орнаментлы аппликацияләр (панно, фризлар, коллажлар) төзергә, сәнгати образ тудыру өчен күптөрле материаллар кулланырга өйрәтү.
Дәлия (георгин), чалма чәчәк (пион), кашкарый (астра) чәчәкләреннән композиция төзү өчен, күләмле аппликация ясау ысулларын камилләштерү. Сурәтне баетучы детальләр (кошлар, бал кортлары, күбәләкләр һ. б.) белән композицияне тулыландыру теләкләрен хуплау.
Туган шәһәре (авылы) тормышындагы вакыйгаларны чагылдыручы сюжетларны мөстәкыйль сайлый белүләрен активлаштыру. Башка белем бирү өлкәләренең эчтәлеге белән яраклаштырып, балалар эшләренең тематикасын киңәйтү.

### *Сынлы сәнгатькә тарту*

Балаларны Г. Тукай әсәрләре һәм аның иҗатын чагылдыручы сәнгать төрләре (Ф. Яруллинның «Шүрәле», Ә. Бәшировның «Су анасы» балетлары, Н. Җиһановның «Кырлай» симфониясе, Б. Урманче, И. Казаков, Б. Әлменов, Ф. Әминов һ. б. ның сынлы һәм рәсем сәнгатьләре әсәрләре) белән таныштыруны дәвам итү. Сәнгатькә карата уңай караш формалаштыру.
Сурәтләү сәнгате әсәрләрен тулысынча кабул итү, аңлый белү өчен шартлар тудыру. Балаларны Татарстан Сынлы сәнгать музеендагы рәсем сәнгате әсәрләре (И. Левитанның «Алтын көз», Н. И. Феминның «Портрет Вари Адоратской» («Варя Адоратская портреты»), И. И. Шишкинның



«Арыш» («Рожь»), Х. Якуповның «Хөкем алдыннан» («Перед приговором»), И. Казаковның «Кечкенә Тукай» («Маленький Тукай») һ. б. әсәрләр) белән таныштыруны дәвам итү.

Сәнгати кабул итү, уйлау, хәтер, күзаллау кебек сыйфатлар үстерү. Сәнгать әсәрләренә мөстәкыйль бәя бирүне хуплау.
Балаларны борынгы сәнгать – металлны нәфис эшкәртү сәнгате белән таныштыру. «Казан» милли-мәдәни үзәгенең милли-мәдәният музеенда булу, анда борынгыдан сакланып калган өй кирәк-яраклары: көмеш поднослар, савыт-саба, бизәк төшерелгән бакыр кувшиннар, комганнар, йорт хайваннары фигуралары формасындагы бронза йозаклар; җәмәгать биналарының интерьерларын һәм экстерьерларын бизәүче декоратив композицияләр белән таныштыру.
Борынгы бизәнү әйберләрен: йөзекләр, алкалар, беләзекләр, чулпылар, яка чылбырлары, хәситәләр һ. б.ны карау. Хәзерге заман рәссам-ювелирларның (И. Фазылҗанов, С. В. Ковалевская, В. О. Ковалевский һ. б.ның) иҗатлары белән таныштыру. Балаларның игътибарын бизәнү әйберләренең милли үзенчәлекләренә юнәлдерү.
Татар халкының үзенчәлекле сәнгати һөнәре булган ука белән чигү турында сөйләү. Чигелгән түбәтәйләр, хатын-кызның бәрхет аяк киеме, күкрәкчәләр, калфаклар һ. б.ны карау. Бигрәк тә популяр булган композицияләргә – «алтын каурый», чәчәк бәйләме, кошлар, бодай башагы, йолдызлар һәм ярымай мотивларына һ. б.га игътибар итү.
Туган шәһәр (авыл) архитектурасы – мәчет һәм храм архитектуралары (Кол Шәриф мәчете, Раифадагы Богородицкий ир-атлар монастыре) белән таныштыру эшен дәвам итү. Аларга хас үзенчәлекләрне, пропорцияләрнең, конструкцияләрнең, бизәү элементларының төрлелеген күрә белергә өйрәтү.
Китап иллюстрацияләре турындагы белемнәрен ныгыту.
Балалар әдәбиятында Шүрәле образын сурәтләүче рәссам-иллюстраторларның (Ф. Әминов, Б. Әлменов, В. Булатов, Ю. Вәлиәхмәтов, А. Тимергалин, Б. Урманче, Н. Хаҗиәхмәтов,

Р. Шәмсетдинов һ. б.ның) иҗатлары белән таныштыру. Бу әкият персонажын һәр рәссамның үзенчә гәүдәләндерүенә игътибар итү. Китап иллюстрацияләрен карау, алар буенча сораулар бирүгә кызыксыну уяту.

## «Музыка» белем бирү өлкәсе

*«Музыка» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис-тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм* ***белем бирү бурычларын*** *билгели.*
Балаларны татар халкының музыка культурасына якынайту. Вокаль, инструменталь, оркестр өчен язылган музыкаль әсәрләрнең иң матур үрнәкләре белән таныштыру. Музыканың характерын, настроениесен билгели белергә өйрәтү, аның турындагы әңгәмәдә катнашасы килү теләге уяту.
С. Сәйдәшев, Ф. Яруллин, М. Мозаффаров. А. Ключарёв, Р. Яхин, Н. Җиһанов һ. б.ның музыкаль әсәрләренә эмоциональ мөнәсәбәт белдерү. Татар композиторларының музыкаль әсәрләре жанрын ачыклый, халык инструментлары оркестры һәм симфония музыкасындагы таныш музыкаль инструментларның яңгырашын таный белүләрен ныгыту.

Татарстан Республикасы, Россия Федерациясенең Дәүләт гимннары белән таныштыру, аларны тану. Горурлык хисләре тәрбияләү.

Милли репертуар нигезендә балаларның җырлау күнекмәләрен формалаштыру эшен дәвам итү; чиста яңгыраш, дөрес әйтелеш, сәнгатьле башкара белү осталыгына ирешү.

Төп бию хәрәкәтләрен («төп йөреш», «сыгылмалы йөреш», «тегү», «беренче йөреш», «тыпырдаулы йөреш», «борма», «бишек», «үкчә-баш», «баш-үкчә», «үкчәдә йөреш», «гади адым», «өчле тыпырдау», «култыклашып әйләнү», «вак тыпырдау» һ. б.) башкара белү осталыкларын үстерү.



Татар биюен башкару техникасын камилләштерү.

Идел буе халыклары биюләрен өйрәтү, хәрәкәтләрне сәнгатьле һәм ритмлы башкара белергә өйрәтү.

Таныш җырларны, әсәрләрне, биюләрне кулланып, бирелгән тема үрнәгендә мөстәкыйль рәвештә көйләр импровизацияләргә өйрәтү. Музыкаль сәләтләрен, фикерләү, хыялларын формалаштырырга дәртләндерү; мөстәкыйльлек һәм активлык күрсәтергә булышу.

***Тәкъдим ителгән музыкаль әсәрләр***

***Музыка тыңлау***

«Бәйрәмдә», Р. Яхин муз.; «Иртәнге нур», С. Садыйкова муз., З. Вәли сүз.; «Татарстан маршы», Х. Вәлиуллин муз.; «Бишек җыры», А. Ключарёв муз.; «Моңсу», «Кайгы», «Көй», Н. Җиһанов муз. («Балалар альбомы»ннан); «Бию көе», Ә. Бакиров муз.; «Алтын көз», А. Батыршин муз., З. Нури сүз.; «Шаяру», А. Луппов муз.; «Әдрән диңгез», С. Сәйдәшев муз.; «Вальс-экспромт», Р. Яхин муз.; «Прелюдие», И. Шәмсетдинов муз.; «Шүрәле шуклыклары», Л. Любовский муз.; «Мәзәк бию», Р. Яхин муз.; «Кылыч белән бию», А. Ключарёв муз. («Тау экияте» балетыннан); «Шүрәле», «Сөембикә һәм кошлар биюе», «Кызлар биюе», Ф. Яруллин муз. («Шүрәле» балетыннан); «Вальс», «Полька», Н. Җиһанов муз.; «Совет Армиясе маршы», С. Сәйдәшев муз.; «Көз», «Кыш», «Яз», «Җәй», Р. Яхин муз. («Табигать күренешләре» циклынан); «Әкият», Н. Җиһанов муз.; «Урман», Н. Җиһанов музыкасы («Кырлай» симфоник поэмасыннан ); «Тукай маршы», З. Яруллин муз.; «Алтынчәч» операсына кереш», Н. Җиһанов муз.; «Күмәк бию», Х. Вәлиуллин муз. («Самат» операсыннан); «Башкорт көйләре», С. Ишбулатов муз.; «Әллүки», татар халык көе, Г. Тукай сүз., Р. Еникеева эшкәрт.; «Сак-Сок бәете», Ә. Шәрәфиев муз.; «Әнисә», татар халык җыры, Л. Батыр-Болгари эшкәрт. (җиңел вариацияләр); «Сабантуй», бәйрәм увертюрасы, Ф. Әхмәтов



муз.; «Сайра, сандугач», М. Мозаффаров муз., М. Садри сүз.; «Гармун моңнары», А. Луппов муз.; «Авылда», Р. Яхин муз. («Җәйге кичләр» циклыннан); «Таң», М. Шәмсетдинова муз. («Авылда бала чагым» циклыннан); «Якты алан», М. Яруллин муз. («Балалар сюитасы»ннан); «Ватан», Р. Салахов муз., Р. Корбан сүз.; «Каршылау маршы», С. Сәйдәшев муз.; «Нас много на шаре земном», Ан. Александров муз., Т. Лихоталь

сүз.; «Детская полька», М. Глинка муз.; «Колыбельная», В. Моцарт муз.; «Весёлый крестьянин», Р. Шуман муз.; «Марш», С. Прокофьев муз.; «Октябрь», П. Чайковский муз. («Времена года» циклыннан); «Камаринская», «Песня жаворонка», «Вальс», П. Чайковский муз. («Балалар альбомы»ннан); «Море», «Белка», «Полёт Шмеля», Н. Римский-Корсаков муз. («Сказка о царе Салтане» операсыннан); «Кавалерийская», Д. Кабалевский муз.; «Осень», «Зима», «Весна», «Лето», А. Вивальди муз. («Времена года» циклыннан).

***Җырлау***

*Музыкаль ишетү сәләте һәм тавыш үстерүгә күнегүләр:* «Пескәем», Р. Еникеева муз., М. Хөсәен сүз.; «Көз», М. Әндерҗанова муз. һәм сүз.; «Гөмбәгә», Ф. Җәләлетдинова муз., Г. Рәхим сүз.; «Чәүкә», Г. Гыйләҗетдинова муз., Х. Гарданов сүз.; «Зөлфия хезмәт сөя», Н. Зарипова муз., Г. Таһирова сүз.; «Яз», Н. Бакиева, З. Шәйхетдинова муз. һәм сүз.; «Кошлар килде», Ш. Мәҗитов муз., Г. Латыйп сүз.; «Язгы яңгыр», Р. Еникеева муз., Г. Афзал сүз.; «Бишек җыры», татар халык көе, Р. Миңнуллин сүз.; «Көтүче», Р. Еникеева муз., Н. Исәнбәт сүз.; «Казлар һәм бәбкәләр», татар халык көе, Л. Лерон сүз.; «Лиса по лесу ходила», рус халык җыры, Т. Попатенко эшкәрт.; «Бубенчики», Е. Тиличеева муз., М. Долинов сүз.; «Скок-скок, поскок», рус халык җыры, Г. Левкодимов эшкәрт.; «Качели», Е. Тиличеева муз., М. Долинов сүз.; «Горошина», В. Карасева муз., Н. Френкель сүз.; «А я по лугу», рус халык көе.

*Җырлар:* «Хәерле иртә!», Р. Салахов муз., Р. Корбан сүз.; «Мин җырларга яратам», Л. Таһирова муз., Р. Миңнуллин сүз.;



«Туган илебез», Л. Батыр-Болгари муз., З. Туфайлова сүз.; «Үтте-китте», Л. Хисмәтуллина муз., К. Нәҗми сүз.; «Кар яугач», А. Батыршин муз., З. Нури сүз.; «Песнәк», Р. Еникеева муз., Г. Афзал сүз.; «Елмаю», Ш. Кашапов муз., Хәйдәр сүз.; «Кыш көне», И. Шәмсетдинов муз., Ә. Ерикәй сүз.; «Кышкы бишек җыры», Л. Таһирова муз., Н. Сафина сүз.; «Кыш бабай», Ф. Җәләлетдинова муз., Э. Рәшитов сүз.; «Яшь спортчы җыры», Н. Лотфуллина муз., Р. Вәлиева сүз.; «Яраткан безнең әни», Л. Батыр-Болгари муз., Ф. Рәхимголова сүз.; «Минем әби», А. Ключарёв муз., Г. Латыйп сүз.; «Әнием», Л. Хисмәтуллина муз., Л. Юнысова сүз.; «Туган илнең улы мин», Ф. Әбүбәкеров муз., Р. Миңнуллин сүз.; «Курчакка күлмәк тектем», Л. Батыр-Болгари муз., Р. Вәлиева сүз.; «Балалар җыры бу», А. Монасыйпов муз., Г. Рәхим сүз.; «Дуслык җыры», А. Гарифуллина муз., Ф. Сафин сүз.; «Тал песие», Ф. Әхмәтов муз., Б. Рәхмәт сүз.; «Яз дуслары», А. Батыршин муз., З. Нури сүз.; «Чыпчык», Ф. Җәләлетдинова муз., Р. Вәлиева сүз.; «Җирдә миңа ни кирәк?», Ф. Ахметшин муз., Ш. Галиев сүз.; «Җиңү көне», А. Гайнетдинова муз. һәм сүз.; «Яңгырдан соң», Л. Таһирова муз., Ә. Кари сүз.; «Мәктәпкә», Н. Лотфуллина муз., Ә. Бикчәнтәева сүз.; «Хушлашабыз бакча белән», А. Имаев муз., Р. Миңнуллин сүз., Р. Еникеева эшкәрт.; «Алфавит», Р. Зарипов муз., К. Нәҗми сүз.; «Рәхмәт сиңа, бакчабыз», Р. Ахиярова муз., Л. Әмирханова сүз.; «Күңелле балачак», И. Шәмсетдинов

муз., Г. Латыйп сүз.; «Бала белән Сандугач», И. Шәмсетдинов муз., Н. Баян сүз.; «Күбәләк», Җ. Фәйзи муз., Ф. Кәрим сүз.; «Әнкәләр, бәбкәләр», С. Вәлиди муз., А. Юнысова сүз.; «Сабан туе», Р. Еникеева муз., Г. Зәйнашева сүз.; «Гөлләрем», Л. Таһирова муз., Ә. Кари сүз.; «Зәңгәр күл», С. Сәйдәшев муз., Г. Насрый сүз.; «Сара мәктәпкә бара», А. Ключарёв муз., Б. Рәхмәт сүз.; «Күңелле безнең шәһәр», Л. Батыр-Болгари муз., Г. Зәйнашева сүз.; «Листопад», Т. Попатенко муз., Е. Авдиенко сүз.; «Здравствуй, Родина моя!», Ю. Чичков муз., К. Ибряев сүз.; «Будет горка во дворе», Т. Попатенко муз.,



Е. Авдиенко сүз.; «Ёлочка», Л. Бекман муз., Р. Кудашева сүз.; «Бравые солдаты», А. Филиппенко муз.,Т. Волгина сүз.; «Самая хорошая», В. Иванников муз., О. Фадеева сүз.; Солнечная капель», С. Соснин муз., И. Вахрушева сүз.; «Мы теперь ученики», Г. Струве муз., К. Ибряев сүз.; «До свиданья, детский сад», А. Филиппенко муз.,Т. Волгина сүз.

*Җыр иҗаты:* «Гөлләр үсә», татар халык көе, Р. Еникеева эшкәрт.; «Көз», Р. Еникеева муз., К. Нәҗми сүз.; «Елак песи», Л. Батыр-Болгари муз., Р. Вәлиева сүз.; «Әнисә», татар халык көе, Р. Еникеева эшкәрт.; «Тын бакчада», М. Мозаффаров муз.; «Бәйрәм бүген», Ш. Тимербулатов муз.; «Яз», Р. Ахиярова муз.; «Лирик җыр», Н. Зарипова муз.; «Фазыл чишмәсе», татар халык көе, Р. Еникеева эшкәрт.

### *Музыкаль-ритмик хәрәкәтләр*

*Күнегүләр:* «Марш», З. Хәбибуллин муз.; «Шәл бәйләдем», башкорт халык көе, Б. Мулюков эшкәрт.; «Шаяру», татар халык көе; «Поход маршы», С. Сәйдәшев муз.; «Полька», З. Хәбибуллин муз.; «Кем яхшы йөгерә?», Л. Батыр-Болгари муз.; «Түгәрәк уен», татар халык көе; «Яфраклар белән күнегү», Р. Яхин муз.; «Яшьләр биюе», татар халык көе; «Кыю җайдаклар», Б. Мулюков муз.; «Түгәрәк уены», татар халык көе, М. Яруллин эшкәрт.; «Пар ат», З. Хәбибуллин муз.; «Кул сугып уйнау», татар халык көе; «Тасмалар белән күнегү», Р. Яхин муз. (1 нче кисәк ); «Язгы вальс», Ф. Шәймәрданова муз.; «Бию көе», Л. Батыр-Болгари эшкәрт.; «Уенлы бию», Ә. Абдуллин муз.; «Хәрефле шакмаклар», Л. Батыр-Болгари муз.; «Чәчәкләр белән күнегү», С. Сәйдәшев муз.; «Флагчыклар тотып төзелүләр», Р. Яхин муз.; «Кояш куянкайлары», Ф. Шәймәрданова муз.; «Туплар белән күнегү», Ә. Шәрәфиев муз.; «Сикергеч», Җ. Фәйзи муз.; «Мәктәп вальсы», Ә. Хәйретдинов муз.; «Без инде хәзер зурлар», А. Батыршин муз.; «Кыршау тәгәрәтү», Ю. Виноградов муз.; «Башкорт биюе», Р. Сабитов эшкәрт.; «Гөлнәзирә», башкорт халык көе, А. Кобагошев эшкәрт.; «Как пошли наши подружки», рус ха-



лык җыры, В. Агафонников эшкәрт.; «Смелый наездник», Р. Шуман; «Цирковые лошадки», М. Красев муз.; «Игра», П. Чайковский муз.; «Из-под дуба», рус халык көе, М. Иорданский эшкәрт.; «Танец», С. Затеплинский муз.; «Полька», белорус халык көе, Т. Попатенко эшкәрт.; «Ах, утушка луговая», рус халык көе, Т. Ломова эшкәрт.

*Этюдлар:* «Шаян бию», Р. Яхин муз.; «Балыкчы малай», Ә. Шәрәфиев муз.; «Шугалакта», Ю. Виноградов муз.; «Боланнар биюе», Л. Хисмәтуллина муз.; «Клоуннар», Ф. Шәймәрданова муз.; «Марш», Х. Вәлиуллин муз.; «Шаян бала», А. Монасыйпов муз.; «Беренче яңгыр», Л. Хәйретдинова муз.; «Бал корты», С. Сәйдәшев муз.; «Күбәләкләр биюе», «Чабыш», Р. Еникеева муз.; «Попляшем» («Барашенька»), рус халык көе; «Выход и пляска медвежат», М. Красев муз.; «Дождик», Н. Любарский муз.; «Солнечный зайчик», В. Мурадели муз., М. Садовский сүз.; «Обидели», М. Степаненко муз.; «Лягушки и аисты», В. Витлин муз.
*Биюләр:* «Түгәрәктә бию», татар халык көе; «Вальс», З. Хәбибуллин муз.; «Күчмә бию», татар халык көе; «Бишле бию», татар халык көе, Р. Курамшин эшкәрт.; «Дәртле бию», Ә. Абдуллин муз.; «Полька», Л. Шиһабетдинова муз.; «Кульяулыклар белән бию», татар халык көе; «Дуслаштык», Л. Хисмәтуллина муз.; «Укучылар вальсы», С. Сәйдәшев муз.; «Яңа ел полькасы» , Ф. Шәймәрданова муз.; «Парлы бию», Р. Халитов муз.; «Егетләр биюе», татар халык көе, М. Макаров эшкәрт.; «Биергә чакырам», татар халык көе, М. Макаров эшкәрт.; «Кызлар биюе», Ә. Абдуллин муз.; «Кулчатыр белән бию», Л. Хисмәтуллина муз.; «Шома бас», татар халык көе; «Мәктәп полькасы», Ф. Шәймәрданова муз.; «Күмәк бию», Л. Хисмәтуллина муз.; «Сигезле бию», татар халык көе, Ю. Виноградов эшкәрт.; «Парлы бию», татар халык көе, А. Ключарёв эшкәрт.; «Вальс», Р. Халитов муз.; «Зәлидә», татар халык көе, А. Ключарёв эшкәрт.; «Түгәрәк», З. Гыйбадуллин муз., Р. Хафизи сүз.; «Саубуллашу вальсы», Ф. Шәймәрданова

муз.; «Балалар биюе», М. Трофименко муз.; «Биергә яратабыз», башкорт халык көе, А. Кобагошев эшкәрт.; «Парлап биибез», башкорт халык көе, А. Кобагошев эшкәрт.; «Парная пляска», карел халык көе, Т. Ломова эшкәрт.; «Танец с колосьями», И. Дунаевский муз.; «Полька», Ю. Чичков муз.; «Русский хоровод», рус халык көе, В. Иванников эшкәрт.; «Танец», Ю. Чичков муз.; «Прялица», рус халык көе,Т. Ломова эшкәрт.; «Сударушка», рус халык көе, Ю. Слонов эшкәрт.; «Задорный танец», В. Золотарёв муз.; «Умарина», мордва халык көе, Р. Мостафин эшкәрт.; «Старинная плясовая», мари халык көе, С. Маков эшкәрт.; «Тункки-тункки»,чуваш халык көе.
*Характерлы биюләр:* «Уракчы кыз», татар халык көе, Р. Еникеева эшкәрт.; «Гөмбәләр», Л. Хисмәтуллина муз.; «Тиен җыры», Г. Беляева муз., А. Бәдретдинова сүз.; «Кар бөртекләре», М. Салихов муз.; «Аю балалары биюе», Ю. Виноградов муз.; «Вальс», Ю. Виноградов муз.; «Ләйсән ява», Л. Батыр-Болгари муз., Ә. Кари сүз.; «Бакалар», Л. Хисмәтуллина муз.; «Танец Петрушек», А. Даргомыжский муз. («Вальс»); «Танец снежинок», А. Жилин муз.; «Матрёшки», Ю. Слонов муз., Л. Некрасова сүз.
*Түгәрәк уеннары:* «Әйлән-бәйлән», Ф. Әбүбәкеров муз., Р. Миңнуллин сүз.; «Кә-кә-кәбестә», татар халык көе, Ш. Галиев сүз.; «Чума үрдәк, чума каз», татар халык көе, Л. Лерон

сүз., Р. Еникеева эшкәрт.; «Яңа ел», Л. Батыр-Болгари муз., Р. Вәлиева сүз.; «Кар кызы», Җ. Фәйзи муз., Н. Зариф сүз.; «Чыршы», Җ. Фәйзи муз., Н. Баян сүз.; «Ак каен», М. Вәлиев муз., З. Ярмәки сүз.; «Төймә,төймә», татар халык сүз., Р. Еникеева муз.; «Эх, зилем зиләле», татар халык җырлы-биюле уены; «Шома бас», татар халык җыры; «Яшә син, Туган илем!», татар халык җыры, Р. Еникеева эшкәрт.; «Такыя», Р. Гыйләҗева муз. һәм сүз.; «Төймә», татар халык уен җыры, Н. Бакиева эшкәрт.; «Түгәрәкле биюләр», татар халык көе; татар халык бию көенә кушылып «Бию такмаклары»; «Где зимой мели бураны», башкорт халык көе, Л. Тумашев эшкәрт., И. Мазнин сүз.; «На



горе-то калина», рус халык җыры, А. Новиков эшкәрт.; «К нам приходит Новый год», В. Герчик муз., З. Петрова сүз.; «Новогодняя», А. Филиппенко муз., Т. Волгина сүз.; «Во поле берёза стояла», рус халык җыры, Н. Римский-Корсаков эшкәрт.; «Дружат дети всей земли», Д. Львов-Комнанейц муз., Д. Викторов сүз.; Ялыке», удмурт халык җыры, В. Емельянов эшкәрт.; «Снежок белый», удмурт халык җыры, П. Поздеев эшкәрт.; «На лугу у ворот», мари халык җыры; «Белая берёза», чуваш халык җыры, Р. Ильгичева эшкәрт.

### ***Музыкаль уеннар***

*Уеннар:* «Үз төсеңне эзлә», С. Низаметдинов муз.; «Чүлмәк сатучы», татар халык уены, А. Мөҗипова эшкәрт.; «Кем беренче?», Ф. Әхмәтов муз.; «Тасмалар җый», Р. Ахиярова муз.; «Дуслашу», татар халык көе, Д. Камалеева эшкәрт.; «Түгәрәк уен», татар халык уены; «Башлык һәм таяк», татар халык көе, Р. Бакиров эшкәрт.; «Таякка атланып», Н. Җиһанов муз.; «Мәче һәм Тычкан», Л. Шиһабетдинова муз.; «Алтын әтәч», татар халык уены, Р. Еникеев муз.; «Почмаклар», З. Хәбибуллин, Р. Еникеев муз.; «Оста егетләр», башкорт халык уены, К. Рәхимов, Р. Касыймов муз.; «Бакыр бүкән», башкорт халык уены; «Плетень», рус халык көе, И. Кишко эшкәрт.; «Узнай по голосу», В. Ребиков муз.; «Бери флажок», венгр халык көе, Е.Туманян эшкәрт.; «Кто скорее?», Л. Шварц муз.; «Игра с цветными флажками», Ю. Чичков муз.; «Ищи», Т. Ломова муз.; «Рыбаки и рыбки», В. Герчик муз.; «Весёлые скачки», Б. Можжевелов муз.; «Игра парами», удмурт халык уены; «Уступи своё место», мари халык уены.

*Җырлы уеннар:* «Танышу», Г. Гыйләҗетдинова муз., татар халык сүз.; «Кап та коп», татар халык уены, Н. Бакиева муз.; «Каравылчы», татар халык уены, Ф. Шәймәрданова муз.; «Ике суык», татар халык уены, Ф. Шәймәрданова муз.; «Саныйбыз да, уйныйбыз да», татар халык көе, Э. Шәрифуллина сүз.; «Кыш бабай һәм балалар», З. Ибраһимова муз., Х. Шабан сүз.; «Почмак алыш», З. Ибраһимова муз., татар халык сүз.;



«Кем беренче кулъяулыкны ала?», татар халык көе, В. Вәлиева сүз.; «Безнең дусларыбыз», А. Ключарёв муз., М. Хөсәен сүз.; «Үрмәкүч», «Түбәтәй», татар халык уены; «Яңгыр», Ф. Шәймәрданова муз., татар халык сүз.; «Яулык алыш», татар халык уены; «Кул бәйләш», татар халык уены, Ф. Шәймәрданова

муз.; «Кәҗә, кермә бакчага», татар халык уены, А. Мөҗипова муз.; «Капкын»,татар халык уены, Д. Камалеева эшкәрт.; «Бу савытта бик күп чәчәк», татар халык җырлы уены; «Паровоз», Р. Еникеев муз., татар халык сүз.; «Кабыргалы-камчылы», башкорт халык көе һәм сүз., А. Кобагошев эшкәрт.; «Как у наших у ворот», «Камаринская», А. Быканов эшкәрт.; «Земелюшка-чернозём», рус халык җыры; «Со вьюном я хожу», рус халык җыры, В. Агафонников эшкәрт.; «Где платок?», мари халык көе, Л. Тумашев эшкәрт., Л. Яхнин сүз.; «Рыщет по лесу лисица», мордва халык көе, Л. Тумашев эшкәрт., И. Мазнин сүз.; «Солнце и месяц», чуваш халык көе, Л. Тумашев эшкәрт., И. Мазнин сүз; « В репку», чуваш халык уены, И. Вдовина эшкәрт.; «Горелки», удмурт халык көе, Л. Тумашев эшкәрт., И. Мазнин сүз.

*Биюле уеннар:* «Полька», Җ. Фәйзи муз.; «Бию», Р. Еникеев муз.; «Җайдак малай», Ш. Шәрифуллин муз.; «Курчаклар», Ф. Шәймәрданова муз.; «Мин кояшны яратам», Л. Хәйретдинова муз., Р. Миңнуллин сүз.; «Егет биюе», Ю. Виноградов муз.; «Мин – чикерткә», Л. Батыр-Болгари муз., Н. Дәүли сүз.; «Вальс», Э. Шәрәфиева муз.; «Без биибез», Р. Гатауллин муз., татар халык сүз.; «Вальс», Җ. Фәйзи муз.; «Су өстендә бию», Ф. Шәймәрданова муз.; «Су буенда», Ә. Абдуллин муз.; «Русский перепляс», рус халык җыры, К. Волков эшкәрт.; «Вышли куклы танцевать», В. Витлин муз.

*Сәхнәләштерү, музыкаль спектакльләр:* «Гөмбә җыйганда», Ш. Мазитов муз., Б. Рәхмәт сүзләре; «Ипекәй белән сөйләшү», татар халык көе, Х. Халиков сүз.; «Балалар һәм торналар», З. Хәбибуллин муз., Г. Лотфи сүз.; «Кунаклар», С. Сабирова муз., Ш. Галиев сүз.; «Карак песи», Җ. Фәйзи муз., М. Җәлил сүз.; «Балалар һәм казлар», Л. Хәйретдинова муз.,



К. Тәхау сүз.; «Кызыл мәкләр-күбәләкләр», М. Мозаффаров муз., Ә. Ерикәй сүз.; «Бала белән Күбәләк», З. Хәбибуллин муз., Г. Тукай сүз.; «Кикри-күк», Л. Батыр-Болгари муз., Д. Хәбибуллин сүз.; «Кызыклы шәкерт», Л. Шиһабетдинова муз., Г.Тукай сүз.; «Бүре һәм кәҗә бәтиләре», балалар фольклоры, Р. Еникеева эшкәрт., «Как на тоненький ледок», рус халык җыры; «Теремок», рус халык җыры.

### *Балалар музыка уен коралларында уйнау*

«Кояш чык», балалар фольклорыннан, Р. Зарипов эшкәрт.; «Хәерле көннәр телим», Ф. Җәләлетдинова муз., И. Юзеев сүз.; «Уфа-Чиләбе», татар халык көе, Л. Шиһабетдинова эшкәрт.; «Болында», Л. Шиһабетдинова муз., Ә. Ерикәй сүз.; «Чума үрдәк, чума каз», татар халык җыры; «Сыерчык», И. Шәмсетдинов муз., Г. Лотфи сүз.; «Санарга өйрәнәбез», Ф. Җәләлетдинова муз., Р. Миңнуллин сүз.; «Чияле», татар халык көе, Р. Еникеева эшкәрт.; «Бишек җыры», Г. Тукай сүз., Л. Шиһабетдинова эшкәрт.; «Зәй-зәй-зәйнәбем», татар халык көе, Н. Бакиева эшкәрт.; «Саный беләм», Р. Еникеев муз., Җ. Дәрзаманов сүз.; «Шаяру», татар халык көе, Ш. Монасыйпов эшкәрт.; «Атта»,Ф. Әхмәтов муз.; «Андрей-воробей», рус халык җыры, Е. Тиличеева эшкәрт.; «Латвийская полька», М. Раухвергер эшкәрт.; «Гармошка», Е.Тиличеева муз., М. До-

линова сүз.; «Ворон», рус халык көе, Е. Тиличеева эшкәрт.; «Барабанщик», М. Красев муз., М. Чарная сүз.



## Пр ограмманы үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләр буенча мониторинг

Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы баланың һәрьяклы (физик, социаль-шәхси, танып белү-сөйләм, нәфис-нәфасәти) үсешенә юнәлдерелә һәм баланың үсешен милли мәдәният башлангычларына якынайту, туган якны һәм татар (рус) телен өйрәнү ярдәмендә баетуны күздә тота.

Балаларның планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешүе буенча мониторинг системасы арадаш нәтиҗәләрне һәм Программаны үзләштерүнең йомгаклау нәтиҗәләрен бәяләүне күздә тота.

Программа үзләштерүнең планлаштырылган йомгаклау нәтиҗәләре мәктәпкәчә мәгарифнең төп гомуми белем бирү программасын үзләштергән 7 яшьлек баланың социаль портреты рәвешендә психолого-педагогик эшнең максатларын җентекләп тасвирлый. Алар мәктәпкәчә мәгарифнең төп гомуми белем бирү программасын эшләү һәм планлаштыру, шулай ук аны тормышка ашыру барышында *куелган көчнең юнәлешен* күрсәтәләр.

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең чыгарылыш баласы портреты гаиләнең, җәмгыять һәм дәүләтнең мәктәпкәчә яшьтәге балаларның белем бирү өлкәсендәге кызыксынуларын һәм ихтыяҗларын чагылдыра. 7 яшьлек баланың социаль портретын аның **интегратив сыйфатлары** тәшкил итә.

*Шәхси сыйфатлар* тәрбияләнүченең шәхси сферасы үсешен (ихтыяр, хис, үз-үзеңә бәя бирү, иреклелек, мотивация), шулай ук әхлакый үсешен чагылдыра.

*Физик сыйфатлар* тәрбияләнүченең физик үсешен (көч, түземлек, гәүдә сыгылмалылыгы, координация, җитезлек, тизлек) күрсәтә.

*Интеллектуаль сыйфатлар* баланың интеллектуаль сферасы үсешен (югары психик функцияләр формалашуны, социаль тәҗрибә туплауны) күрсәтә.



### ***Мәктәпкәчә мәгарифнең төп гомуми белем бирү программасын үзләштергән 7 яшьлек баланың социаль портреты***

1. *Физик яктан үскән, төп культура-гигиена күнекмәләрен үзләштергән.*

Бала гармонияле физик үсешнең мөмкин булган иң зур дәрәҗәсенә ирешкән (шәхси мөмкинлекләрен исәпкә алып). Аның төп физик сыйфатлары һәм актив хәрәкәт итү ихтыяҗы формалашкан. Үз яшенә туры килгән гигиена процедураларын мөстәкыйль башкара, сәламәт яшәү рәвешенең иң гади кагыйдәләрен үти.

2. *Кызыксынучан, актив.*

Әйләнә-тирәдәге (предметлар һәм әйберләр дөньясындагы, мөнәсәбәтләр дөньясындагы һәм үзенең эчке дөньясындагы) яңа билгесез әйберләр һ. б. белән кызыксына. Өлкәннәргә со-

раулар бирә, экспериментлар ясарга ярата. Мөстәкыйль эш итә ала (көндәлек тормышта, бала эшчәнлегенең күптөрле төрләрендә). Авырсынган очракларда өлкәннәрдән ярдәм сорый. Белем бирү процессында зур кызыксыну белән, актив катнаша.

3. *Хисчән, кеше хәленә керә белүче.*

Якын кешеләренең һәм дусларының хисләренә җавап бирә. Әкият, тарих, хикәяләрнең персонажларын кызгана, хәлләрен аңлый. Сынлы сәнгать әсәрләренә, музыкаль һәм әдәби әсәрләргә, табигать дөньясына хис-тойгылы мөнәсәбәт күрсәтә.

4. *Өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашу чараларын һәм үзара мөгамәлә ысулларын үзләштергән.*

Бала вербаль һәм вербаль булмаган аралашу чараларын бердәй куллана, әңгәмә кора белә, өлкәннәр һәм балалар белән үзара мөгамәләнең конструктив ысулларын файдалана белә (килешә, предметлар алмаша, хезмәттәшлек иткәндә эшләрен бүлешә). Өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән сөйләшкәндә, ситуациягә карап, сөйләшү стилен үзгәртә ала.



5. *Беренчел әһәмиятле күзаллаулар нигезендә үзенең тәртибе белән идарә итә ала һәм үз эш-гамәлләрен планлаштыра белә, гомуми кабул ителгән элементар нормаларны һәм үз-үзен тоту кагыйдәләрен үти.*

Баланың тәртибе минутлык теләк һәм ихтыяҗ белән түгел, ә өлкәннәр тарафыннан куелган таләпләр һәм «нәрсә ул яхшы, нәрсә ул начар» дигән беренчел әһәмиятле күзаллаулар (мәсәлән, сугышырга, кечеләрне кыерсытырга, әләкләшергә ярамый; булганың белән уртаклашырга, өлкәннәрне хөрмәт итәргә кирәк һ. б.) белән билгеләнә. Билгеле бер максатка ирешүгә юнәлтелгән эш-гамәлләрен планлаштыра ала. Урамда юл йөрү кагыйдәләре, җәмәгать урыннарында (транспортта, кибеттә, даруханәдә, театрда һ. б.да) үз-үзен тоту кагыйдәләрен үти.

6. *Яшенә ярашлы интеллектуаль һәм шәхси мәсьәләләрне чишәргә сәләтле.*

Бала мөстәкыйль үзләштергән белемнәрен һәм эшчәнлек ысулларын яңа мәсьәләләр (проблемалар) чишүдә куллана ала; ситуациягә карап, мәсьәләне (проблеманы) чишү ысулын үзгәртә белә. Ул үзенең уйлаганын тәкъдим итә ала һәм аны рәсемдә, төзүдә, сөйләмдә һ. б. да тасвирлый белә.

7. *Үзе, гаиләсе, җәмгыять (якын-тирә социум), дәүләт (ил), дөнья һәм табигать турында беренчел күзаллаулары бар. Бала күзаллый:*

*– үзе турында, үзенең һәм башка кешеләрнең билгеле бер җенестә булуы турында;*

*– гаилә составы, туганлык мөнәсәбәтләре һәм үзара бәйләнеш, гаилә вазифаларын бүлешү, гаилә гореф-гадәтләре (традицияләре) турында;*

*– җәмгыять (якын-тирә социум), аның мәдәни кыйммәтләре һәм җәмгыятьтә үзе тоткан урын турында;*

*– дәүләт (шулай ук аның символлары, «кече» һәм «зур»*

*Ватан, аның табигате ) һәм үзенең аның бер өлеше булуы турында;*



*– дөнья (Җир планетасы, төрле илләр һәм дәүләтләр, халыклар, планета табигатенең төрлелеге) турында.*

*8. Уку эшчәнлегенең универсаль алшартларын үзләштергән.*

*Кагыйдә һәм үрнәк буенча эшли белә, өлкәннәрне тыңлый, аларның күрсәтмәләрен үти.*

*9. Кирәкле күнекмәләр һәм гадәтләрне үзләштергән.*

*Бала эшчәнлегенең күптөрле төрләрен тормышка ашыру өчен кирәкле булган сөйләм, сурәтләү, музыкаль, конструкцияләү күнекмәләре бар.*

*Программаны үзләштерүнең йомгаклау нәтиҗәсе – баланың формалашкан интегратив сыйфатлары ул. Һәр сыйфат Программа үзләштерүнең бөтен чорында аны тәшкил итүчеләрне – арадаш нәтиҗәләрне формалаштырырга мөмкинлек бирә.*

*Программа үзләштерүнең арадаш нәтиҗәләре буенча мониторинг елына бер яки ике тапкыр үткәрелә. Мониторингның периодик рәвештә кабатланып торуы мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе тарафыннан билгеләнә. Мониторингның төп бурычы баланың Программаны үзләштерү дәрәҗәсен ачыклаудан һәм белем бирү процессының балада интегратив сыйфатлар формалашу динамикасына йогынтысыннан гыйбарәт. Психолого-педагогик эшнең эчтәлеге билгеле бер һәм конкрет эчтәлекне үзләштерүгә генә түгел, ә бәлки балалар тарафыннан һәр яшь чорын үзенә генә хас эшчәнлек төрләренең үзләштерелүенә һәм төрле шартларда, шулай ук яңа шартларда да практик тәҗрибәне куллана белү күнекмәләрен формалаштыруга юнәлтелгән. Программа таләпләренең балалар тарафыннан уңышлы үзләштерелүе реаль эшчәнлек процессында бәяләнә, чөнки үсеш тасвирламасы (характеристика) булып теге яки бу мәгълүматның формаль үзләштерелүе генә түгел, ә аны практик эшчәнлектә куллана белү тора.*

*Мониторинг процессында федераль дәүләт таләпләрендә күрсәтелгән физик, интеллектуаль һәм шәхси сыйфатлар ачык-*



*лана. Балаларның уңышлары түбән формалы (күзәтүләр, әңгәмәләр, педагогик ситуацияләр, әти-әниләр белән фикер алышулар һ. б.) һәм югары формалы (тестлар, сынаулар һ. б.) методлар куллану юлы белән бәяләнә. Татар (рус) теленә өйрәтү нәтиҗәләре буенча мониторингны «Говорим по-русски» («Русча сөйләшәбез)», «Говорим по-татарски» («Татарча сөйләшәбез)» (2011) уку-укыту методик комплектларына нигезләнеп үткәрү тәкъдим ителә.*

*Арадаш нәтиҗәләр диагностикасы педагогларның һөнәри эшчәнлегендә мөһим элемент булып тора, ләкин ул белем бирү процессының барышын бозмаска һәм аны катлауландырмаска тиеш. Мониторинг системасын төзүгә мәҗбүри таләп булып тиешле мәгълүмат күләмен кыска срокта алырга мөмкинлек бирә торган методлар гына куллану тора.*

***Список рекомендуемой литературы***

*1. Гаффарова С. М., Гарипова Д. С., Нигматуллина Р. С. и др. Изучаем русский язык: методическое пособие для воспитателя. (Методические рекомендации, конспекты занятий, игры и упражнения.) – Казань: Хэтер, 2011. – 296 с.*
*2. Гаффарова С. М., Гарипова Д. С., Нигматуллина Р. С. и др. Изучаем русский язык: рабочая тетрадь для детей 4–5 лет, изучающих русский язык. – Казань: Хэтер, 2011. – 44 с.*
*3. Гаффарова С. М., Гарипова Д. С., Нигматуллина Р. С. и др. Изучаем русский язык: демонстрационный материал для средней группы.*
*4. Зарипова З. М., Кидрячева Р. Г., Шарипова Л. А. и др. Татарча сљйлђшђбез: рабочая тетрадь для детей 4–5 лет, изучающих татарский язык с комплектом наклеек. – Казань: Хэтер, 2011. – 20 с.*
*5. Зарипова З. М., Кидрячева Р. Г., Шарипова Л. А. и др. Методическое пособие к рабочей тетради «Татарча сљйлђшђбез». – Казань: Хэтер, 2011. – 56 с.*
*6. Зарипова З. М., Кидрячева Р. Г., Шарипова Л. А. и др. Татарча сљйлђшђбез: демонстрационный, раздаточный материал к театрализованным играм и игровым ситуациям.*
*7. Закирова К. В. На поляне детства: хрестоматия для воспитателей дошкольных образовательных учреждений и родителей. – Казань: Редакционно-издательский центр, 2011. – 256 с.*
*8. Закирова К. В. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия. – Казан: РИЦ, 2011. — 560 б.*
*9. Шаехова Р. К. Рабочая тетрадь № 1. «Мђктђпкђчђ яшьтђгелђр ђлифбасы: авазларны уйнатып. 1нче кисђк». – Казань: Хэтер, 2011. – 96 с.*
*10. Шаехова Р. К. Рабочая тетрадь № 2. «Мђктђпкђчђ яшьтђгелђр ђлифбасы: авазларны уйнатып. 2нче кисђк». – Казань: Хэтер, 2011. – 72 с.*
*11. Шаехова Р. К. Методическое пособие к рабочей тетради «Мђктђпкђчђ яшьтђгелђр ђлифбасы: авазларны уйнатып. 1–2нче кисәкләр». – Казань: Хэтер, 2011. – 42 с.*
*12. Шаехова Р. К. Раз – словечко, два – словечко... : занимательное обучение татарскому языку. – Казань: Хэтер, 2011. – 96 с.*



***Готовятся к изданию***

*1. Гаффарова С. М., Гарипова Д. С., Нигматуллина Р. С. и др. Изучаем русский язык: рабочая тетрадь для детей 5–6 лет. – Казань: Хэтер, 2012.*
*2. Гаффарова С. М., Гарипова Д. С., Нигматуллина Р. С. и др. Изучаем русский язык: рабочая тетрадь для детей 6–7 лет. – Казань: Хэтер, 2012.*
*3. Гаффарова С. М., Гарипова Д. С., Нигматуллина Р. С. и др. Изучаем русский язык: демонстрационный материал для старшей группы. – Казань: Хэтер, 2012.*
*4. Гаффарова С. М., Гарипова Д. С., Нигматуллина Р. С. и др. Изучаем русский язык: демонстрационный материал для подготовительной к школе группы. – Казань: Хэтер, 2012.*
*5. Зарипова З. М., Кидрячева Р. Г., Шарипова Л. А. и др. Татарча сљйлђшђбез: рабочая тетрадь для детей 5–6 лет с комплектом наклеек. – Казань: Хэтер, 2012.*
*6. Зарипова З. М., Кидрячева Р. Г., Шарипова Л. А. и др. Татарча сљйлђшђбез: рабочая тетрадь для детей 6–7 лет с комплектом наклеек. – Казань: Хэтер, 2012.*

*7. Зарипова З. М., Кидрячева Р. Г., Шарипова Л. А. и др. Методическое пособие к рабочей тетради для детей 5–6 лет «Татарча сљйлђшђбез». – Казань: Хэтер, 2012.*
*8. Зарипова З. М., Кидрячева Р. Г., Шарипова Л. А. и др. Методическое пособие к рабочей тетради для детей 6–7 лет «Татарча сљйлђшђбез». – Казань: Хэтер, 2012.*
*9. Зарипова З. М., Кидрячева Р. Г., Шарипова Л. А. и др. Татарча сљйлђшђбез: демонстрационный, раздаточный материал для детей 5–6 лет. – Казань: Хэтер, 2012.*
*10. Зарипова З. М., Кидрячева Р. Г., Шарипова Л. А. и др. Татарча сљйлђшђбез: демонстрационный, раздаточный материал для детей 6–7 лет. – Казань: Хэтер, 2012.*


## *Содерж ание*

*Пояснительная записка.......................................................................... 3*
*Организация деятельности взрослых и детей по реализации и освоению Программы....................................................................... 7*
***Младшая группа (от трёх до четырёх лет)**.................................. 14*
*Содержание психолого-педагогической работы.............................. 14*
*Физическое развитие......................................................................... 14*
*Образовательная область «Здоровье»......................................... 14*
*Образовательная область «Физическая культура» ..................... 15*
*Образовательная область «Безопасность» ................................ 16*
*Социально-личностное развитие...................................................... 18*
*Образовательная область «Социализация» ............................... 18*
*Образовательная область «Труд» ............................................... 20*
*Познавательно-речевое развитие..................................................... 21*
*Образовательная область «Познание» ....................................... 21*
*Образовательная область «Коммуникация»............................... 22*
*Образовательная область «Чтение художественной литературы» .................................................................................. 23*
*Художественно-эстетическое развитие.............................................. 24*
*Образовательная область «Художественное творчество» ......... 24*
*Образовательная область «Музыка» .......................................... 26*
***Средняя группа (от четырёх до пяти лет)**.................................. 28*
*Содержание психолого-педагогической работы.............................. 28*
*Физическое развитие......................................................................... 28*
*Образовательная область «Здоровье» ........................................ 28*
*Образовательная область «Физическая культура» .................... 29*
*Образовательная область «Безопасность» ................................ 30*
*Социально-личностное развитие...................................................... 33*
*Образовательная область «Социализация» ............................... 33*
*Образовательная область «Труд» ............................................... 35*
*Познавательно-речевое развитие..................................................... 35*
*Образовательная область «Познание» ....................................... 35*
*Образовательная область «Коммуникация» .............................. 36*
*Образовательная область «Чтение художественной литературы» .................................................................................. 37*

*Художественно-эстетическое развитие.............................................. 39*
*Образовательная область «Художественное творчество» ......... 39*
*Образовательная область «Музыка»........................................... 42*
***Старшая группа (от пяти до шести лет)**.................................... 45*
*Содержание психолого-педагогической работы.............................. 45*
*Физическое развитие......................................................................... 45*
*Образовательная область «Здоровье» ........................................ 45*
*Образовательная область «Физическая культура» .................... 46*

*Образовательная область «Безопасность» ................................ 47*
*Социально-личностное развитие..................................................... 51*
*Образовательная область «Социализация» ............................... 51*
*Образовательная область «Труд» ............................................ 52*
*Познавательно-речевое развитие..................................................... 53*
*Образовательная область «Познание» ..................................... 53*
*Образовательная область «Коммуникация» ............................ 55*
*Образовательная область «Чтение художественной литературы» .55*
*Художественно-эстетическое развитие............................................ 57*
*Образовательная область «Художественное творчество» ......... 57*
*Образовательная область «Музыка»........................................... 62*
***Подготовительная к школе группа (от шести до семи лет)***...... 65
*Содержание психолого-педагогической работы.............................. 65*
*Физическое развитие.......................................................................... 65*
*Образовательная область «Здоровье» ..................................... 65*
*Образовательная область «Физическая культура» .................... 66*
*Образовательная область «Безопасность» ................................ 67*
*Социально-личностное развитие..................................................... 71*
*Образовательная область «Социализация» ............................... 71*
*Образовательная область «Труд» ............................................ 72*
*Познавательно-речевое развитие..................................................... 73*
*Образовательная область «Познание» ..................................... 73*
*Образовательная область «Коммуникация» ............................... 75*
*Образовательная область «Чтение художественной литературы» .76*
*Художественно-эстетическое развитие............................................ 78*
*Образовательная область «Художественное творчество» ......... 78*
*Образовательная область «Музыка»........................................... 82*
*Мониторинг планируемых результатов освоения Программы ....... 86*
206 Р. К. Шәехова
*Аңлатма язуы......................................................................................... 91*
*Программаны гамәлгә кертү һәм үзләштерү буенча өлкәннәр һәм балалар эшчәнлеген оештыру........................................................... 95*
***Кечкенәләр төркеме (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)***......................... 102
*Психолого-педагогик эш эчтәлеге................................................... 102*
*Физик үсеш........................................................................................... 102*
*«Сәламәтлек» белем бирү өлкәсе............................................. 102*
*«Физик культура» белем бирү өлкәсе....................................... 103*
*«Куркынычсызлык» белем бирү өлкәсе.................................. 104*
*Социаль-шәхси үсеш........................................................................ 106*
*«Социальләштерү» белем бирү өлкәсе..................................... 106*
*«Хезмәт» белем бирү өлкәсе...................................................... 108*
*Танып белү-сөйләм үсеше............................................................... 108*
*«Танып белү» белем бирү өлкәсе............................................. 108*
*«Аралашу» белем бирү өлкәсе................................................... 110*
*«Матур әдәбият уку» белем бирү өлкәсе.................................. 110*
*Нәфис-нәфасәти үсеш......................................................................... 113*
*«Иҗади сәнгать» белем бирү өлкәсе......................................... 113*
*«Музыка» белем бирү өлкәсе..................................................... 115*
***Уртанчылар төркеме (4 яшьтән 5 яшькә кадәр)***....................... 120
*Психолого-педагогик эш эчтәлеге................................................... 120*
*Физик үсеш........................................................................................... 120*
*«Сәламәтлек» белем бирү өлкәсе............................................. 120*
*«Физик культура» белем бирү өлкәсе....................................... 121*
*«Куркынычсызлык» белем бирү өлкәсе.................................. 122*
*Социаль-шәхси үсеш........................................................................ 125*
*«Социальләштерү» белем бирү өлкәсе..................................... 125*
*«Хезмәт» белем бирү өлкәсе...................................................... 127*

*Танып белү-сөйләм үсеше*........................................................... 127
*«Танып белү» белем бирү өлкәсе*............................................. 127
*«Аралашу» белем бирү өлкәсе*................................................. 128
*«Матур әдәбият уку» белем бирү өлкәсе*................................ 129
*Нәфис-нәфасәти үсеш*.................................................................. 131
*«Иҗади сәнгать» белем бирү өлкәсе*....................................... 131
*«Музыка» белем бирү өлкәсе*..................................................... 135
Төбәкнең ___________*мәктәпкәчә белем бирү программасы* 207
***Зурлар төркеме (5 яшьтән 6 яшькә кадәр)***................................. 142
*Психолого-педагогик эш эчтәлеге*............................................. 142
*Физик үсеш*.................................................................................... 142
*«Сәламәтлек» белем бирү өлкәсе*............................................. 142
*«Физик культура» белем бирү өлкәсе*...................................... 143
*«Куркынычсызлык» белем бирү өлкәсе*................................... 144
*Социаль-шәхси үсеш*................................................................... 148
*«Социальләштерү» белем бирү өлкәсе*.................................... 148
*«Хезмәт» белем бирү өлкәсе*..................................................... 150
*Танып белү-сөйләм үсеше*.......................................................... 151
*«Танып белү» белем бирү өлкәсе*............................................. 151
*«Аралашу» белем бирү өлкәсе*................................................. 153
*«Матур әдәбият уку» белем бирү өлкәсе*................................ 153
*Нәфис-нәфасәти үсеш*................................................................. 156
*«Иҗади сәнгать» белем бирү өлкәсе*....................................... 156
*«Музыка» белем бирү өлкәсе*..................................................... 160
***Мәктәпкә әзерлек төркеме (6 яшьтән 7 яшькә кадәр)***............. 168
*Психолого-педагогик эш эчтәлеге*............................................. 168
*Физик үсеш*.................................................................................... 168
*«Сәламәтлек» белем бирү өлкәсе*............................................. 168
*«Физик культура» белем бирү өлкәсе*...................................... 169
*«Куркынычсызлык» белем бирү өлкәсе*................................... 170
*Социаль-шәхси үсеш*................................................................... 174
*«Социальләштерү» белем бирү өлкәсе*.................................... 174
*«Хезмәт» белем бирү өлкәсе*..................................................... 175
*Танып белү-сөйләм үсеше*.......................................................... 176
*«Танып белү» белем бирү өлкәсе*............................................. 176
*«Аралашу» белем бирү өлкәсе*................................................. 178
*«Матур әдәбият уку» белем бирү өлкәсе*................................ 179
*Нәфис-нәфасәти үсеш*................................................................. 183
*«Иҗади сәнгать» белем бирү өлкәсе*....................................... 183
*«Музыка» белем бирү өлкәсе*..................................................... 187
*Программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләр буенча мониторинг*.......................................................................... 197
*Список рекомендуемой литературы* ............................................. 202

***Региональная программа дошкольного образования***

***Резида Камильевна Шаехова***

*Оригинал-макет подписан в печать 05.05.2012.*
*Формат 60х90 1/16. Бумага офсетная.*
*Гарнитура «Таймс». Печать офсетная.*
*Усл. печ. 13 л. Тираж 4000 экз. Заказ № 7.*
*В печать подготовлено*
*творческим объединением*
*«Редакционно-издательский центр».*
*Отпечатано в полном соответствии с качеством*
*предоставленного электронного оригинал-макета*
*в типографии филиала ОАО «ТАТМЕДИА» «ПИК «Идел-Пресс»*
*420066, г. Казань, ул. Декабристов,*___